ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

№ 1 (360)
ГЫЙНВАР 2022

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

РЕДАКЦИЯ КУНАГЫ, ОСТА КОЛУМНИСТ, ТУГРЫЛЫКЛЫ УКУЧЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Ксения Семина,
Луиза Шарова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О-0148
Басарга кул куелды: 21.01.2022
Басмадан чыкты: 27.01.2022

Коммерция директоры: Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7 9600 487 900

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КӨЧ ТУПЛАУ УРЫНЫ

Беләсезме, кайчак бер сан безнең турында, бүгенгебез һәм киләчәгебез хакында кайбер сәясәтче, икътисадчы һәм астрологлардан да күбрәкне әйтә ала. Сүз редакциядә хәтта Яңа ел табынына җыелгач та, кызып-кызып бәхәсләшкән сан турында бара. Ел ахырында әлеге санны Бөтенроссия җан исәбен алу нәтиҗәләре күрсәтте: Татарстанда халык саны беренче мәртәбә 4 миллионнан артып киткән. Килешәсездер, Яңа ел салютын һәм шампан шәрабен аттырып билгеләп үтәрлек сан. Без күбрәк. Без артабыз. Пандемия афәтенә, икътисадны акрынайткан инфляциягә һәм тынгысыз заманның башка сюрпризларына да карамастан, без күбәябез. Без алга барабыз, яңа уңышларга, казанышларга ирешәбез. Тагын шунысы да бар: уңышларыбыз, кайчак үзебез дә бәяләп бетермәгән тормыш дәрәҗәсе (чөнки яхшыга тиз ияләшәбез) безнең кебек яшәргә теләүчеләрне дә бирегә җәлеп итә. Дүрт миллион саны шуны аңлата: халык перспективалы, яшәү яхшы булган, дин төрлелеге, сөйләмдәге акцент һәм тән төсе яшәргә комачауламаган төбәктә арта.

Дүрт миллионлы кеше капиталы – теләсә кайсы эре нефть чыганагына караганда да текәрәк. Алай икән, димәк, безне бәхетле киләчәк көтәчәгенә шик юк.

Яңа ел белән, кадерлеләребез!

Сезнең оптимистик редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә



«Казан басмасы» – мөселман дөньясында

«Коръән Мәккәдә иңдерелгән, Мәдинәдә җыелган, Каһирәдә укылган, Истанбулда язылган, ә Казанда басылган!». Әлеге гыйбарә XIX гасырда Көнчыгышта очраклы рәвештә генә тумаган. Мөселманнар өчен беренче басма Коръән 1803 елда Казанда (мөселманнар тарафыннан мөселман басмаханәсендә) дөнья күрә. Әлеге максатта Санкт-Петербургтан гарәп шрифтлары китерелә. Мең ярым тираж белән нәшер ителгән беренче басма Коръән «Казан басмасы» дип атала башлый. Җиңел укыла торган уңайлы шрифтлы басма уңыш казана: Казанда чыккан Коръән күп тапкырлар яңадан нәшер ителә, Европада һәм мөселман илләрендә аңа ихтыяҗ зур була. 1803–1859 еллар арасында басылган изге китап 150 меңнән артык данәдә исәпләнә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Экологик һәлакәткә каршы Татарстан калканы
Республикада нинди полигоннар ачыла

10. Киләчәк транспорты
Без кайчан электромобильгә күчеп утырачакбыз

14. Йолдызлы күк
ЮНЕСКО Казан обсерваториясендә нәрсә тапкан

18. Көпчәк уйлап табар чак
«Татар Илон Маскы» нәрсә белән шаккатыра ала

22. Моношәһәрләр мөмкинлеге
Чаллы һәм Түбән Кама ни өчен беренче унлыкка кергән

махсус проект

26. «Без – Минтимер Шәрипович командасыннан!»
Рөстәм Миңнеханов Минтимер Шәймиев шәхесе турында

28. «Йомшак нервлар белән хакимияткә барырга ярамый»
Компромисслар һәм бердәнбер дөрес карар таба белү сәнгате

38. Хатын-кыз Президент була аламы?
Моңа Минтимер Шәймиев ничек җавап бирде

42. Мең дә бер сәләткә ия җитәкче
Капремонт буенча федераль программаны кем эшләтеп җибәрергә булышты

44. Чор фонындагы портрет
«Без бергә!» – уникаль китап ничек язылды

46. Еллар үтәр. Тарих калыр
Милли җәүһәрләр ничек торгызыла

игелекле эшләр

54. Галәм белән элемтә
Радиоэфир яшьләрне ничек җәлеп итә

58. Аш-су
Нәкыя апа Гыйләҗевада кунакта

64. Нуриәхмәт Сафинның тормыш линиясе
«Язмышыма зарланмыйм»

68. Яңа гасыр блогерлары
«Татарстан» укучылары кемнәр өчен тавыш бирле

мәңгелек кыйммәтләр

74. Тарих сәхифәләре
Михаил Худяков – романтик тарихчы

78. Китап киштәсе
Көзгедәге чагылыш

82. Татар авыллары
Кул Черкене – тиктормас авыл

88. Чыңгызлар байлыгы,
яисә келәмнәрне Рудольф Нуриев кайдан сатып алган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

31.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, – татарстанлыларга Яңа ел мөрәҗәгатендә:

– 2022 елны без Цифрлаштыру елы дип игълан иттек. Ул цифрлы икътисадны алга таба үстерүгә, халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең уңайлылыгын арттыруга юнәлдерелгән технология һәм сервисларны камилләштерергә ярдәм итәр, дип ышанам.

20.12

Талия Миңнуллина, Татарстан Республикасы Инвестицияле үсеш агентлыгы җитәкчесе:

– Ун ел эчендә Татарстан икътисадына чит ил инвестицияләре күләме, төп капиталга инвестицияләр кебек үк, 18 тапкыр артты. Безнең алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары гына да 31 миллиард сум акча җәлеп итте, 17,5 мең эш урыны булдырылды. Республика икътисады белән аеруча Төркия һәм Кытай кызыксына.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

30.12

Руслан Шагалиев, Иннополис мэры, – Татарстан Милли китапханәсендә үткәрелгән киләчәктә акыллы шәһәрләрнең тышкы күренешенә һәм аларның үсешенә цифрлы трансформация йогынтысына багышланган очрашуда:

– Минем өчен акыллы шәһәр – беренче чиратта үз кешесен аңларга һәм аның ихтыяҗларына туры китереп үзгәрергә теләгән кала ул. Инсан үзен кирәкле хис итсен һәм үз сәләтләрен тормышка ашыру мөмкинлеге таба алсын өчен шартлар тудырачак шәһәрләр кеше потенциалы ягыннан отачак. Һәм нәкъ менә шундый калалар бенчмарклар булачак, алар артыннан башкалар да тартылачак.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

акыллы гамәлләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Без **КАЙЧАН** электромобильгә күчеп утырачакбыз

Татарстанда **НИНДИ** полигоннар ачыла

ЮНЕСКО Казан обсерваториясендә **НӘРСӘ** тапкан

«Татар Илон Маскы» **НӘРСӘ** белән шаккатыра ала

Чаллы һәм Түбән Кама **НИ ӨЧЕН** беренче унлыкка кергән

PRESSA

БЕРЕНЧЕЛӘР ЧОРЫ

2021 ел Россиядә рәсми рәвештә Фән һәм технологияләр елы дип игълан ителгән иде. Аңа алмашка килгән елдан нәрсәләр көтәргә соң? Әлбәттә, яңа ачышлар һәм алдан әзерләнгән алгарышлы проектларны тормышка ашыруны. Табигый ки, бу эшләрдән Татарстан да читтә кала алмый: 2022 ел республикада Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Тормышның һәм җитештерүнең төрле өлкәләренә нәкъ менә цифрлы технологияләрне кертүнең моңарчы күрелмәгән синергетик нәтиҗәлелек бирүе инде исбатланган. Перспективалар шундый. Ә «Татарстан»ның бүгенге санында сүз чынбарлыкка әйләнә баручы алгарышлы проектлар турында барыр.

ДӨНЬЯНЫ ҺӘЛАКӘТТӘН САКЛАУДА ТАТАРСТАН КАЛКАНЫ

Ольга Туманская

2022 елның җәендә Казан янында карбон полигоны эшли башлаячак. Ул ил күләмендә гамәлгә ашырыла торган куәтле проектның бер өлеше санала. Проект экологиягә караса да, аның соңгы максаты – икътисад өлкәсе.

ҖЫЛЫ, ТАГЫН ДА ҖЫЛЫРАК!

Парник газларын чыннан да «яшел» валютага әйләндерү мөмкин икән. Иң якын киләчәктә салым өчен углеводород берәмлекләре белән «түләргә» мөмкин булачак. Ә аларны ничек эшләп табарга соң? Монда бизнеска ярдәмгә галим-биологлар һәм экологлар килә.

Сүз уңаенда, барысына да климатның глобаль җылынуы гаепле, соңгысының сәбәбе Җир атмосферасында углекислый газның, шулай ук башка климатик актив газларның артуына бәйле. Евроберлек әлеге проблемага финанс яктан радикаль якын килергә карар кылды һәм «углерод салымын» кертү ниятен белдерде. Әгәр товарны җитештерү барышында һавага парник газлары бүленеп чыга икән, мондый продукция Европа Берлеге илләренә сатылганда аңа салым салыначак. Закон 2023 елдан эшли башлаячак.

Фотолар Казан федераль университетыннан алынды

Boston Consulting Group консалтинг компаниясе фаразларына караганда, Россия өчен яңа түләүнең күләме елына 5 млрд сумга кадәр булырга мөмкин. Һәм бу Россия экспортына аяк чалачак, чөнки читкә чыгарыла торган барлык товарның 40 проценттан артыгы Евроберлеккә туры килә. Бу Европада безнең товарларның көндәшлеккә сәләтен шактый киметә. Ә инде Россия предприятиеләре (шул исәптән, әлбәттә, Татарстанныкылар) керемнең җитештерүне яңарту һәм экопроектларга салына алырлык күпмедер күләмен югалтачак.

Әлеге проблеманы карбон полигоннары хәл итәргә тиеш. Әмма бу схема ничек эшләячәк? Аңлаешлырак булсын өчен, Татарстанда әлеге проект өчен җаваплы, Казан федераль университетының Экология һәм табигатьтән файдалану институты директорының фәнни эшчәнлек буенча урынбасары Мария Кожевникова көнкүрештәге коммуналь хезмәтләр исәпләгече белән чагыштырып күрсәтә. Аның эшләү принцибын һәркайсыбыз белә: прибор куймыйсың икән, күбрәк түлисең, чөнки бүленеп бетмәгән чыгымнар синең җилкәңә төшә; куйдырасың икән, тотылган күләм өчен генә түлисең. Карбон полигоны да күпмедер дәрәҗәдә менә шундый «исәпләгеч» булырга тиеш.

Эш шунда ки, углерод җыемнарын хисаплаганда Евроберлек Россия экосистемаларының углекислый газны йотуга керткән өлешен тулы күләмдә исәпкә алып бетерми. Ә ул бик зур, чөнки дөнья урманнарының егерме проценты безнең ил территориясендә урнашкан. Алар һавага чыгарылган углеродның күпме өлешен йотарга сәләтле соң? Әйтик, тагын сулыкларыбыз моңа нинди өлеш кертә ала? Җирне экологик һәлакәттән коткарырга булышу өчен нинди махсус чаралар үткәрергә кирәк? Сораулар әлегә күп – җаваплар юк диярлек.

– Бүген безгә исәпләүләребезне башкарганда чит ил күрсәткечләрен күз уңында тотарга туры килә, – дип сөйли Мария Кожевникова. – Безнең экосистемаларыбыз моннан да күбрәк углеродны йотарга сәләтле дигәндә, безгә, исбатлагыз, дип җавап бирәләр.

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының углерод балансын контрольгә алачак технологияләрне эшләү һәм сынау буенча карбон полигоны челтәрен төзү проекты Россиядә 2021 елда эшләп китте. Татарстан әлеге проектта катнашучыларның сигезенчесе булды. Барлыгы 80 гә якын карбон полигоны ачу планлаштырыла. Сезгә бу күп тоеламы? Чагыштыру өчен: Европада алар инде 190 га якын, Төньяк Америкада – 200 чамасы.

ТАБИГАТЬНЕ «ЦИФРЛАШТЫРАБЫЗ»

50 гә 50 метрлы тигез өслекле кишәрлек урман чытырманлыгында башка планетаныкыдай күренә. Кырык метрлы мачта күккә ашкан. Ә аста – ярымсфера рәвешендәге космик корылманы хәтерләткән резервуар. Аларның үтә күренмәле капкачлары автомат рәвештә күтәрелә, «һава» йотыла, аппарат ябыла. Бераз вакыт үтә, һәм цикл кабатлана бара.

Әйе, Казан янындагы Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясеннән ерак түгел эшләп китәргә тиешле карбон полигоны тышкы яктан нәкъ менә шундый булачак. Мачта зурлыгы мондагы агачларның биеклегенә бәйле: сизгер һава тапшыргычлары урман өстеннән җиде метрга биегрәк булырга тиеш. Алты туфрак камерасы җиргә якын өслектә һава алмашынуына бәя биреп торачак. Әлеге мәгълүматлар электрон җыйгычта туплана, ә аннан соң оптик сүс кабельләр яисә wi-fi буенча турыдан-туры мәгълүмат туплауның бердәм үзәгенә озатыла. Һәр полигон шундый принцип буенча эшләячәк.

Әлеге үлчәүләр конкрет экосистема һәм атмосфера арасындагы балансны бәяләүгә юнәлдерелгән. Аның нәтиҗәләре проектка кергән төрле шәһәрләрдәге белгечләргә тапшырыла, шул исәптән Татарстан галимнәренә дә. Нәкъ менә аларга безнең табигатьнең секвестрация потенциалын, ягъни органик углеродны атмосферадан юкка чыгару һәм аны бер урында «туплау» мөмкинлекләрен бәяләргә туры киләчәк.

– Без табигатьтә барысының да ничек барганын аңларга, аның механизмнарын ачарга тиешбез, – дип төшендерә Мария Кожевникова. – Нәтиҗәдә, әлеге бурычны кайсы табигый экосистеманың яхшырак башкаруын һәм моны конкрет климатик проектны гамәлгә ашыру өчен ни рәвешле кулланып булуын ачыклый алабыз. Берникадәр вакыттан соң, без, шартлы рәвештә әйткәндә, атмосферага үзебез чыгарган парник газларын максималь дәрәҗәдә юкка чыгару өчен кайсы урында эш башкарырга кирәклеген төгәл беләчәкбез. Шул рәвешле без климатик нейтральлеккә, ягъни кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә бүленеп чыккан зарарлы матдәнең табигатьнең аны тигезләү мөмкинлегеннән артмавына ирешәчәкбез. Бу безнең глобаль җылынуга каршы көрәшкә керткән өлешебез булачак.

Татарстанның бөтен җиренә 70 әр млн сумлык манара куеп чыгып та булмый бит. Шуңа күрә галимнәрдә стационар приборлар гына түгел, дистанцион зондлаштыру технологияләре дә булачак. Дроннар ярдәмендә бөтен республикадан мәгълүмат (кәүсә һәм ябалдашының углеродны йота алу сәләте бәяләнгән һәр агачка кадәр) җыярга тиешле мультиспектраль камералар һәм радарлар эшкә җигеләчәк. Нәтиҗәдә галимнәр республиканың төрле экосистемаларының цифрлы моделен төзүгә ирешә алачак.

– Экосистеманың цифрлы моделе – ул гадиләштерелгән чынбарлык, аның белән экспериментлар ясарга була, – дип сөйли Мария



1
–Берникадәр вакыттан соң, без атмосферага үзебез чыгарган парник газларын максималь дәрәҗәдә юкка чыгару өчен кайсы урында эш башкарырга кирәклеген төгәл беләчәкбез. Шул рәвешле без климатик нейтральлеккә ирешәчәкбез, – дип аңлата Мария Кожевникова.

2
– Безнең экосистемаларыбыз моннан да күбрәк углеродны йотарга сәләтле дигәндә, безгә, исбатлагыз, дип җавап бирәләр.

3
Дроннар ярдәмендә бөтен республикадан мәгълүмат (кәүсә һәм ябалдашының углеродны йота алу сәләте бәяләнгән һәр агачка кадәр) җыярга тиешле мультиспектраль камералар һәм радарлар эшкә җигеләчәк.

Кожевникова. – Әлеге конкрет урманны сирәкләсәк яисә, киресенчә, агачларны тыгызрак итеп утыртсак, нәрсә булачак? Әлеге урында углеродны секвестрацияләүгә бу нинди йогынты ясар? Болар барысы да республика экосистемасын ничек яхшырак кулланырга кирәклеген аңларга ярдәм итәчәк.

Сүз уңаенда, бүген Татарстанда республикабызны нуль углерод балансына чыгарырга тиешле киң күләмле декарбонлаштыру программасы әзерләнә. Һәм шунда ук төтенләп утырган завод торбалары күз алдына килсә дә, төп проблема җитештерү өлкәсенә карамый. Ахыр чиктә хәтта иң «пычрак» заводны да урыны-урыны белән яңартырга була. Юк, әлеге программаның бурычы күпкә киңрәк, һәм бу күбрәк стационар булмаган чыганаклар – транспорт, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе, төзелеш, авыл хуҗалыгы урман-кырлары тарафыннан һавага чыгарылган зарарлы матдәләргә кагыла... Ниһаять, терлекчелек комплексын атарга була, ул чыгарган парник газлары транспортныкыннан да артып китә. Һәм бу углеродны яхшы фильтрлы торбага җыеп булмый. Декарбонлаштыруның комплекслы программасы кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә углеводород әзен киметүгә юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала. Һәм карбон полигоннарында галимнәр тарафыннан алынган мәгълүмат бу эштә җитди роль уйнарга тиеш була.

УРМАН-СУЛАРДА, КЫРЛАРДА

Ышанычлы якорь – ансыз бернишләп тә булмый. Татарстан карбон полигоннарының берсе суда урнашачак, чөнки Татарстан, башка төбәкләр белән чагыштырганда, шактый зур су запасларына ия. Безнең монда үзебезнең «татар диңгезе» – ике сусаклагыч кына да ни тора!

Җайланмалар Идел-Кама тыюлыгының Саралан участогы территориясендәге салда, аскы кордон районында урнаштырылачак. Каланчаның биеклеге җиде метрга якын. Әлеге үлчәүләр атмосфера белән газ алмашуда су ресурсларының нинди роль уйнавын аңларга булышачак: елгалар углекислый газны йотамы, үзләре күпме бүлеп чыгара? Мәсәлән, су күпләп бака ефәге белән капланганда. Бу участок 2023 елда эшләп китәр дип планлаштырыла. Хәер, аны эшләтеп җибәрүгә әзерлек башлаган инде.

– Иң катлаулысы – алынган мәгълүмат репрезентатив булсын өчен полигон урынын дөрес сайлау, – дип аңлата Мария Кожевникова. – Мәйданчыкны дөрес урнаштыру максатында бик күп территорияләрне карап чыктык. Таләпләр шактый. Шуларның берсе –

куркынычсызлык: җайланмаларны бозваткыч ватмаска һәм сусаклагычта су күтәрелгәндә су басмаска тиеш. Урман мәйданчыгы өчен обсерватория районы очраклы рәвештә генә сайланмады. Бу киң яфраклы урман – каен, усак, имән һәм чыршы катнаш юкәлек. Урман таксациясенә караганда, Татарстанда әлеге агач токымы өстенлек итә.

Кызганычка, Татарстан галимнәренең барлык планнары да тормышка аша алмый. Һәрхәлдә, якын араларда. Әйтик, Кама буенда җайланмалар урнаштыру. Эш шунда ки, Түбән Кама районында ылыслы урманлы зур территорияләр бар. Өстәвенә, яше шактый булган бу нарат урманы кеше кулы белән утыртылган, димәк, эксперимент өчен үрнәк бар – әгәр без бүген зур урман утыртсак, сиксән елдан соң нәрсә булачагын шактый төгәл итеп исәпли алабыз. Әмма гадәттәгечә галимнәрнең планнарына финанс мәсьәләсе аяк чала. Аны хәл итү өчен республика хакимияten һәм бизнес-җәмәгатьчелеген җәлеп итәргә уйлыйлар.

КЫРДАН ЯҢАЛЫКЛАР

Көз алдына китерегез, кырда җир сукаланмаган. Тик бу хуҗасызлыктан түгел, бәлки, фермерның No-Till технологиясен куллануын гына аңлата. Туфракны «нуль» эшкәртү вакытында җир сукаланмый, ә мүлчә белән каплана. Әлеге технология беренче карашка гади тоелса да, ул аерым белем һәм югары квалификация таләп итә. Һәм шактый зур «бонуслар» да бирә. Шуларның берсе – әлеге дә баягы «яшел» валюта, чөнки традицион сөрүдән No-Till технологиясенә күчү асылда игенчелектә углерод эзен дә, экспортка китә торган авыл хуҗалыгы продукциясенә салына торган «углерод салымын» да сизелерлек киметергә мөмкинлек бирәчәк климатик проект үрнәге булып тора.

– Без сүз алып барган мәсьәләдә аграр тематика – шул ук урманнардан аермалы буларак, иң реактив өлкәләрдән берсе, – дип сөйли Мария Кожевникова. – Бик тиз нәтиҗә алырга була, мәсәлән, бары тик җирне эшкәртү ысулын үзгәртеп яисә территориянең бер өлешенә бик тиз үсә һәм углородны яхшы йота торган техник киндер утыртып. Әмма шул ук вакытта әлеге эффект шактый кыска булырга мөмкин. Шуңа күрә безгә төрле юнәлешләр буенча эшләргә кирәк тә, шул исәптән урман һәм сулыкларны да кертеп.

Сүз уңаенда, Татарстанда эшләп китәчәк карбон полигоннарының өченчесе авыл хуҗалыгына караячак. Олы Кабан авылы тирәсендә аның өчен мәйдан әзерләнгән. Җайланмалар 2022 елның җәендә эшли башлар дип ниятләнелә. Ил күләмендә авыл хуҗалыгы карбон полигоннары алай күп булыр дип көтелми. Татарстан белән бергә, кырлардан мөһим мәгълүматны Воронеж, Тамбов һәм Ростов өлкәләрендә, Чечен һәм Башкортостан республикаларында алачаклар.

Ләкин әлеге белемнәрне реаль икътисад ни рәвешле куллана алыр соң? Җиңел һәм нәтиҗәле итеп: климатик проектлар ярдәмендә углеродны «яшел облигацияләргә» әйләндереп.

– Үз продукциясен читкә саткан предприятиенең әлеге салымны чит илгә түләве республикага файдалы түгел, климатик проектлар рәвешендә акчаны үз территориясендә калдыру отышлырак, – дип аңлата Мария Кожевникова. – Мондый һәр проект – экологик чара бит. Урман утырту яисә калдык газларны утилләштерү булсынмы ул, ягулык системасын яңарту яисә энергия алуның альтернатив чыганакларына күчүме, туфрак эшкәртү технологиясен үзгәртү яисә аның эрозиясен киметүме... Хәзер бу дәүләт һәм бизнес үзара файдалы эшчәнлек алып бара алырлык тагын бер юнәлеш. Предприятие, әйләнә-тирә мохитне яхшыртып, салым йөген киметә, ә без, галимнәр, моны ничек яхшырак итеп эшләргә кирәген өйрәтергә һәрвакыт әзер.

4
Татарстан карбон полигоннарының берсе суда урнашачак, чөнки Татарстан, башка төбәкләр белән чагыштырганда, шактый зур су запасларына ия.

5
Татарстанда эшләп китәчәк карбон полигоннарының өченчесе авыл хуҗалыгына караячак. Ил күләмендә агрономик карбон полигоннары алай күп булыр дип көтелми.

КИЛӘЧӘК ТРАНСПОРТЫ

Ксения Сёмина

Әле ике ел элек кенә Татарстанда электромобильләр өчен корылма җыю станцияләре бик зур экзотика санала иде. Бүген исә алар өч дистәдән артык. Тиздән барыбыз да электромобильгә күчеп утырырбызмы икән?

КУНАККА – ЭЛЕКТРОКАРДА

Киләчәк транспортын кору станцияләрен үстерү тизлегенә күз салсак, бу «тиздәнгә» инде ерак калмаган. Әлеге процесста актив катнашучылар – энергетиклар, кору станцияләрен җитештерүчеләр, цифрлы сервислар уйлап табучыларга күптән түгел хәтта идарәче компанияләр дә кушылды. Гомумкулланыштагы беренче стационар кору станциясе Казанда, Волгоград урамындагы күпфатирлы йорт ишегалдында пәйда булды. Станция «Безнең ишегалды» программасы һәм Мәскәү районы «ТКХ» ИК ярдәмендә ачылды. Электрокары булган һәркем үз номерын махсус реестрга кертә һәм станциядән файдалана ала.

Алга таба – тагын да күбрәк. «ТКХ» ИК директоры урынбасары Павел Карунин сүзләренә

караганда, быел шундый ук станцияләр Баруди һәм Батыршин урамнарындагы ишегалларында ачылачак. Экологик транспортка ия булачак яшәүчеләрнең ихтыяҗларын төзүчеләр дә исәпкә ала башлады. «Арт-Сити» торак комплексында баштан ук ике Schneider Electric салмак кору станциясе урнаштырылды. Моннан тыш, Казанда бүген персональ компактлы кору станцияләре дә пәйда була башлады. Техник тоташуның һәм ялгауның барлык бюрократик этапларын үтәргә казанлыларга «Рестарт» АКБО бушлай ярдәм итә.

– Мин Казанда булгалыйм, шәһәр станцияләрендә «корылам» һәм монда электромобильчеләргә игътибарның артуын күрәм. Бездә, Яр Чаллыда, бөтен шәһәргә ике тиз арада кору станциясе эшли. Шуларның берсен мин үзем урнаштырдым, – дип сөйли Nissan Leaf электромобиле хуҗасы Борис. Бу аның икенче электромобиле, әлеге модель өчен батареяларның максималь куәте 62 кВт тәшкил итә. Бер тапкыр кору 360 км га җитә, һәм Борис Чаллыдан республика башкаласына кадәр электромобилен өстәмә рәвештә кормыйча килеп җитә ала. Ә менә азрак куәтле батареяларда йөри торган электрокар хуҗалары әлегә моны эшли алмый. М-7 автоюлында берән-сәрән урнашкан станцияләр вазгыятьне тамырдан үзгәртә алмый. Шулай да процесс бер урында гына тормый. Күптән түгел генә кору станцияләре Болгарда, Чистайда, Алексеевскоеда, Базарлы Матакта пәйда булды. Моннан тыш, РФ Икътисадый үсеш министрлыгының субсидияләү программаларына өмет бар. Аның буенча Татарстан шәһәрләрендә быел 95 тиз арада (кору вакыты – 30 минуттан 1,5 сәгатькә кадәр) кору станциясе барлыкка килергә тиеш.

Хәтта кайбер үзенчәлекләргә дә карамастан, Татарстан корылма җыю инфраструктурасы үсеше дәрәҗәсе буенча күрше төбәкләр арасында лидер санала. Электромобильле булу өчен иң төп каршылыклардан берсе – кору станцияләренең юклыгы республикада хәл ителгән дияргә була. Бу вазгыятьтә электромобильчеләр саны тиз артырга тиеш кебек. Әмма чынлыкта бу алай түгел. «Рестарт» АКБО мәгълүматларына караганда, республикада хәзер бары тик 150-170 ләп кенә электромобиль исәпләнә.

БУЛМЫЙ КАЛГАН ДЕБЮТ

Моңа берничә сәбәп бар. Шуларның берсе – имидж. Кешеләр электромобильгә ияләшмәгән әле. Популярлаштыруның үтемле чарасы – лидерлар: сәясәтчеләр, блогерлар, шоу-бизнес йолдызлары үрнәге. Алар электрокарга кучеп утыра һәм башкалар белән уңай тәҗрибәсен уртаклаша алыр иде. Әмма проблема шунда: кучеп утырыр нәрсә юк.

– Хәзер Россиядә рәсми рәвештә бары тик ультрапремиум-сегменттагы яисә йөреш запасы 100 км лы яшьләр модельләрен генә сатып алырга мөмкин. Электромобильләр базары оешуын көтәбез! – дип сөйли кору станцияләре өчен цифрлы платформалар эшләү белән шөгыльләнә торган «АйТи Чардж» Мәскәү компаниясенең генераль директоры Дмитрий Матвиевский.

Россия электрокарларының төп чыганагы – БДБ илләре аша Европадан, Япония һәм АКШтан соры схема буенча машина кертү (күпчелеге – кулланууда булган). Быелга кадәр бәясе 500 меңнән (иң популяры Nissan Leaf) 4 млн сумга кадәр (мәсәлән, Tesla 3) тәшкил иткән. 2022 елдан Россиягә электромобильләр кертүгә таможня пошлиналары кире кайтарылды, шуңа күрә бәяләр артырга тиеш. Әлеге вазгыятьтә үзебезнең автоҗитештерүчеләр уенга кушыла алыр иде, әмма монда да җиңел генә түгел. 2030 елга кадәрге чорда Россия Федерациясендә электр автомобиль транспортын җитештерүне һәм куллануны үстерү концепциясе расланган, әмма аның буенча перспективалы дип аталган проектларны күпләп җитештерүгә чыгарырга әле шактый ерак.

Беренче булып базарга КАМАЗның үз электрокарын чыгару мөмкинлеге бар иде. Беренче Россия электр смарт-кроссоверы – өч ишекле, озынлыгы 3,7 метрлы, кызыл төстәге «Кама-1» хэтчбегы киң җәмәгатьчелеккә инде 2020 елның декабрендә Мәскәүдә тәкъдим ителде. Техник характеристикалары мондый: йөрү запасы – 200 км, максималь тизлеге – сәгатенә 150 км. Электрокарны Бөек Петр исемендәге Санкт-Петербург политехника университеты (СПбПУ) белгечләре проектлаштырган. Проектны эшләү бюджеты (бары тик үзебездә җитештерелгән компонентлардан җыелган) 210 млн сум тәшкил иткән, шуның 150 млн сумы – РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы гранты, ә 60 млн сумы – КАМАЗ акчасы.

Татарстан автогиганты башлыгы Сергей Когогин ул вакытта электрокар тулысынча эшләнгән дип белдерде, ә аның СПбГУдагы коллегалары машинаны сынаулар һәм сертификацияләүне узган, сериялап җитештерү алды үрнәге дип атады. Электрокарның хәтта ихтимал булган базар бәясе дә аталды –

Башкалабызның Волгоград һәм Декабристлар урамнары чатындагы ишегалдында салмак кору станциясе урнаштырылды.

1–1,3 млн сум. Әлеге проект өчен эшләнмәнең Питердагы җитәкчесе Алексей Боровков «Технологик алгарыш – 2020» бүләген алды.

Әмма могҗиза булмады. «Кама-1» сериялэп җитештерүгә кертелмәде. Аның урынына 2021 елның җәендә Сергей Когогин белән олигарх Рубен Варданян устав капиталы 720 млн сум белән исәпләнгән «Кама» ҖЧҖ предприятиесен ачты. «Кама» шул исемдәге кроссовер эшләүне нульдән диярлек башлаячак. Беренчел концепт кайбер җитди үзгәртүләргә дучар ителәчәк. Проектны максималь дәрәҗәдә тиз гамәлгә ашырган очракта 2025 елда йөрү запасы 450 км булган «Кама-1» конвейердан төшәчәк, ул 18–30 яшьлекләргә тәгаенләнә. КАМАЗның инновацияле автомобильләр баш конструкторы Сергей Назаренко сүзләренә караганда, электрокарның бәясе, максималь комплектацияне күз уңында тотканда, 1,2–1,5 млн сум булырга мөмкин. Аннан соң бераз «өлкәнрәк» «Кама-2» (1,9 млн сумга кадәр) һәм «Кама-3» (2,5 млн сумга кадәр) электрокарларын күпләп җитештерү планлаштырыла. Ләкин кулланучыга барып җитү өчен, КАМАЗга да, электрокарларны күпләп җитештерүгә әзерлеген белдергән башка Россия автомобиль компанияләренә дә шактый катлаулы бурычларны хәл итәргә туры киләчәк.

БАТАРЕЙКАЛАР КОМПЛЕКТКА КЕРМИ

Беренче чиратта – комплектлаштыру мәсьәләсе. Күпләп җитештерү өчен, эчке базарны электр двигателе, контроллер, батареялар белән тәэмин итүчеләр кирәк. Әлегә бу урын буш. Шул ук Назаренко сөйләвенчә, Россия җитештерүчеләре «Кама-1» өчен туры килгән электр двигателе һәм батареяларны тәкъдим итә алмаганга, беренче мәлләрдә алар Кытайдан, Кореядан һәм Япониядән сатып алыначак.

– Комплектлаштыру детальләренең эчке базарын оештыру процессын тизләтү өчен электромобиль җитештерүче компанияләрнең кооперациясе кирәк, һәм алар тарафыннан компонентларның аерым төрләрен уртак җитештерү яисә консорциумнар оештыру таләп ителә. Бу, беренчедән, тиз арада һәм зур күләмле инвестицияләрне җәлеп итәргә, икенчедән, продукциянең адекват бәясен сакларга, нәтиҗә буларак электрокарның үзенең бәясен дә бер дәрәҗәдә тотарга мөмкинлек бирер иде, – дип саный Россиягә электротранспорт өчен электр двигательләре, аккумуляторлар һәм башка запас частьләрне читтән кертү белән шөгыльләнүче Golden Motor Russia компаниясенең генераль директоры Сергей Антонов.

Сүз уңаенда, илебездә җитештерелгән электрокарның бәясе дә күп сораулар тудыра. Кайбер экспертлар питерлылар ясаган «Кама-1» беркайчан да серияле продукт буларак каралмады дип саный, чөнки аның компонентларының шактый өлеше проект өчен махсус эшләнгән, ә аларны күпләп җитештерүне әле оештырырга кирәк. Шуңа күрә бу, машина чыгару вакытын ераккарак этү белән бергә, аның бәясен дә төгәлрәк әйтү мөмкинлеген калдырмый.Бүгенге электромобиль хуҗалары җәмәгатьчелеге якынча икегә: гаражларында бишенче һәм алтынчы транспорт чарасы буларак бәясе 5 млн сумга кадәрле люкс электромобилен сатып алучы бик бай бизнесменнар һәм экономия йөзеннән, эчке янулы двигательле автоны куллану белән чагыштырганда, елына 50 мең сумнан артык акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирүче электромобиль (шул ук 500–700 мең сумлык Nissan Leaf) сатып алучыларга бүленә. Һәм сатып алучыларның бик аз өлеше генә – нигездә инновацияле технологияләрне, «яшел энергетика» һәм башка эксперименталь продуктларны үз итүчеләр – ниндидер уртачарак бәяне сайлый.

– 2–3 миллион сумлык электромобиль минем өчен, мәсәлән, үзенең экономияле булуын югалта. Әгәр куллануның беренче ике елында 30% бәясен югалта торган тимер өчен мондый акчалар бирәм икән, бензин яга торган машинаны тоту да минем өчен проблема булырга тиеш түгел, – дип үз фикерен белдерә Казанда яшәүче Анна Тальнова. Ул республикада беренчеләрдән булып электромобиль (тотылган Nissan Leaf) сатып алган. – Шуңа күрә минем кебекләр – бай булмаганнар дип әйтик, өстәмә акча түгәргә, ай саен бензин өчен 15әр мең акча тотарга кирәк булмаган машина сатып ала. Сүз уңаенда, башка илләрдә электр транспорты сатып алучыларга электрокар бәясенең 30–40% күләмендә субсидия бүләләр һәм шул рәвешле аларны сату һәм куллануга этәргеч бирәләр.

КАПИТАЛЬ СОРАУ

Әмма хәтта үсеш проблемаларын хәл иткәндә дә, илебездәге электр автомобиле базары бүген шактый ярлы күренә. Базарга әзер продукт белән чыгарга әзер компанияләрне бармак белән генә санарлык. Бу КАМАЗ, Тольяттидагы «Зетта», Калининградта югары локальләштерелгән электромобильләрне күпләп җитештерүгә кертәчәкләрен белдергән АВТОТОР (күрсәң, үзләрендә чыгарыла торган Kia һәм Hyundai

брендларын), Aurus (предприятие 2022 елда Aurus Komendant джибын сериялэп чыгаруны җайга салачак, ул электромобиль булырга мөмкин). Тагын – «Алмаз-Антей» оборона концерны, ул күптән түгел генә шул ук исемдәге электр кроссоверы, «Волгобас» һәм ГАЗ электробуслары сурәтен тәкъдим итте.

Күләмле инвестицияләр кертү булачак базарның зурлыгын, төрлелеген тәэмин итә алыр иде, һәм, хәзер үк оешса, яхшы булачак. Австралиядә Arrival микроэлектробусларын җитештерү буенча лаборатория оештырган Россия эшкуары Денис Свердлов стартабына 6 ел кирәк булган һәм, концептны сериялэп чыгару алдыннан тест рәвешендә үткәрелә торган сынау этабына җиткерү өчен, берничә йөз миллион евро күләмендә инвестицияләр кертелгән. Әмма, экспертлар фикере буенча, тармакка зур күләмле шәхси капиталны китерүгә Россия Федерациясендә әлеге мәсьәләдә дәүләт мөнәсәбәтенең аңлашылып бетмәве аяк чала. Мәсәлән, югарыда аталган концепциядә корылма җыю инфраструктурасын булдыруны субсидияләү (кору станциясе бәясенең 60%ы һәм технологик тоташуның 30%ы күләмендә) турында да әйтелә. Шул ук вакытта РФ Энергетика министрлыгы 2024 елга кадәр бары тик тиз арада кору пунктларын субсидияләүне генә раслады, ә электромобильчеләр һәм әлеге кырда эш йөртүче эшкуарлар салмак кору станцияләрен дә бик көтә.

КИЛӘЧӘК – ӨМЕТЛЕ

Электромобиль тармагы үсешенең кайбер авырлыкларына да карамастан, бу аны үстерүчеләрне борчымый. Электромобиль темасын киләчәккә таба этәрү өчен тырышучы чын энтузиастлар алар. Бу җәһәттән Татарстан турында әйткәндә, сәясәтчеләр арасында да, чиновниклар, электрокар хуҗалары, галимнәр, эшкуарлар арасында да мондый кешеләрнең барлыгын билгеләп үтәргә кирәк.

Мисал өчен, Казан дәүләт энергетика университеты республика хөкүмәтенең ярдәмен алды һәм хәзер үзенең күпьеллык эшләнмәләрен гамәлгә ашыра. Монда интеллектуаль электр транспорты һәм корылма җыю инфраструктурасы үзәге эшләячәк. Предприятиеләр белән бергә фәнни карарларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыралар, шул исәптән камилләштерелгән электр двигателен, шулай ук автомобиль диагностикасы һәм идарәсе системаларын эшлиләр. «Зарница» Җитештерү берләшмәсе белән хезмәттәшлек итеп, КДЭУ галимнәре электр энергиясен туплау системасы булган мобиль кору комплекслары җитештерүне оештыру проекты буенча эшли. Бу – бер үк вакытта электр транспортының төрле төрләрен, шул исәптән дроннарны кора алачак йөк контейнеры зурлыгындагы батареялар. 2021 елда КДЭУ базасында «Рестарт» АКБО белән уртак «Электромобиль һәм пилотсыз транспорт» юнәлеше буенча бакалаврлыкка укучы беренче ике төркем тупланды. Укырга теләүчеләр саны планлаштырылганнан ике мәртәбә күбрәк булып чыкты. Быел «Электр техникасы җиһазларын, электромобиль һәм корылма җыю инфраструктурасын проектлаштыру» юнәлеше буенча беренче магистр төркеменә студентлар кабул ителәчәк.

Электромобиль төзелеше, үзенчәлекле һәм оешу ягыннан катлаулы булуына да карамастан, шул өлкәгә якын эшкуарларны җәлеп итә. «Таткардан» федераль челтәре хуҗасы Рафаэль Габдрахманов экологиягә битараф булмаган яшьләргә тәгаенләнгән EVA шәһәр электропаркетнигы проектын эшләү белән шөгыльләнә. Электрокарны җитештерүдә биокомпозит материаллар кулланырга ниятли.

– Мин башка илләрдәге берничә шундый җитештерүне карадым һәм проектымны чынга ашырып була дип саныйм. Без «электромобиль – ул гаджет» концепциясе яклы. Зур булмаган ике урынлы электрокардан башлыйбыз, аннан соң дүрт урынлыга күчәчәкбез, алга таба – кечерәк йөк электромобильләренә, – дип ниятләре белән бүлешә Рафаэль Габдрахманов. Күптән түгел генә проект Иннополис резиденты статусын алган. Хәзерге вакытта проектны эшләүчеләр EVAның цифрлы варианты – алга таба модельләштерү (шул исәптән финанслар ягыннан да) максатында виртуаль электромобиль эшләү белән мәшгуль.

Иннополиста авто- һәм электромобиль төзелеше өлкәсендә электрон һәм цифрлы продуктлар уйлап табучы компанияләрне берләштергән Future Mobility консорциумы төзелгән. Консорциумның максаты – үзендә катнашучыларның продуктларын тышкы һәм эчке базарларда алга этәрү. 2022 елның июлендә анда катнашучылар Татарстанда фестиваль үткәрергә ниятли. Чараның төп темасы – электромобильләшү. Фестивальнең вип-катнашучылары арасында дөнья күләмендә әйдәп баручы җитештерүчеләрнең 12 яңа электрокар моделе булачак.

Ихтимал, республика юлларында беренче электро-«Кама», яңа энергия һәм яңа мобильлек дөньясының башлангычы булмаса да, аның органик бер өлешенә әверелер әле.

КҮКТӘ НИ БУЛМАС ДИСЕҢ...



Ольга Туманская

Энгельгардт обсерваториясе инде быел ук Татарстан Республикасының ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән дүртенче һәм туры мәгънәсендә иң йолдызлы объектына әйләнергә мөмкин.

Җәен, бернәрсә дә комачауламаса, Татарстан башкаласында ЮНЕСКОның зур конгрессы үткәреләчәк. Көн тәртибендә «Казан мәсьәләсе» дә булырга тиеш. Борынгы Астрономия обсерваториясе ЮНЕСКО объекты статусын дәгъвалаучыларның башлангыч исемлегенә КФУның тулы бер ансамбле составында – университетның баш бинасы ишегалдындагы 1837 елгы Шәһәр астрономия обсерваториясе белән бергә кертелгән.

Сүз уңаенда, җиһандагы биш йөз обсерваториядән ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә лаек дип табылганнары саны бер дистәдән артмый. Алардан да нибары икесе мөстәкыйль объект буларак, сигезе исә төрле комплекс һәм ансамбльләр составында кертелгән. Шуңа карамастан, Татарстан объектларына мондый бәхет тәтү ихтималы шактый зур. Ә инде 1675 елгы легендар Гринвич король обсерваториясе белән бер сафта булу – абруй гына түгел, киләчәктә саклану, үсү һәм шулай ук финанслану җәһәтеннән дә бик мөһим.

ҮЗ КҮЗЕҢ БЕЛӘН КҮРҮ

Юпитер, Ай, Андромеда томанлыгы чынбарлыкта нинди соң? Галәм серләрен үз күзебез белән күрүгә безгә заманча технологияләр комачаулый. Менә шундый мәгънәви оксюморон килеп чыга.

Бүген астрономнар йолдызлы күкне монитор экранына төбәлеп өйрәнә. Цифрлы технологияләр иң төгәл проекция алу мөмкинлеген бирә. Әмма бу вакытта үз күзең белән йолдызларга карап соклану тылсымы, ни кызганыч, юкка чыга шул... Зур визуаль телескоплар заманы үтте – андыйлар дөньяда нибары 26 данә исәпләнә. Шулардан берсе – Казан янындагы Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясендә.

– Менә бөтен кеше тәртипсезлекнең ничек аталуын белә, – дип каршылый безне Энгель-

Фото: Александр Ефремов; «Татарстан» журналы архивыннан

гардт исемендәге астрономия обсерваториясе директоры, КФУ профессоры, «Астровызов» стратегик академия берәмлегенең «Космик навигацияләр һәм планеталарны өйрәнү» фәнни-тикшеренү лабораториясе җитәкчесе Юрий Нефедьев.

– Хаос, – дип шундук әйтеп куйдым мин.

– Ә тәртип ничек була?

Дәшмим. Космос икән!

– Чынлыкта кешеләр безнең космостан килүебезне сиземли, – дип дәвам итә Юрий Анатольевич. – Җирдәге барлык җан иясе углеродтан тора. Бу элемент исә Җирдә барлыкка килә алмый, ул – үтә яңа йолдыз шартлау нәтиҗәсе. Шунлыктан безнең күккә тартылуыбыз табигый да: үзебезне чолгап алган Галәмне – Айдагы кратерларны, Сатурн боҗраларын безнең үз күзебез белән күрәсебез килә... Визуаль телескоп – әлеге хыялны тормышка ашыру мөмкинлеге бирә торган бердәнбер җиһаз. Безнең очракта исә мондый җиһаз матди тарихи мирас кына түгел, бәлки астрономияне популярлаштыру өчен кирәкле әсбап та.

Ирландия оптика әсбаплары ясау остасы Грабб 1875 елда төзегән 12 дюймлы рефрактор озак вакыт буе обсерваториядә җитди фәнни тикшеренүләр үткәрү өчен файдаланылган. Аны Казан император университетына Василий Энгельгардт бүләк иткән, әлеге коллекциягә тагын Грабб экваториалы, комета эзләгеч экват һәм кече комета эзләгеч, Бамбергның пассаж коралы, Фенельнең универсаль коралы, Кноблих һәм Тиде сәгатьләре кергән.

Әйе, бүген инде бу җиһазлар заманча фәнни күзәтүләр өчен файдаланылмый, әмма әлеге тиңдәшсез телескоп ЮНЕСКО мирасы булуга бик лаек. Шулай ук гелиометр телескобы да – танылган астрономия инструментлары конструкторы Репсольд остаханәсендә эшләнгән тәүге гелиометрлардан берсе ул. Яки тагын бер бик сирәк очрый торган әсбап – объективы 125 миллиметрлы меридиан түгәрәге, ул да 1845 елда шушы остаханәдә ясалган. Әлеге түгәрәктә бүлемнәр ике микронга кадәр төгәллек белән бүленгән, бүгенге техника исә 4 микронга кадәр төгәллектән арттыра алмый. Дөньяда тагын шундый нибары дүрт телескоп бар – аларны Европа музейләрында күрергә була.

Астрономнар эше өчен махсус планлаштырылган корылмалар да аерым игътибарга лаек. Шундый «җәүһәрләрдән» берсе – махсус меридиан залы, аның гадәти булмаган конструкциясе галимнәргә һаваның эчке һәм тышкы температурасын тиз арада тигезләү мөмкинлеге бирә, бу исә үтә сизгер үлчәнешләр үткәргәндә бик мөһим.

Обсерватория территориясендә астрономик күзәтүләр өчен түбәсе ачылмалы кечкенә йортлар да, әйләнмәле гөмбәзле махсус таш павильон да бар – анысында алдарак искә алынган уникаль гелиометр ярдәмендә астрономнар Меркурийның Кояш түгәрәгеннән үтүен күзәткән, аннары исә Айны озаклап күзәтүләрдә файдаланган.

Боларның барысын да астрономия фәненә гамәлдәге һәйкәл дип атап була. Һәм астрономиягә генә дә түгел. Мәсәлән, әлеге обсерваториядәге часовняда ориентир-нокта – географик меридиан, шулай ук нуленче гравиметрия пункты һәм «нуленче километр» дип атарлык репер ноктасы билгеләнгән. Аның буенча галимнәр бөтен Идел буеның төгәл координаталарын билгели торган булган. Тагын бер нокта – «нуленче түгәрәк» тә бар, анысы 1904 елда әйләнә-тирәдәге бөтен калкулыкларның биеклеген ачыклау өчен билгеләнгән.

Әлбәттә, санап кителгәннәрдән күбесен «рәткә кертү» таләп ителә. ЮНЕСКО делегатлары килгәнче, обсерваторияне бераз яңартырга: биналарга косметик ремонт ясарга, өстәмә сукмаклар һәм яңа ял итү зоналары булдырырга кирәк. Белүебезчә, иң кыйммәтле алмаз да тиешенчә кырлап шомартылуга мохтаҗ бит.

1

– Кешеләр безнең космостан килүебезне сиземли. Шунлыктан үзебезне чолгап алган Галәмне – Айдагы кратерларны, Сатурн боҗраларын безнең үз күзебез белән күрәсебез килә...

ФИЗИКА ЛИРИКАДАН БАШЛАНА

Әгәр бәхет елмайса, аларның ни турында сөйләшүен ишетергә була. Кар бөртекләрен

2
Эскәмиядә Василий Павлович Энгельгардт һәм Дмитрий Иванович Дубяго мәңгеләштерелгән. Казан янындагы обсерватория нәкъ менә шушы «йолдызлы» дуслык нәтиҗәсендә пәйда булган.

өереп алып киткән җил миңа әңгәмәнең кайбер өлешләрен китереп җиткерә: «500 әр данә томанлыгы булган Шёнфельд һәм Шульцны куып тоту өчен, миңа тагын 200 томанлык кирәк әле... Күрүегезчә, минем ниятләрем шактый кыю». «Кыю гынамы соң!» – дип елмая аңа әңгәмәдәше. Һәм аларның шундый бердәмлегеннән һәм үзара аңлашуыннан җанга рәхәт булып китә – аларның үзләренә дә, бер гасырдан соң ирексездән аларның сөйләшүен тыңлап торучыга да...

Бу – тугры дуслыкка һәйкәл. Эскәмиядә дворян, юрист һәм җәмәгать эшлеклесе, отставкадан соң бөтен гомерен яраткан шөгыле – астрономия белән мавыгуга багышлаган Василий Павлович Энгельгардт үзе һәм Казан астрономия мәктәбенә нигез салучы, Казан император университеты профессоры һәм ректоры Дмитрий Иванович Дубяго мәңгеләштерелгән. Әйе, без хәзер нәкъ менә шушы «йолдызлы» дуслык нәтиҗәсендә пәйда булган Энгельгардт обсерваториясенең тарихи бинасы янәшәсендә басып торабыз.

Сүз уңаенда, әлеге урынның тарихи мирасы – аны мәртәбәле исемлеккә кертүдә хәлиткеч шартлардан берсе. Тарих безне биредән Казанга, Германиягә генә түгел, хәтта Антарктидага да җибәрә. Һәм аның акылга сыймаслык кискен борылышлары барысы да документлар белән дәлилләнә һәм ЮНЕСКОга гаризага теркәлгән.

– Сез гаҗәпләнерсез бәлки, әмма Василий Павлович Энгельгардт бирёдә беркайчан да булмаган, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Ул үзенең хыялын Дрезденда тормышка ашырган – хосусый обсерваториясен төзеткән һәм аны астрономик күзәтүләр өчен ул замандагы иң яхшы әсбаплар белән җиһазландырган. Әлеге һәвәскәрнең нинди һөнәри биеклекләр яулавы таң калдыра – аның хезмәтләре өч томда бастырып чыгарылган һәм бөтен фәнни бергәлек тарафыннан хуплап кабул ителгән, ул үзе исә Россия Фәннәр академиясе мөхбирәгъзасы итеп сайланган!

Бервакыт, бер койрыклы йолдызны өйрәнгәндә, уйларын фикердәшләре белән бүлешәсе килгән. Хатлар язып җибәргән – җавап исә бары тик Казаннан, Дмитрий Иванович Дубягодан гына килгән. Василий Павлович хатын тикмәгә генә Казанга юлламаган. Казан университетының астрономия факультеты – Россиядә иң борынгы, ул хәтта Санкт-Петербург һәм Мәскәү университетларындагы астрономия бүлекләреннән дә иртәрәк оешкан. Дөньяга фәнни караш бергәлегенә нигезләнгән дуслык әнә шулай башланган. Ә инде өлкәнәйгәч, күзәтүләрен туктатырга мәҗбүр булгач, Василий Энгельгардт үзенең астрономия коралларын Казан университетына тапшырырга карар кылган.

– Билгеле, ул чакта Европадагы гыйльми даирәләрдә әлеге ул заман өчен иң алдынгы астрономия паркын «бер генә кулга» тапшыру ярамый, аны берничә, нигездә, әлбәттә инде, Европадагы оешмаларга бүлеп бирү мәслихәт, дигән сүзләр йөргән, – ди Юрий Нефедьев. – Әмма Василий Павлович үз сүзендә торган. Өстәвенә, ул әле обсерватория төзелешен дә финанслаган, шул рәвешле Идел буендагы фән меценатларының иң күренекле вәкилләреннән берсенә әйләнгән. Казан университеты аның бу гамәлен югары бәяләгән. Документ кабул ителгән – Василий Павловичның кабер ташындагы лампадка мәңге янып торырга тиеш.

Кар шыгырдатып, без курган янына киләбез. Төрбәдә обсерваториягә нигез салучы ике дус – Энгельгардт һәм Дубяго җирләнгән. Василий Павловичның васыятен – обсерватория янында җирләнү теләген әле күптән түгел генә үтәгәннәр. Вафатыннан соң 100 ел үткәч, 2014 елда Дрезденнан Энгельгардтның җәсәде кайтартылган һәм тантаналы рәвештә бирёдә җирләнгән.

Сүз уңаенда, әлеге «Дрезден» тарихы – обсерватория тарихи мирасының бер өлеше генә. 120 ел эчендә бу урын бөек ачышлар һәм гаҗәеп вакыйгаларга гаять бай булган, аларның төп геройлары исә – Казан галимнәре.

БУ НИНДИДЕР КОСМОС БИТ!

Дөньяда башка мондый әсбап юк. Мини-Мега-Тортора, күк сферасында зур өлкәне (900 квадрат градус) сканерлап, космик объектлардагы тиз бара торган процессларны автомат рәвештә терки. Метеорит, метеор, кече планета яки Җирнең ясалма иярченеме – берсен дә күрми калмый. Объектны тапкач, астрономик система үзенең тугыз телескобын да шундук аңа юнәлтә һәм бик ачык сурәткә төшерә, аннары шул «күрелгән» процессны цифрлы мәгълүмат йөрткечләрдә саклый.

Ә Казанга моның ни катнашы бар соң, дисезме? Мини-Мега-Тортора белән идарә итү үзәге системаның үзеннән ерактагы

3

Ирландия оптика әсбаплары ясау остасы Грабб XIX гасырда төзегән 12 дюймлы рефрактор озак вакыт буе обсерваториядә җитди фәнни тикшеренүләр үткәрү өчен файдаланылган. Бүген ул – ЮНЕСКО мирасы булуга лаек раритет.

пунктта – Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясендә эшли. Кызганычка, Мини-Мега-Торторaны Татарстанга урнаштыру мөмкин булмаган, чөнки бездә идеаль аяз төннәр бик аз.

Сүз уңаенда, бу системаны безнең Россия галимнәре һәм прибор ясаучылары уйлап тапкан. Аның ярдәмендә казанлылар тиңдәшсез күзәтүләр алып бара. Үтә яңа йолдыз шартлавын бик ачык сурәткә төшерү, мәсәлән. Әле башка беркем дә моны кабатлый алмаган.

– Әлбәттә, безнең цифрлы гасырда оптик күзәтүләр ярдәмендә җитди тикшеренүләр үткәрү шактый катлаулы, – дип сөйли Юрий Анатольевич. – Без үзебезнең фәнни фикерләребезне Галәмне өйрәнүдәге радиокүзәтүләргә һәм космик аппаратларның навигация системаларын эшләүгә юнәлтергә маташабыз.

Сүз уңаенда, Энгельгардт исемендәге обсерватория базасында яңа тикшеренүләрне киләчәктә дә үткәрүне дәвам итү – аның ЮНЕСКО объектлары исемлегенә кертелүе өчен кирәкле мәҗбүри шарт. Фән музее булу гына җитми – объектны үстерү һәм заманча технологияләр зарур! Бәхеткә, Казанда алар – күктәге йолдызлардай бихисап.

Әйтик, Россия Фәннәр академиясенең астрономия буенча гыйльми советының күптән түгел уздырылган утырышында Казан галимнәренең Айның физик либрациясен өйрәнү өлкәсендәге эше Россия Федерациясендә 2021 елдагы иң мөһим фәнни казанышлар исемлегенә, шулай ук Highlighted on Springer Nature академик нәшрият компаниясенә кертелгән. Казан фәне Айны инде күп еллар буе өйрәнә. Бу җәһәттән без дөньяда алдынгылардан саналабыз һәм хәзергә кадәр үзебезнең «айлы позицияләребезне» саклап киләбез.

– Бүген дөньяда әлеге юнәлештә нибары ике заманча фән мәктәбе эшли, алардан берсе – NASA, икенчесе – Казан университеты, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Билгеле, әлеге мәгълүмат киләчәктә Айга кагылышлы миссияләрдә файдаланылачак, чөнки Айның физик либрациясе турында белмичә гомумән төгәл координата-вакытны билгеләү мөмкин түгел бит.

Бүген Казанда алып барылган барлык астрофизик һәм астрономик фәнни тикшеренүләрне бер мәкаләдә генә санап бетерү дә мөмкин түгел. Бу – космоста һәм Җирдә координата-вакыт һәм навигация өлкәсендәге фундаменталь хезмәтләр дә; йолдызларның иң тулы каталогларын төзү дә; астероидлар һәм башка кече күк җисемнәре хәрәкәтен һәм структурасын өйрәнү дә; йолдызлар һәм Галәм төзелешен һәм эволюциясен өйрәнү дә, һәм башка бик күп нәрсә. Әлеге тикшеренүләрнең күпчелеге шундук практикада кулланыла да – ГЛОНАСС иярченнәре төркеме эшенең төгәллеген тәэмин итү булсынмы ул, космик кораблар хәрәкәтенең иминлеген саклаумы яки Җирнең астероидлар белән бәрелешү хәвефен исәпләүме...

Шунысы мөһим: Казан обсерваторияләре базасында Россиядә иң озак вакытлы күзәтүләр алып барылган. Тагын да әһәмиятлерәге исә – бу күзәтүләрнең бүген дә дәвам итүе. Энгельгардт обсерваториясе хезмәткәрләре карамагында унике телескоп эшли, шул исәптән АЗТ-14А телескобы да – ул барлык күзәтүләрне автомат режимда башкара һәм галимнәргә нәтиҗәләрне интернет технологияләре ярдәмендә эшкәртү мөмкинлеген бирә; менисклы телескоп исә астрофизик объектларны төрле фильтрлар кулланып күзәтү өчен файдаланыла. 2010 елда бирердә Роскосмос төзегән метрология полигонында ГЛОНАСС иярченнәр төркеме күзәтүләре мәгълүматлары һәм студентларның производство практикасы мәгълүматлары буенча навигация җиһазларын сынаулар үткәрелә.

Күптән түгел исә Кытайдагы коллегалары, үтә озын базалар белән радиоинтерферометрлы күзәтүләр алып бару өчен, Энгельгардт обсерваториясендә диаметры 13 метрлы зур антенна урнаштырырга тәкъдим иткән. Димәк, искиткеч бай фәнни традицияләр бирердә җиһандагы өр-яңа технологияләр белән баетыла һәм космос турында иң заманча фән пәйда булуына китерә.

КАЯ ТӘГӘРИ БУ МОТОРЛЫ КӨПЧӘК?

Ксения Сёмина

Татарстанлы Динар Минәхмәтов – берничә бизнесның хуҗасы. Башкалар аның урынында ирешелгәннәргә канәгатьләнеп, рәхәтләнеп яшәр иде, әмма бүгенге героебыз кадерле буш вакытының һәм акчасының бер өлешен тормышыбызны үзгәртергә сәләтле технологик проектларын үстерүгә сарыф итә.

БӨТЕН ИШЕКНЕ ЕРАКТАН АЧА АЛА ТОРГАН АЧКЫЧ

Кием-салым кибетенең сәүдә залы үзгәндә алсу топ һәм ачык төстәге итәк кигән, кара чәчле, төз гәүдәле бер кыз чакыргандай ишарәләп кул болгый. Якынрак килеп карагач исә, ул... робот булып чыга. Механик модельнең иптәше дә бар – гироскутердагы робот-консультант. Кунаклар янына килеп, нәрсә сатып алырга теләүләре белән кызыксына, ул нәрсәне залдан ничек табарга икәнен аңлата. Әлеге роботларны Динар Минәхмәтов һәм аның командасы берничә ел элек сәүдә үзәкләренә килүчеләрнең игътибарын җәлеп итү өчен ясаган. Ясалма интеллектлы робот-консультантның сүзлек запасы һәм аралашу сәләте автомат өйрәтү ысуллары ярдәмендә үстерелә барыр дип уйланылган. Тупланган белемнәрне исә башка машиналарга тарату күздә тотыла. Ясалма интеллектлы бер хезмәткәрнең бәясе берничә йөз мең сум тәшкил итәргә тиеш була, ул очракта эре сәүдә үзәкләре исә тулы бер робот паркын тота алыр иде. Әммә сәүдә үзәкләренә офлайн сәфәрләрне кискен киметкән пандемия проектның туктап калуына китерә.

Ясалма интеллект белән тәҗрибәләр – Динар Минәхмәтовның яраткан шөгыле генә. Программа язу эшен мөстәкыйль үзләштергән һәм 12 яшьтә беренче программасын саткан Илон Маск кебек үк, безнең героебыз да электроника белән балачактан мавыга, өлкән сыйныфларда лампалы телевизорлар һәм магнитофоннар төзәтә, читтән торып идарә ителә торган модельләр җыя. Күчемсез милек сату буенча ширкәт ачып, сатыла торган объектлар урнашкан территорияләрне видеога төшерү өчен, Минәхмәтов үз дронының проектын эшли һәм аны 3D-принтерда бастырып та чыгара.

Эшмәкәр үз бизнесы өчен фатир һәм йортларны читтән торып күрсәтү системасын да уйлап таба. Потенциаль сатып алучы үзен кызыксындырган өй-фатирга килә, менеджер исә йозак белән читтән торып кына идарә итә һәм аңа ишекне ача. Фатирда килгән кешене планшет көтә, шуның ярдәмендә видеоэлемтә аша менеджер торак буйлап экскурсия үткәрә. Фатирны карарга килгән кеше чыгып киткәч, менеджер ишекне бикли торган төймәгә баса, йозакларның бикләнүе турында мәгълүмат программада күренә. Мондый система риелтор хезмәтләрендә шактый акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Алга таба ул күчемсез милек сату буенча комплекслы хезмәтнең бер өлешенә әйләнә ала. Минәхмәтов ширкәте якын киләчәктә бу системаны сатуга чыгарырга җыена. Әммә эшмәкәрнең барлык эшләнмәләре дә бизнесның чыгымнарын киметүне күздә тотмый.

АККУМУЛЯТОР ҺӘРЧАК ЯНЫҢДА

Уйлап табучы бервакыт танышы белән ике тәгәрмәчле транспортның төрле төрләре турында фикер алыша. Электр велосипедлары турында сүз чыга. Танышы исә, аларның мәгънәсен күрмим, ди – бәяләре кыйбат, үзләре авыр, офиска алып керергә җайсыз, ә урамда калдырып булмый – урларга мөмкиннәр. Уйлап табарга оста егетнең башында шунда ук идея



Динар Минәхмәтов уйлавынча, робот-консультант, үзенә игътибар җәлеп итмичә генә, сәүдә залында сатып алучылар белән аралашырга тиеш.

туа – эченә аккумулятор урнаштырылган, салдырып алына торган тәгәрмәч ясау. Һәм велосипедның тизлеге дә яхшы булсын – сәгатенә 50 километрга кадәр.

– Менә андыйны алыр идем мин! – ди танышы.

Тиз арада Минәхмәтов универсаль конструкция ясап куя. Бу конструкция бер-берсенә тоташтырылган батареялардан, берничә төрле дисктан (тәгәрмәчне төрле модель велосипедка куеп булсын өчен), приводлар һәм электерү җайланмаларыннан гыйбарәт. Нәтиҗәдә, тиз салдырып алына торган алгы мотор-көпчәк барлыкка килә, ул велосипедка сәгатенә 50 километрга кадәр тизлек белән барырга, бер тапкыр корылып (көнкүреш электр челтәреннән алына), 35 километр юл узарга мөмкинлек бирә. Тизлек, батареяның корылмасы һәм башка параметрлар турында мәгълүмат рульгә беркетелә торган смартфонда күрсәтелә. Мотор куәте – 1 кВт. Тәгәрмәченең авырлыгы – якынча 18 кг, аны, күп дигәндә, бер минутта салдырырга һәм кире куярга мөмкин. Уйлап табучы сөйләвенчә, бөтен бер велосипедка караганда, бер тәгәрмәчне каядыр алып менү күпкә җиңелрәк. Аны үзең белән хәтта сәүдә үзәгенә дә алып керергә була, андый җирләргә велосипед белән кертмиләр.

– Шәһәрдә электр самокатларының тизлеге яңа сезоннан 25 км/сәг белән чикләнәчәк, ә безнең көпчәк ярдәмендә хезмәт урынына костюм кигән килеш җилдереп барып булачак, күлмәкне дә алыштырырга кирәкми, – дип сөйли Динар Минәхмәтов үз иҗат җимешенең өстенлекләре турында. – Өстәвенә, парковка белән дә проблема юк. Һәм соңгысы – бу отышлы. Тәгәрмәч бәясе якынча 50-60 мең сум тәш-

Үзенең төзелеш объектларын мониторинглау өчен квадрокоптерны уйлап табучы үзе проектлаштыра, аннан соң 3D-принтерда бастырып чыгара.

кил итәчәк. Шундый ук куәттәге велосипед 90–100 мең сумга төшә.

Детальләрнең бер өлеше Кытайдан сатып алыначак, аккумуляторлар японныкы булачак. Ә менә аккумулятор урнаштырылган көпчәкләрнең тулаем конструкциясенә патент алырга ирешү – мөмкин нәрсә. Хәзер мотор-тәгәрмәч сынаулар уза, аның ахыргы дизайны эшләнә. Моннан тыш, җилдән саклагыч пыяла конструкция дә эшләнә, аны шулай ук рульгә урнаштыру күздә тотыла.

Динар Минәхмәтов мавыга торган экономияле шәһәр транспорты идеясенең чираттагы алгарышлы адымы– электровеломобиль ясау. Асылда, бу – батарея һәм кабина көйләнгән ике урынлы, дүрт тәгәрмәчле велосипед. Кабина аның аэродинамикасын яхшырта, пассажирларны җил һәм яңгырдан саклый. Транспорт чарасындагы двигательнең куәте – 3 кВт, йөреш запасы – 100 км, тизлеге– сәгатенә 60 км чамасы. Тулы корылма җыю вакыты– 5 сәгать тирәсе. Хуҗа кеше өчен уңайлылыкны кайгыртып, аккумулятор салдырып алына торган булыр дип күзаллана. Машина йөртүче аккумуляторны бик җиңел генә салдырып, кабат корыр өчен, махсус арбада үзе белән алып китә алачак, электровеломобиль исә парковкада кала.

Электровеломобиль рамасының проекты ясалган инде, хәзер кабина эшләнә. Мондый электрокар шәһәр яки парклар буйлап мөстәкыйль экскурсияләр өчен дә, сәнәгать зоналарының яки сәнәгать комплексларының зур ябык территорияләре буенча хәрәкәт итү өчен дә бик шәп. Ә транспорт чарасы белән урамга чыгарга рөхсәт алынса, эшкә дә барып булачак. Әмма прототип ясауга тагын бер-ике ел вакыт китәчәк әле. Аның каравы мотор-тәгәрмәчнең тест сынаулары быел ук башланачак инде.

ТӨП-10

ИЛНЕҢ ИҢ ЯХШЫ МОНОШӘҺӘРЛӘРЕ (СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШНЕҢ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘСЕН КҮРСӘТҮЧЕЛӘР*)

ЯР ЧАЛЛЫ, ТАТАРСТАН

ТҮБӘН КАМА, ТАТАРСТАН

ТОЛЬЯТТИ, САМАРА ӨЛКӘСЕ

НОВОУЛЬЯНОВСК, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ

ГУБКИН, БЕЛГОРОД ӨЛКӘСЕ

ПАВЛОВСК, ВОРОНЕЖ ӨЛКӘСЕ

ЧЕРЕПОВЕЦ, ВОЛОГДА ӨЛКӘСЕ

КОТОВСК, ТАМБОВ ӨЛКӘСЕ

МАГНИТОГОРСК, ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ

НЕВИННОМЫССК, СТАВРОПОЛЬ КРАЕ

МӨҺИМ

Моношәһәрләр рейтингы, 2016 елдан башлап, ел саен төзелә. Ул 4 блокка берләштерелгән 17 күрсәткечтән чыгып исәпләнә: статистика күрсәткечләре, халыкны һәм бизнес вәкилләрен сораштыру нәтиҗәләре, шәһәрнең үсеш институтлары белән хезмәттәшлеген бәяләү күрсәткечләре. Рейтинг лидер моношәһәрләрнең иң көчле һәм перспективалы якларын ачыкларга, шулай ук шәһәрлеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту буенча иң яхшы проектларны билгеләргә булыша.

** Моношәһәрләрне үстерү фондының еллык рейтингы нәтиҗәләре буенча (РФ ТИБ Төркеме).*

Лидерларның казанышлары

Яр Чаллы РФ МОНОШӘҺӘРЛӘРЕ, Сәнәгатьне үстерү фонды, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү институтлары белән хезмәттәшлек итү буенча лидер булып тора, шулай ук Мәскәү Хөкүмәтенең Тотрыклы үсеш максатлары пилот проектында катнаша.

Тольятти – алгарышлы үсеш территориясенә (АҮТ) резидентларны җәлеп итү буенча рекорд куйган шәһәр, анда инде 69 резидент эшли.

Новоульяновск кече һәм урта эшкуарлык (КУЭ) предприятиеләрендә халык мәшгульлегенең зур проценты өчен югары бәя алды, шәһәрлеләр моношәһәрдә муниципаль ярдәм чараларыннан канәгать.

Губкин – моношәһәрләр арасында АҮТ резидентлары саны буенча лидерларның берсе (41), шәһәр шулай ук КУЭ сферасында эшкуарлык активлыгы потенциалы буенча югары бәя алды.

Котовск шәһәре икътисадый вазгыятькә халык тарафыннан бирелгән бәя буенча лидер дип табылды.

Павловск КУЭ субъектлары саны буенча беренче урынга чыкты.

Невинномысск шәһәрендә башлык эшчәнлегенә ышанычның югары дәрәҗәсе билгеләп үтелде, шулай ук шәһәр Надвоицы бистәсе һәм Сегежа шәһәре (Карелия Республикасы) һәм Ковдор шәһәренең (Мурманск өлкәсе) менторы булып тора.

Череповецта КУЭ субъектларының саны арткан, шәһәр шулай ук Мәскәү Хөкүмәтенең Тотрыклы үсеш максатлары пилот проектында актив катнаша.

Магнитогорск шәһәрендә кече һәм урта эшкуарлык актив үстерелә.

Түбән Кама – үсеш институтлары белән тыгыз хезмәттәшлек итә.

Ирина Макиева,
РФ Тышкы икътисад банкының шәһәрләрне үстерү буенча төп идарәче партнеры, Моношәһәрләрне үстерү фондының генераль директоры:

– Безнең ТОП-10 – үрнәк алырлык моношәһәрләр, аларга карап эш итәргә кирәк. Алар үз территорияләрен үзгәртә, аны яшәүчеләр, туристлар һәм инвесторларны җәлеп итәрлек матур, кызыклы ясый алдылар. Һәм бу шәһәр, төбәк һәм Фонд командаларының көйләнгән эше нәтиҗәсендә мөмкин булды.

Мидхәт Шаһиәхмәтов,
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстанның икътисад министры:

– Республика моношәһәрләргә ярдәм йөзеннән гамәлгә ашырыла торган барлык федераль программаларда актив катнаша. Шуның нәтиҗәсендә 13 меңнән артык эш урыны ачылды һәм 33 млрд сум күләмендә инвестицияләр җәлеп ителде. Мәсәлән, Моношәһәрне үстерү фонды булышлыгы белән Яр Чаллы һәм Түбән Кама калаларында төп автомобиль юллары төзекләндерелде. Сәнәгать паркларының инженерлык һәм юл инфраструктурасы төзелде. Әлеге инфраструктура моношәһәрләргә Haier, X5 Retail Group, OZON һәм Wildberries кебек эре бизнес субъектларын җәлеп итәргә һәм республикада кече һәм урта эшкуарлыкның үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Махсус проект

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Төп

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Рөстәм Миңнеханов өчен **КЕМ** үрнәк булып тора

Фәрит Мөхәммәтшинның онычына исемне **КЕМ** сайлаган

НИ ӨЧЕН хатын-кызга президентлыкка омтылырга кирәкми

КЕМ чиновник мундиры астында кешелек хисләрен яшерми



«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ
МАХСУС ПРОЕКТЫ

ПРЕЗИДЕНТ, РЕДАКЦИЯ КУНАГЫ, ОСТА КОЛУМНИСТ, ТУГРЫЛЫКЛЫ УКУЧЫ, БЕЗНЕҢ БАБАЙ

«Татарстан» журналының тарихы Татарстанның беренче Президенты шәхесеннән башка тулы булмас иде. Әгәр татарстанлыларның барысы өчен дә ул һәрвакыт беренче Президент булып кала икән, басмабыз редакциясе журналистлары Минтимер Шәймиев белән «туганлыкның» төрле дәрәҗәсе белән мактана ала: язмаларыбыз герое, кадерле кунак, журналның үткер каләмле колумнисты, «Татарстан»ның тугрылыклы укучысы, ниһаять. Бер сүз белән әйткәндә, үзебезнең Бабай.

Бүген безнең Бабайны 85 яшьлек юбилее белән көрәштәшләре, фикердәшләре, дуслары, журналистлар – бөтен Татарстан халкы ихлас күңелдән тәбрик итә. Басмабыз битләрендә алар беренче Президент турындагы якты уйлары, матур хатирәләре белән дә уртаклаша.

ШӘЙМИЕВ – МИНЕМ ӨЧЕН ҮРНӘК ШӘХЕС

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты

1993 елда мине Биектау муниципаль районы башлыгы итеп куйдылар. Минем Минтимер Шәрип улы Шәймиев командасында эшем нәкъ менә шул вакыттан башланды.

Минтимер Шәймиев инде ул чакта ук ил күләмендә абруйлы һәм сүзе үтә торган шәхес буларак танылды. Ул дәвердә Татарстанның яңа тарихы язылды, республика белән кызыксынучылар бихисап, безнең турыда күп сөйлиләр иде. Һәм без барыбыз да – Минтимер Шәрип улы командасында эшләүчеләр – үзебезгә йөкләнгән гаять зур җаваплылыкны яхшы тоя идек.

Минтимер Шәрип улы белән эшләү миңа нәрсә бирдеме? Бу – иң шәп университетта укуга тиң сабак. Бик күп яңа белем, тәҗрибә алдым, гаять зур практика үттем. Өстәвенә, аның республика белән җитәкчелек итүе шактый катлаулы елларга туры килде.

Шәймиев төбәкне илебез өчен сәяси һәм икътисадый яктан катлаулы вакытта җитәкли башлады. Минемчә, ул һәрвакыт республика, тулаем ил мәнфәгатьләрендәге проблемаларны хәл итүнең иң нәтиҗәле юлларын таба белде. Һәм ул кабул иткән карарлар һәрчак бик урынлы да, нәтиҗәле дә була иде.

Мин инде берничә тапкыр искә алып сөйләгәнем бар. Әлеге хәл 1990 нчы еллар азагында, мин республиканың финанс министры чагында булды. Ихтимал, бу икътисад җәһәтеннән иң кыен чор булгандыр, чөнки озак вакытка нәрсәдер планлаштыру бөтенләй мөмкин түгел иде. Һәм нәкъ менә шул чакта Минтимер Шәрип улы Казанда метро төзергә карар кылды. Яшермим, миңа бу артык кыю карар булып тоелды. Әмма Президент фәрманын үтәү мәҗбүри, баш тарта алмыйсың. Без искиткеч зур төзелешне башладык. Һәм әгәр ул чакта без моңа керешмәгән булсак, алга таба нәрсә булачагын миңа бүген күз алдына китерүе дә кыен. Казан метрополитенын төзү карары башкалабызда тулаем транспорт челтәрен үстерүгә этәргеч булды. Һәм без бүген дә бу эшне дәвам итәбез.

Ә республиканы тулысынча газлаштыру, тузган торакны бетерү кебек ифрат мөһим программалар? Шәймиев – киләчәкне күздә тотып гамәл кылучы кеше. Бүген илдә газлаштыру һәм тузган торактан күчерү юлы белән халыкның торак шартларын яхшырту мәсьәләләре иң өстенлекләләр арасында. Шәймиев исә бу эшне беренчеләрдән булып башлады.

Күптән түгел гамәлгә ашырылган үрнәк мисаллардан берсе – «Адымнар» полилингваль комплекслары челтәрен булдыру. Әйе, без барыбыз да, ата-ана өчен иң кадерлесе бала, дип әйтергә яратабыз. Ә Минтимер Шәрип улы исә, үзенә генә хас сизгерлек белән, балаларга өч телдә лаеклы белем алу мөмкинлеген бирәчәк проектны тормышка ашырырга алынды. Киләчәккә карап эш йөртү – Шәймиев принципларыннан берсе шул!

Ул хәзерге Россияне үстерү өчен күп хезмәт куйды, ватанына ихластан бирелгән милләтпәрвәр дә. Үзенең хезмәте кешеләргә сөенеч китерүен күрү аны чын-чынлап куандыра кебек тоела миңа.

Минтимер Шәрип улы бүген дә сафта. Тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу республика фонды мөселман дине, православие дине ядкәрләрен саклауны кайгырта. Әлбәттә инде, бу гамәлләр кешеләр йөрәгендә бары тик уңай хисләр генә тудыра. Минтимер Шәрип улы үзе дә бу хакта еш сөйли – Татарстанда халыклар арасында үзара дуслык һәм хөрмәт сакланып калу аның иң мөһим казанышларыннан берсе булып тора.

Шәймиевле булу, аның энергиясе, ә иң мөһиме – карарлар кабул

итү һәм җаваплылыкны үз өстенә алу кыюлыгы республикабызны иң алдынгы төбәкләрнең берсенә әйләндерде. Ул – гасырлар чигендә республикада тотрыклылыкны саклап кала алган олпат шәхесләрдән берсе. Һәм бүген дә армый-талмый эшләвен, яңадан-яңа идеяләрен, грандиоз проектларын тормышка ашыруын дәвам итә.

Минтимер Шәрип улының яраткан гыйбарәсе – «Без булдырабыз!» – гади сүзләр генә түгел, ул чыннан да шулай яши.

Мин Шәймиев командасында эшләвем белән бәхетле. Аның бүген дә безнең белән бергә, иңгә-иң торып, республикабыз халкы мәнфәгатьләрендә хезмәт куюы өчен язмышыма рәхмәтле.

КОМПРОМИССЛАР
ҺӘМ БЕРДӘНБЕР ДӨРЕС КАРАР ТАБА БЕЛҮ СӘНГАТЕ

Фәрит Мөхәммәтшин,
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Минем өчен Минтимер Шәрип улы – фикердәш тә, көрәштәш тә, остаз да, тормышның барлык өлкәләрендә шәхси үрнәк тә. Безнең бергә кичергән истәлекле вакыйгаларыбыз бик күп, әмма минем нәкъ менә бу хәлне искә алудан башлыйсым килә – ул Минтимер Шәрип улын кеше һәм сәясәтче буларак та тасвирлый, безнең үзара мөнәсәбәтләребезнең никадәр якын булуын да күрсәтә.

– Казан Ратушасында мөһим киңәшмә бара. Инде кич тә җитте... Әмма кызу бәхәсләр әле тынарга да уйламый, тегe яки бу карашны яклап яңадан-яңадан дәлилләр китерелә. Карарны тиз арада һәм бик уйлап кабул итәргә кирәк. Вазгыять шуны таләп итә. Өйдә исә мине балаларым һәм якыннарым көтә: кичен оныгыма исем куштырасы бар. Кызымның, апасы Алинә исеменә охшатып, Алисә кушасы килә. Мулла инде килгән, нишләп татар исеме кушмыйсыз, дип сорый икән. Гаиләдә бәхәс. Хәл кискенләшә бара... Шалтыратып, минем фикерне сорыйлар. Мин дә уйлыйм. Нәкъ шул чакта Минтимер Шәрип улы шалтырата, киңәшмә нәтиҗәләре турында сөйләшәбез, мин исә шул арада үземнең кичерешләрем белән дә бүлешәм: оныгым туды, исем кушарга кирәк, дим. «Кем дип кушасыз соң?» – ди. «Алисә», – дим мин. «Алисә? Ә бәлки Халисә дип кушаргадыр?» – ди Минтимер Шәрип улы. Бу исем барыбызга да ошады, бәхәс тынды.

Сәясәт – гомумән компромисслар сәнгате ул, һәм Минтимер Шәрип улы, минемчә, моның чын остасы. Ул – көчле шәхес, Россиядә һәм дөнья күләмендә танылган сәясәтче, миңа күп еллар буе аның белән иңне иңгә терәп эшләү бәхете насыйп булды. Бу вакыт эчендә акылга сыймаслык хәлләр, дискуссияләр, фикер алышулар бихисап булды, нәтиҗәдә алар Татарстанның беренче Президенты буларак Шәймиев тарафыннан республикабыз файдасына кабул ителгән принципиаль сәяси карарларга әйләнә иде.

Һичшиксез, Россия Федерациясендә Татарстанның алдынгы, динамик үсештәге, үзенең милләтара һәм конфессияара татулыгы белән көчле төбәккә әйләнүе Минтимер Шәймиев исеме белән бәйле. Иң яңа тарихның хәлиткеч елларында аның зирәклеге, җаваплылыгы һәм сәяси ихтыяры татарстанлыларны республиканың киләчәген конституцион тигезлек һәм демократик тәртип нигезендә төзү идеясе тирәсендә берләштерде. Ул формалаштырган «Татарстан моделе» күп ил тикшеренүчеләре, сәясәтчеләре тарафыннан өйрәнелде һәм хәзергә кадәр аларның игътибарын җәлеп итә.

Әлеге гаҗәеп катлаулы елларда республика җитәкчесе вазыйфасында башка кешене бүген күз алдына да китерүе кыен. Мөгаен, яшьтән үк төрле вазыйфаларда сынап, халкыбызга хас булган хезмәт сөючәнлек, кешелеклелек, сөйләшүләр үткәрү осталыгы, каршылыклы хәлләрдә салкын канлылыкны саклап калу кебек сыйфатларны мулдан биреп, тормыш үзе аны Татарстан белән җитәкчелек итүгә әзерләгәндер. Минтимер Шәрип улы үзе әйтергә яратканча, сәясәтче һәм җитәкче ул иң әүвәл «җир кешесе» булырга тиеш – әзерлекле, тормыш чынбарлыгын һәм хуҗалык эшенең тәртибен белүче, кеше белән уртак тел таба алучы. Гаҗәеп Тормыш мәктәбен үткән шәхес – ул үзе дә нәкъ менә шундый.

Минтимер Шәрип улының сәясәтче буларак тиңдәшсез сыйфатлары – эшлеклелек һәм конструктивлык, төрле, еш кына капма-каршы фикерләрне исәпкә алып дөрес карарга китерерлек дипломатия таланты. Шул ук вакытта ул принципиаль мизгелләрдә тәвәккәл, нык, эзлекле һәм төпле. Тикмәгә генә ул үзенең тормыш

кредосын сыйфатлаганда: «Йомшак нервлар белән хакимияткә барырга ярамый», – дип әйтми инде.

Минемчә, нәкъ менә шуңа күрә аның сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе өчен иң кадерле нәрсәсе – милләтенә, диненә, яшенә, һөнәренә яки идея инануларына карамастан, бар халыкның ышанычы һәм хуплавы, коллегалары һәм оппонентлары арасында хөрмәте һәм абруе бар.

Турысын әйткәндә, нәкъ менә Минтимер Шәймиев Татарстанда хәзерге заман сәясәте мәктәбен төзеде һәм реформалар чорын үзе белән иңгә-иң үткән хакимият, предприятие һәм оешма җитәкчеләре өчен аның беренче мөгаллиме булды. Мин әле һаман үземне карарлар кабул итәргә, барысын да алдан исәпләп уйларга, аңларга һәм ышандырырга аннан өйрәнәм дип саныйм. Аның: «Беркайчан да дәлилләрсез халык каршына чыкма, дәлилләрең исә корычтай нык булсын», – дигән сүзләрен мин гомергә исемдә калдырдым.

Бүген инде Минтимер Шәрип улы уйлап тапкан һәм гамәлгә керткән бөтен нәрсә кайчандыр үзе дә Шәймиев командасында булган һәм хакимият баскычларыннан һаман өскәрәк күтәрелеп алга барган Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кулында тулы куәткә эшләвен дәвам итә.

Үз халкының лаеклы улы Минтимер Шәймиев гомере буе туган республикасына фидакарь хезмәт итә. Болгар һәм Зөяне торгызу, Казан соборын төзү, «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» полилингваль мәктәпләр челтәрен булдыру – болар барысы да Минтимер Шәймиевнең ватандашлары файдасына тырышлыгына мисал булып тора.

- ХӨРМӘТЛЕ МИНТИМЕР ШӘРИПОВИЧ!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм шәхсән үз исемемнән чын йөрәктән Сезне 85 яшь тулган көнегез белән тәбрик итәм. Һәр көн Сездән гаять күп көч һәм энергия таләп итә. Шунлыктан бүгенге туган көнегездә мин Сезгә нык сәламәтлек, игелек, барлык өметләрегезнең аклануын, планнарыгызның тормышка ашуын телим.

РЕДАКЦИЯ КУНАГЫ

ТАТАРСТАН 12 2005

"Татарстан халкына лаеклы хезмәт итүегез өчен рәхмәт сезгә!"

бөек традицияләргә тугры дип әйтә алам. Без һәрвакыт әчке әхлакый, социаль жаваплылык хисе белән эшлибез, шул ук вакытта бездә һәрвакыт горурлык хисе дә яши". Шуна күрә, дип дәвам итте Рифат Фәттахов, республикабыз Президентының бүгенге визитын без журналның хәзерге коллективын тануы, аңа хөрмәт күрсәтүе дип кабул итәбез.

Баш мөхәррир чыгышында журнал үсешендәге хәзерге һәм стратегик хәл-халәт хакында уйландырырлык фикерләр янгырады. Ул журналның бүгенге чор массакүләм мәгълүмат чаралары базарына тагын да активрак һәм һөжүмчәнрәк үтеп керүенең катгый зарурлыгы турында сөйләде. Шул ук вакытта, дип ассызыклады ул, республика кысалары гына күз алдында тотылмый.

Журналның финанс хәлөте мәсьәләсенә килгәндә, Рифат Фәттахов басмага Президент, хөкүмәт һәм республика тарафыннан булышлык күрсәтелгәне өчен рәхмәт белдерде. Журналның үз табышы базасын (реклама-коммерция хезмәтенең шактый әйбәт эшләве нәтижәсендә) арттыру юнәлешендә мәгълүм бер кимәлдә уңышка ирешүләре турында сөйләп, ул игътибарны бигрәк тә ижтимагый-сәяси басма өчен тирән эчтәлекле язмалар һәм реклама мәкаләләре арасында тигезлек саклауның мөһимлегенә юнәлтте.

Алга таба Рифат Фәттахов, аның фикеренчә, бик тә четерекле һәм хәвефле мәсьәләгә карата борчылуын белдерде. Бу мәсьәләнең асылы, республика басмаларын үз чыгымнарын тулысынча үзләре капларлык дәрәжәгә куярга кирәк, дигән кайбер тәкъдимнәрдән гыйбарәт. Әмма шактый күп кенә абруйлы белгечләр фикере һәм икътисадый анализ нәтижәләре "Татарстан" журналының бу дәрәжәгә, ягъни үз чыгымнарын 100%ы белән үзе каплау кимәленә фәкать басманың татар телендәге вариантын чыгарудан баш тартканда гына ирешә алачагын күрсәтә. Әлеге бәяләмә, реклама бирүчеләр, кызганыч ки, татар басмалары белән хезмәттәшлек итәргә һич тә ашкынып тормыйлар, дигән фикергә нигезләнә. "Югыйсә, татар вакытлы матбугаты, - диде баш мөхәррир, - массакүләм аралашу чарасы гына түгел. Ул барыннан да элек милли мәдәниятебезнең аерылгысыз өлеше. Тагын да кинрәк итеп әйтсәк, ул - безнең милли казанышыбыз".

Татар телендәге басмаларның язмышы турында Рифат Фәттаховның борчылып әйткән фикерләрен хуплап, Татарстан Президенты катгый рәвештә: "Без үз-үзебезгә һөжүм итә алмыйбыз", - диде һәм республикабызда ике дәүләт телендә чыгып килүче барча гавами матбугат чаралары өчен мондый рухтагы мәсьәлә хәтта бөтенләй куелмаска тиеш дип белдерде. Басма йә тулысынча яши, йә бөтенләе белән яшәүдән туктый. Икенче төрле әйтсәк, йә ике телдә дә чыга, йә икесе дә юк. Журналның бер телдә чыгучы вариантын икенче телдәгесе хисабына саклап калу - дөрес хәл түгел. М. Ш. Шәймиев фикеренчә, республикабызда икетеллелек хөкем сергән, толерантлылык-түземлелек, милләтләр һәм диннәр арасында татулык тантана кылган шартларда "басманың бөтен яклап та тулыканлы булып калуы аеруча әһәмиятле". ТР Президенты залда утырган рәсми затларга һәм журналистларга мөрәжәгать итеп: "Минемчә, әлеге мәсьәләдә без принципиаль рәвештә килештек", - дип белдерде.

Аннары баш мөхәррир Рифат Фәттахов, журналның үз табыш базасын киңәйтү юнәлешен саклап калган тәкъдирдә, базар шартларында басманың киләчәктә эш тактикасын бәян итте. Ул ТР Президентына редакция эшчәнлеген төрле яклап үстерү планнары турында сөйләде. Бу җәһәттән өстенлекле юнәлешләрдән берсе - нәширлек эшчәнлеге. Ә бу өлкәдә мәгълүм бер уңай тәжрибә бар инде. Журналга берничә кушымта булдыру күздә тотыла. Басманы

2005 ЕЛ

"ТАТАРСТАН" ЖУРНАЛЫНА - 85

тарату буенча үзебезнен альтернатив системабызны булдыру эшен тагын да активлаштырачакбыз. Шулай ук реклама сыйфатын яхшырту, димәк ки, бәясен күтәрү хисабына, журналда реклама мәйданнарын арттырмау максатын куябыз.

"Шул рәвешчә, - дип тәгәлләде үз сүзен Рифат Фәттахов, - без "Татарстан" журналының нәшрият йортын булдыруга ныклап якын килергә җыенабыз... Әлбәттә, проблемалар бездә дә җитәрлек. Ләкин алар безне шурләтми. Проблемалар аларны хәл итү өчен туалар. Без үзебезнен кирәк икәнлегебезне тоябыз. Без булдырабыз!"

Журнал коллективын һәм аның даими авторларын тәбрик итеп, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев бүгенге визитының, журналның, үткәненә генә түгел, аның бүгенге көненә дә икәнлеген ассызыклап үзды. Ул әлеге басманың совет чорында да зур популярлык казануын, республикабызда гына түгел, ә бөтен ил күләмендә танылуын билгеләп узды. "Бәхәссез ки, журналның бүген дә җәмгыять төзелешенен яңа шартларында үз урыны бар", - диде Илбашы һәм бер үк вакытта хәзерге конкурентлык-көндәшлек журнал редакциясе коллективын яңача эшләргә мәҗбүр итә дип белдерде. Журналның көтеп алынганлыгы, кирәклеге - баш мөхәррир һәм талантлы коллектив тарафыннан куелган хезмәт нәтиҗәсе ул, дип бәяләде республика башлыгы. "Журналның эчтәлеге зур кызыксыну уята. Әлеге бәя күпне аңлата. Ул тематикасы, юнәлешләре белән дә, эчтәлеге, материалларның бирелеше, сыйфаты белән дә үзенә җәлеп итә - аны рәхәтләнеп кулга аласың", - диде М. Ш. Шәймиев. Көндәшлек, хәрәкәткә китерүче көч буларак, безне даими рәвештә эшләргә, алга барырга мәҗбүр итә, дип дәвам итте ул үз сүзен: "Көндәшлек, әлбәттә, җитди нәрсә. Мондый шартларда гадәти рәвештә генә эшләү аз. Үз журналыгызның позицияләрен тагын да ныгыту өчен эшләргә кирәклеге сорала. Бер үк вакытта акрынлап республика чигеннән үтеп чыгу зарур. Бу сезнен кулыгыздан килә", - дип ассызыклап әйтте Илбашы. "Бүген сезне шәхсән үз исемемнән, Татарстан Хөкүмәте һәм Дәүләт Советы исеменнән шушы күркәм юбилей белән чын күңелдән котларга мөмкин һәм котларга кирәк!"

Минтимер Шәймиев үз чыгышында, "Татарстан" журналы хаклы рәвештә бай иҗат традицияләре белән горурлана ала, диде һәм төрле елларда журналны җитәкләгән, танылган, талантлы һәм сәләтле журналистларның эшчәнлеген җентекләп күздән кичерде. Президент Ш. Хамматов, Ш. Вәлиев, А. Афанасьев, Д. Шәрәфетдинов, Р. Мостафин исемнәрен рәхмәт сүзләре белән искә алды.

Минтимер Шәймиев шулай ук хәзерге вакытта башка журналларның да язмышы турында фикерләр әйтте. Мәгълүматларның ифрат мул булуына, телевидение һәм газеталар кысрыклавына да карамастан, журналлар яши бирә һәм яшәячәк, дип саный ул. "Мәгълүматлар белән шыплап тулган гавамдә "Культура" телеканалы пәйда булгач, һәммәсе дә җиңел сулап куйдылар. Ниһаять, җанга якын нәрсә барлыкка килде. Мәгълүматларның чиктән тыш тыгызлыгы туйдыра башлый, адәм балаларының тормыш фәлсәфәсе әнә шундый... Хәзерге журналлар, эш бик әйбәт башкарылганда, үзләрен кулга карандаш алып укырга мәҗбүр итәләр. Журналлардагы төпле материаллар үзләренә җәлеп итәләр, үзләренә тарталар. Журнал журналистикасы яшәргә сәләтле һәм кирәкле, киләчәктә тагын да ныграк кирәкле булачак". Минтимер Шәймиев елмаеп, коммунистлар партиясенен инде күптән булмавын искә төшерде, ә журналның һаман яшәвен хуплады. "Монда нидер бар", - диде ул. Шул ук вакытта ТР Президенты журналның республикада күппартиялелекне яктыртуга тиешле игътибар бирмәвен әйтте.

Аннары Минтимер Шәймиев журналистларның Казанның меңьеллыгын



2005 елда «Татарстан» журналы үзенең 85 еллыгын бәйрәм итте. Басмабыз юбилеена республика Президенты да килде. **«Татарстан халкына лаеклы хезмәт итүегез өчен рәхмәт сезгә!»** – дип, журналистларга ихлас күңелдән рәхмәтен җиткерде ул чакта Минтимер Шәймиев.

ОСТА КОЛУМНИСТ

: җәмгыять : яңарыш : ихлас күңелдән

БОЛГАР ФОРУМЫ УҢЫШЛЫ ЭШ БУЛЫП ЧЫКТЫ

Михаил КОЗЛОВСКИЙ фотосы

Минтимер ШӘЙМИЕВ
тексты

УЗГАН ЕЛНЫҢ 19–21 ИЮНЕНДӘ БЕЗ ТРАДИЦИЯ БУЕНЧА ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЛАРЫНЫҢ ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ РӘВЕШТӘ КАБУЛ ИТҮЛӘРЕНӘ 1121 ЕЛ ТУЛУНЫ БИЛГЕЛӘП ҮТКӘН ВАКЫТТА, ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ КӨННӘРЕНДӘ, БОЛГАР ҖИРЕНДӘ БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ГАЛИМНӘРНЕҢ ХАЛЫКАРА БОЛГАР ФОРУМЫ ҮТКӘРЕЛДЕ. АНЫ ОЕШТЫРУ ТУРЫНДАГЫ КАРАР БЕЗНЕҢ БАШЛАНГЫЧ БУЕНЧА ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ, МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ ҺӘМ КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ ТАРАФЫННАН КАБУЛ ИТЕЛДЕ. МАКСАТЫ – БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕН КҮПСАНЛЫ ЮНӘЛЕШЛӘРДӘ ТИКШЕРҮЧЕ БЕЛГЕЧЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРҮ, БОЛГАР МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫГЫН МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ТУРИСТЛЫК ҮЗӘГЕ БУЛАРАК ҮСТЕРҮ, БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ ЧЫГАНАКЛАРЫН ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮ. ФОРУМДА ЙӨЗДӘН АРТЫК ГАЛИМ, РОССИЯДӘН ҺӘМ ЧИТ ИЛЛӘРДӘН РӘСМИ ВӘКИЛЛӘР КАТНАШТЫ, АНЫҢ ФӘННИ ДАИРӘДӘ ЯҢГЫРАШЫ ЗУР БУЛДЫ.

2010–2011 ЕЛЛАР

: җәмгыять : яңарыш : ихлас күңелдән

РУХИЯТКӘ ИРЕШҮ ЮЛЫНДА

Минтимер ШӘЙМИЕВ
тексты

БЕЗ ЯҢА ЕЛГА ЯҢА ИДЕЯЛӘР, ЯҢА ПЛАННАР ҺӘМ ЯҢА КӨЧЛӘР БЕЛӘН КЕРӘБЕЗ. Ә ЯҢА КӨЧЛӘРНЕҢ ЧЫГАНАГЫ – ЭШЛӘНГӘН ЭШЛӘРЕБЕЗДӘ. УЗГАН ЕЛНЫҢ СИГЕЗ АЕ ЭЧЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИХИ ҺӘМ МӘДӘНИ ИСТӘЛЕКЛӘРЕН ТОРГЫЗУ РЕСПУБЛИКА ФОНДЫ ТАРАФЫННАН, РЕСПУБЛИКАБЫЗ ХАЛКЫ ҺӘМ ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН, БОРЫНГЫ ШӘҺРИ БОЛГАРНЫ ҺӘМ УТРАУ-ШӘҺӘР СВИЯЖСКИНЫ ТОРГЫЗУ БУЕНЧА КҮП НӘРСӘ ЭШЛӘНДЕ. БЕЗ НИЯТЛӘГӘННЕҢ ЗУР ӨЛЕШЕН БАШКАРЫП ЧЫКТЫК. ЧЫНЛАП ТА, СӨЙЛӘР ӨЧЕН НИГЕЗ БАР. 2010 ЕЛДА ФОНДНЫ ОЕШТЫРДЫК, БЕРДӘМ ТОТЫНЫП, ӘЛЕГЕ ИГЕЛЕКЛЕ ЭШТӘ ЯХШЫ СТАРТ АЛДЫК ҺӘМ ЮЛНЫҢ ГАЯТЬ ҖИТДИ ӨЛЕШЕН УЗДЫК.

Төгәлрәк әйткәндә, торгызыла һәм төзелә торган объектларның барысында да кызу эш бара. Заманча технологияләр төзү эшләренең кайберләрен хәтта кыш көне дә дәвам итәргә мөмкинлек бирә. Реставрация эшләрен дә ел әйләнәсе алып барабыз. Инженерлык челтәрләрен төзү буенча эш ахырына якынлаша. Бу су үткәрүгә, канализация һәм чистарту корылмалары булдыруга кагыла. Болгарда әлеге челтәрләргә бәйле мәсьәләләр инде хәл ителгән диярлек. Свияжск утравына газ кертелде. Хәзерге вакытта газны мәдәният биналарына, православие храмнарына һәм торак йортларга кертү бара. Болгардагы һәм Свияжскидагы объектларда төзү-төзекләндерү эшенә керешкән инвестор-предприятиеләр, узган елның май аеннан башлап, зур күләмдә эшләр башкарырга өлгерделәр.

Фотолар ТР Президентының матбугат хезмәтеннән алынды.

50 **татарстан** / гыйнвар / 2011

2010–2011 елларда Минтимер Шәймиев журналыбызның колумнисты булды, басмабыз битләрендә үз колонкасын алып барды. Укучыларыбыз Болгар һәм Зөядә барган торгызу-яңарту эшләре турында әлеге эшләрнең башында торган кешедән ишеттеләр.

ТУГРЫЛЫКЛЫ УКУЧЫ

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР / КАДЕРЛЕ

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ КИТАП КИШТӘСЕ

«Китапларым тәртиптә түгел, тик бу барыбер матурлык дөньясы!» – ди Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев. Аның эш бүлмәсендә бөтен өстәлләр һәм тумбочкалар китап белән тулган. Тарихи-мәдәни мирасны торгызу эше белән шөгыльләнгәч, хәзер Татарстанның беренче Президенты күбрәк тарих, археология, архитектура турында укый...

48 ТАТАРСТАН / №01 / 2017





Минтимер Шәймиев һәрвакытта да «Татарстан» журналының тугрылыклы укучысы булды. Еш кына, чираттагы санybыз дөнья күргәннән соң, без аңардан кәгазь битенә язылган хуплау, мактау сүзләре алабыз, кайберләрен журнал тышлыгына да беркетеп куябыз:

«Так держать, ребята! У вас получается!»

Бүген, 85 яшьлек күркәм юбилей көнендә, без Минтимер Шәриповичны журналыбызның 85 еллыгы уңаеннан безгә аталган үз сүзләре белән үк тәбрик итәсебез килә:

«Татарстан халкына лаеклы хезмәт итүегез өчен рәхмәт Сезгә!»

Сәламәт булыгыз!

«ТАТАРСТАН»ның 85 ЕЛЛЫГЫН – ПРЕЗИДЕНТ БЕЛӘН

Нияз Әхмәдуллин,
2000–2021 елларда «Татарстан» журналының баш мөхәррир урынбасары

– 2005 елның салкын декабрь көне. «Татарстан» журналы редакциясенең бөтен коллективы иртәнге җидедән үк эш урыннарында. Инде һәркем бу вакыйгага әзер кебек иде, ә шулай да берәр нәрсәне онытып җибәргән булсалар, күрми калсалар?! Мондый дулкынлану юктан гына түгел: басманың 85 еллыгы уңаеннан үз тарихында беренче тапкыр журнал Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевне кабул итәргә әзерләнә. Ул чор өчен, хәер, хәзерге заман өчен дә һич күрелмәгән вакыйга. Журналлардан иң беренче булып, без республиканың иң югары вазыйфаи затын кабул итәбез!

Шулай итеп, иртәнге унда һәркем үз урынында. Берничә минуттан Минтимер Шәймиев килеп тә җитте һәм лифтта редакциябезгә менде. Коридорның ике ягы буйлап журналның төрле еллардагы тышлыклары эленгән, монда татар басмасы да, шактый озакка сузылган тәнәфестән соң 2001 елда гына кабат басыла башлаган русчасы да бар. Бу эшне оештыруны миңа йөкләделәр, әмма барыбыз да тырыштык. Хәзер без хезмәтебезнең нәтиҗәсен беләчәкбез. Шәймиевнең сүзеннән аңлашылганча, безне котларга килү турында карарны ул очраклы гына кабул итмәгән, журналны укып бара һәм югары бәяли икән. Кайчандыр аның тарафыннан әйтелгән «Татарстан» журналы – ул республиканың визит карточкасы» дигән сүзләрнең нигезе бар иде. Менә ул республикадагы бер зур предприятие директорының фотосурәте төшерелгән тышлык янында тукталды. Сурәттә – затлы мыеклы күркәм ир-ат. «Менә бу фотография ичмасам! Профессионал төшергәнлеге шунда ук күренә. Нинди фактура! Нинди җете төсләр! Кем фотосы бу?» – дип сорады ул баш мөхәррир Рифат Фәттаховтан. «Безнең фотограф Солтан Исхаковныкы», – дип җавап бирде җитәкче. «Козловскийга (Шәймиевнең шәхси фотографы – авт.) күрсәтергә кирәк, өйрәнсен», – диде Минтимер Шәрип улы. Шул мизгелдә карашларның барысы да Миша Козловскийга төбәлде. Ә фотограф елмая гына иде.

Ул вакытта типография директоры Ислам Әхмәтҗановка да беразэлкте. «Иртән газета тотасың икән, – диде Шәймиев, – соңыннан кулдагы кара буяуны бетерү өчен бик озаклап юарга туры килә...» «Минтимер Шәрипович, без инде җиһазларны алыштырдык, хәзер андый нәрсә юк», – дип акланырга ашыкты Ислам Әхмәтҗанов.

Шәймиев түргәрәк узып, редакциянең барлык кабинетларын карап чыкты. Минем шкафта Муса Җәлил бюстын күреп, аның кем эше булуы белән кызыксынды. Мин теләсә нинди сорауга әзер идем, әмма моңа гына түгел. Без шунда ук бюстны карап, җавап та бирдек. «Әйе, – дип уйладым мин ул чакта, – ничек кенә әзерләнсәң дә, бөтен нәрсәне алдан күреп булмый икән».

Редакция коллективы белән танышканнан соң, барлык иҗади хезмәткәрләр катнашында Минтимер Шәрип улы белән гомуми әңгәмә оештырылды. Анда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү нәтиҗәләре, алга таба нинди зур проектлар булачагы, федератив мөнәсәбәтләрнең перспективалары, Мәскәү һәм Казан арасында вәкаләтләрне бүлешү турында шартнамә, татар телен үстерү перспективалары, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр турында сорадылар. Минтимер Шәймиев җентекләп уйлап, нигезле җаваплар бирде. Без әңгәмәнең уңышлы баруына чын күңелдән шатландык! Минтимер Шәрипович җитди мәсьәләләр турында фикер алышканда берникадәр җиңеллек кертеп җибәрә белә. Шулкадәр мәшгуль була торып, кайчан укырга өлгерүе турында сөйләгәндә, Шәймиев журналларны кич белән караштыруын әйтте, шул вакытта текстка кереп китеп, тыныч кына укырга, уйларга, бизәлешен карарга була. Ул кинәт сүзен бүлеп, миңа карады да: «Син дә шулай эшлисеңме?» – дип кырыс кына сорап куйды. Тик бу юлы инде югалып калмадым: «Әйе, Минтимер Шәрипович, шулай эшлим». Шәймиев елмайды да сүзен дәвам итте.

Төп-төгәл кырык биш минуттан соң Президент алдында торган кассеталы ике диктофон да (ул вакытта хәзерге кебек цифрлылары юк), шыртлаган тавыш чыгарып, сүнеп китте. Тасмалар тулды дигән сүз иде бу. Мин баш мөхәрриргә күз ташладым, ул да бу хәлне аңлап, диктофоннарның берсен кулында боргалады да, аптырап, кире урынына куйды. Минтимер Шәймиевнең мыек очы да селкенмәде – ул әңгәмәне дәвам итте. Мин мөхәррирргә карыйм, аның кассеталарны кирегә әйләндереп, диктофоннар кабызуын көтәм, ә ул исә карашын миңа төбәгән. «Күрәсең, ничек кабызырга икәнен белми, – дигән уй сызып үтте. – Нишләргә? Куелган тәртипне бозып, үземә торып басаргамы? Нинди көн булды бу!..» Ниһаять, Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе Айрат Зариповның карашын күреп алдым. «Бар, хәлне җайла», – дип ымлый иде ул. Шуннан соң торып басып, Минтимер Шәймиев иңбашы аша диктофоннарга үрелергә һәм аларга җан кертеп җибәрергә туры килде.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

Алга таба барысы да үз җаена барды. Соңыннан Шәймиев баш мөхәррирнең, реклама бирүчеләр, рус телендәге басмага өстенлек биреп, татарчасына килергә бик атлыгып тормыйлар, дигән сүзләренә кырыс кына җавап бирде. Бу очракта татар басмасының язмышына куркыныч янарга мөмкин, дип зарланган иде баш мөхәррир. «Без монда татар журналын ябу өчен җыелдыкмы әллә?» – дип сорады Минтимер Шәймиев, редакция коллективына сынаулы караш ташлап. Әлбәттә, һичкем дәшмәде. «Бу хакта сүз дә булырга тиеш түгел, – диде Президент. – Без моның өчен эшләмибез. Дөрес баланс табарга кирәк. Бездә күпмилләтле халык. Иң зур күпчелеге – руслар һәм татарлар. Журнал шуларга эшләргә тиеш. Бу көнгә кадәр сез моны башкарып килдегез, алга таба да булдырачаксыз. Барысы да уңышлы булыр дип ышанам». Сүз ахырында Минтимер Шәймиев журналның профессиональ югарылыкта булуына, иҗтимагый-сәяси материалларның сыйфатына, бай бизәлешенә игътибар юнәлтте.

Әңгәмәне күтәренке кәефтә тәмамладык. Шәймиевнең журнал турындагы яхшы сүзләре илһамландырды, эшебезнең кадерен белүләрен, аның хөрмәт ителүен һәрберебез тойдык.

Минтимер Шәрип улы әлеге сәфәреннән соң журналның проблемалары турында онытмады. Декабрь ахырында редакция Президенттан яңа техника һәм компьютерлар рәвешендә шәп ярдәмне кабул итеп алды. Ә бу салкын декабрь көне, журналның 85 еллыгын билгеләп үткән, үзебезне шундый яшь, шундый дәртле итеп тойган чак, бөтен коллективның хәтеренә уелып калды. Алда безне матур мизгелләр генә көтә иде...

– ХАТЫН-КЫЗНЫҢ БЕРӘР КАЙЧАН ПРЕЗИДЕНТ БУЛУ ИХТИМАЛЫ БАРМЫ? – АЛЛА САКЛАСЫН!

Диләрә Байчурина,
«Окно» галереясын гамәлгә куючыларның берсе. «Татарстан» журналы белән 2009–2012 елларда җитәкчелек итә.

– «Татарстан»га кадәр минем нәширлек өлкәсендә тәҗрибәм зур иде, редакциядә исә журналистлык тәҗрибәсе барлыкка килде. Көчле команда, кызыклы эш, журналны тулысынча үзгәртеп кору, версткадан башлап эшкә карашка кадәр – һәрнәрсәне яңарту...

«Татарстан» редакциясендә эшемне аерым бер җылылык белән искә алам. Чөнки журналның бер колумнисты Минтимер Шәрип улы Шәймиев үзе иде.

Искиткеч оешкан кеше ул! «Ә икенче номерга нәрсә язарбыз?», «Нинди тема булачак?», «Кайчан тапшырырга?»... – дип гел сораштырып тора. Үз материалын, кирәк очракта, һәрвакыт үз кулы белән кыскарта, үзе төзәтмәләр кертә. Һәм язмасын һәрчак вакытында тапшыра. Өлгермәүне сылтау итеп, эшне сузган, соңарткан күп кенә журналистлар өчен үрнәк булып торды ул. Аңа моның өчен рәхмәт! Президент үрнәгеннән илһамланып, өлгермәүчеләр барысы да тиз арада үзгәрә алды һәм текстларын вакытында тапшыра башлады.

Командабызга колумнист Шәймиев өстәлер алдыннан гына, аның белән беренче әңгәмәбез узды. Аның янына без Юрий Прокопьевич Алаев белән бергә киттек. Бу Татарстан АССР оешуга 90 ел тулу алдыннан булды. Татарстанның беренче Президенты республиканың үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турындагы фикерләре белән уртаклашты. Минтимер Шәрип улы – бик кызыклы әңгәмәдәш, без бөтен дөнья турында сөйләштек һәм сөйләшеп туя алмадык. Ул вакытта бөтен интервьюны бизәп торган җөмләләре әле дә исемдә: «Татарстанда олигархлар булмады һәм хәзер дә юк, үзебезнекеләр дә, читтән килгәннәре дә юк»; яки менә бу: «Иң мөһиме, тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын яхшырту өчен көрәшкән чакта, без нормаль эшләп торган нәрсәне беркайчан да җимермәдек һәм гражданнарны беркайчан да мөселманга, христианга, яһүдкә, беренче-икенче сортлыга аермадык. Кадрларны да, сүз уңаеннан, сакладык һәм үстердек»...

: сәясәт : яңарыш
БЕЗНЕҢ МОНДА
ДА ҺӘР ҖӘҺӘТТӘН АЛДА
БУЛУЫБЫЗГА ШИГЕМ ЮК!

34 — татарстан / июль / 2010

Хәтерлим әле, ул чакта сүз ахырында мин Татарстанның беренче Президентына: «Хатын-кызның президент булу ихтималы бармы?» – дип сорау бирдем. Журнал өчен түгел, ә үзем өчен генә сорадым. «Алла сакласын!» – дип көлеп җибәрде ул. Аннары инде җитдиләнеп: «Хатын-кызның язмыш тарафыннан билгеләнгән югары вазыйфалары бар: йорт, гаилә, балалар», – дип өстәде. Ә аннары бакчага керде дә миңа түтәлдән лалә чәчәкләре җыеп бирде.

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ БЕЛӘН ИНТЕРВЬЮ – ҺӘРВАКЫТ ИХЛАС ӘҢГӘМӘ УЛ

Ринат Билалов,
«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы баш мөхәррире

– Зур булмаган беренче интервьюны мин Шәймиевтән 90 нчы еллар башында Чаллыда алдым. Әле бөтенләй яшь, эшли генә башлаган журналист идем. Минтимер Шәрип улы ул вакытта Чаллыга килгән иде, шәһәрдә төрле объектларны карап йөрде, шул исәптән күптән түгел төзелгән «Тәүбә» мәчетендә дә булды. Бу вакытта мәчет шәһәр өчен бик мөһим объект иде. Мин шунда Президент янына килеп, хис-кичерешләре белән уртаклашуын сорадым. Ул чакта яшьләр басмасы вәкиле булганлыктан, Чаллы яшьләре өчен теләкләрен җиткерүен һәм автограф бирүен үтендем. Ул хис-кичерешләрен дә сөйләде, теләкләрен дә әйтте, имзасын да салды, редакциягә бик канәгать булып кайттым.

Соңрак, журналистлар коллективы җитәкчесе сыйфатында, мин үзебезнең басмадагы хезмәттәшләрем белән аннан ике тапкыр интервью алдым. Әңгәмәдәш буларак, аңа тиңнәр юк. Гадәттә, интервью ничек була? Син – журналист, әңгәмәне үзең көйлисең, үзең алып барасың – сораулар бирәсең, ниндидер төгәллек керттерәсең, әңгәмәдәшеңне ул тулы итеп җавап бирмәгән сорауга кире кайтарасың... Тик Шәймиев белән сөйләшкәндә, ул инициативаны үз кулына ала дигән хис туа. Һәм, асылда, хәтта интервью да түгел, ә үзара гәпләшү, әңгәмә килеп чыга. Бу әңгәмә шулкадәр мавыктырып алып кереп китә ки, алдан бирелгән вакыт кысаларына ул һичкайчан сыешмый. Вакыт узганын сизмисең дә, чөнки кызык. Сөйләшү барышында әңгәмәнең күпкатлы, күпкырлы рәвеш алуы истә калды. Ягъни ниндидер бер темага кагылган сорауга җавап шулкадәр күпкатлы була ки, аннан үзеннән-үзе икенче сорау килеп чыга, башка темалар формалаша.

Минтимер Шәрип улы – журналист өчен шактый катлаулы, әмма бик кызыклы әңгәмәдәш. Мондый күпкырлы, укымышлы, зирәк кеше белән интервью – әлбәттә, журналист өчен зур уңыш ул. Бу әңгәмә бик озакка хәтергә сеңеп кала, ул цитаталарга аерылып еш искә алына, аның белән гомер буе горурланасың.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

2012 ел. Автор фотосы.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

«БЕР КҮРҮДӘ ГАШЫЙК БУЛУ» ТУРЫНДА



Әскәр Сабиров,
«Татарстан» журналының шеф-редакторы

– Бүгенгедәй хәтеремдә: узган гасырның 90 нчы елларында безнең редакция («Аргументы и факты» Регион») Минтимер Шәрип улыннан курка-курка гына газетада бастыру өчен җәмгатенең фотосурәтен сорарга җөрьәт итте, ике сорауга җавап бирүен дә үтенде: яраткан Сәкинәсе белән ничек танышканнар һәм алар гомерендә иң бәхетле көн нинди булган. Ул заманда хәтта уртакул түрәләрнең дә шәхси тормышы җиде йозак белән бикләнгән иде, ә без Президент кадәр Президентның мәхәббәт тарихын белмәкче булабыз!..

Мин, безгә Шәймиевнең матбугат хезмәте җавап бирер, анда безне кызыксындырган мәгълүмат бик аз булыр, дип өметләндем. Икенче көнне безнең ничек гаҗәпләнгәнне күз алдыгызга да китерә алмассыз хәзер – Сәкинә ханымның фотосы редакциягә килеп тә җитте, арткы ягына исә Шәймиевнең үз кулы белән хатыны турында наз тулы сүзләр язылган иде. Сөйгәне белән клубта биюләр вакытында танышуы, «бер күрүдә гашыйк булуы» хакында, ихтимал, нәкъ менә шул чакта Минтимер Шәймиев беренче тапкыр сөйләгәндер. Һәм иң бәхетле көннәре – өйләнешкәннән соң «ак пароходта» туй сәяхәтенә китеп барулары турында да җылы хатирәләрен барлаган иде ул...

Минемчә, һәркемнең, хәтта сәяси көндәшләренең дә беренче Президентка шундый дустанә мөнәсәбәттә булуы, аның кеше күңеленә хуш килүе менә бу очрактан аңлашыладыр кебек тоела. Шәймиев беркайчан да үзенең ихлас хисләрен чиновник мундиры артына яшерми. Һәм аңа үзен «зур түрәләрчә» тоту стереотибы бөтенләй хас түгел. Моннан егерме биш ел элек, 1997 елның 20 гыйнварында, мин моңа тагын бер кат инандым.

Бу Минтимер Шәрип улына 60 яшь тулган көн иде, һәм мин дә тантанага шәхсән ул үзе чакырган кунаклар арасына эләктем. Аппарат иерархиясе буенча гади журналистка дәрәҗәле сәясәтчеләр, хәрби һәм нефть генераллары белән бер табында утыру бәлки рөхсәт тә ителмәгәндер (минем янәшәмдә, мәсәлән, Анатолий Чубайс утырды). Һәм минем кебекләр, исемсез һәм статуссыз гади кешеләр, биредә бармак белән генә санарлык түгел, байтак иде...

Банкет юбилейга килгән кунакларга бүләк бирү белән тәгәлләнде. Чакырылган һәркемгә – бу исә берничә йөз кеше иде – Минтимер Шәрип улы истәлеккә тиңдәшсез фотоальбом бүләк итте. Анда һәр кунакка тантанасына килгән өчен рәхмәт сүзләре язылган иде...

Бу альбом да, Сәкинә ханымның Минтимер Шәймиев сүзләре язылган фотосурәте дә – минем өчен иң кадерле раритетлардан берсе. Т

Фото: Михаил Козловский

ШӘЙМИЕВНЕҢ КИЛҮЕ БУЛДЫ – КӘЕФЕМ ШУНДУК КҮТӘРЕЛДЕ

Ната Смирнова,
«Татарстан» журналы фотографы

– Әлбәттә инде, миңа Минтимер Шәймиевне төрле чараларда еш фотога төшерергә туры килә иде – эшем шул бит. Әмма бу һәрвакыт бер төркем коллега-журналистлар арасында була – янәшәдәге камералар, терсәк-җилкәләрдән сакланып кына өлгер – һәркемгә уңышлы кадр кирәк... Ә менә тынычрак шартларда бер-ике тапкыр гына очрашырга туры килде.

Миңа бигрәк тә Зөядәге очрашу ошады. Бу 2012 елның октябрендә булды, мин космонавт Сергей Крикалёвның Зөядә йөрүен төшерәм, «Татмедиа» биремен үтим... Без тулы бер делегация белән йөрибез, ракурслар сайлыйбыз, төшерәбез... Һәм бөтенләй очраклы рәвештә икенче бер делегация белән очрашабыз – Минтимер Шәймиев үзенә кунакка килгән ниндидер французларга Зөя утрау-шәһәрен күрсәтә икән. Ул космонавтны танып ала, Крикалёв исә аны таный, барысы да куанышып сәламләшәләр, берберсе белән таныштыралар. Һәм мин боларның барысын да Шәймиевнең кочагында диярлек күзәтәм... Чөнки мин төркемнәребез очрашканда иң алда тора идем. Ул мине күптәнге танышын күргәндәй, аталарча кочып алды – һәм бу шулкадәр шәп иде, әмма, кызганычка, әлеге гүзәл мизгелне фотога төшерә алмый калдым. Саубуллашкан чакларында гына берничә кадр ясарга өлгердем...

Икенче тапкыр без 2018 елда Кремльдә очраштык. Журналның баш мөхәррире белән 8 Март алдыннан Минтимер Шәрип улыннан интервью алырга килдек. Миңа джинс чалбардан булуым өчен бераз әләкте, кәефем төште – икенче бер очрашудан йөгереп килеп җитеп, кием алыштырырга өлгермәгән идем шул... Әмма шул чакта Шәймиев килеп керде, барыбыз белән дә ихластан исәнләште, барыбызга да елмайды, минем джинс чалбарыма игътибар да итмәде. Кәефем шундук күтәрелде. Без озак, мавыгып эшләдек. Фотосурәтләр күп булды, беркем дә комачауламаганга, төрле ракурслардан төшердем. Иң уңышлысы, караган саен кәефне күтәрә торганы журнал тышлыгында чыкты. «Тимер» кешенең яраткан хатын-кызлары» хакында сөйли торган шул сан – минем иң яраткан журналым.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

Фото: Ната Смирнова

МЕҢ ДӘ БЕР СӘЛӘТКӘ ИЯ ҖИТӘКЧЕ

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Күренекле сәясәтче, оста стратег, бик сирәкләргә генә бирелә торган идарәче сәләтенә, сизгерлеккә, кыюлыкка ия шәхес һәм җитәкче. Шәймиевнең шәхси сыйфатларын бик озак санарга була – аның сәләтле яклары бихисап. Әмма, мөгаен, аларның иң мөһиме – үзенең көчле якларыңны республика файдасына, кешеләр мәнфәгатенә куллану омтылышыдыр.

– Бүген Минтимер Шәймиевнең бу сәләте нәтиҗәсендә республикада әллә ничә тармак уңышлы эшли. Энергетика – шулардан берсе. Бу уңайдан 1999 ел искә төшә. Россия тарихында иң авыр икътисадый кризис чорларының берсе иде. «Татэнерго» ширкәтенә яңа команда килә. Бу вакытка хезмәткәрләрнең инде җиде айдан артык эш хакы күргәне булмый. Ул чакта нигездә Минтимер Шәриповичның тиңсез ярдәме аркасында предприятиене аякка бастыруга ирешәләр. Хәтта бүген без эшли торган бина да ширкәткә аның тәкъдиме белән әләгә. Әмма иң мөһиме – энергетика хуҗалыгы республика милкендә кала. Һәм моны мин Шәймиевнең казанышы дип турыдан әйтә алам.

ПОРТРЕТКА ӨСТӘМӘЛӘР

Бервакыт, туксанынчы елларда, әле Чаллының вице-мэры булган чакта, мин Минтимер Шәрипович үткәргән бер киңәшмәгә эләктем. Иң кызу вакыт – урып-җыю чоры иде. Комбайннар җитми, эш темпы түбән... Һәм кинәт ЮХИДИ вәкиле торып басты да зарлана башлады. Янәсе, авыл хуҗалыгы техникасы автомобиль хәрәкәтенә комачаулый, комбайннарны басудан басуга күчергәндә, кайчагында хәтта махсус билгеләр дә куймыйлар. Вакыт-вакыт бу эш хәтта төнлә дә башкарыла – Дәүләт автоинспекциясе өчен менә кайда төп проблема! Минтимер Шәрипович аны игътибар белән тыңлады да: «Әйе, андый проблема бар – юлларда машиналар артык күп. Һәм бу... комбайннарга комачаулый! Сезнең бурыч: берниндИ юл-транспорт һәлакәте дә булырга тиеш түгел!» – диде. Бу аның вазгыятькә бәйле искиткеч тиз җавабы булды, вак-төякне мөһим нәрсәдән аера белү кебек шаккаткыч сәләте менә шундый чакларда күренә иде. Әйе, икмәк кешелек өчен һәрнәрсәдән кыйммәтрәк. Минтимер Шәймиев – җир кешесе, җирне ярата. Берәү дә туган якны, туган туфракны аның кебек яратмыйдыр. Аның барлык эш-гамәлләре мәхәббәт белән сугарылган. Һәм ул безне дә шуңа өйрәтте.

Башка бер вакыйганы искә төшерәсем килә – Шәймиев портретына тагын бер матур штрих. Югары урында утыручы бер түрә аның белән сөйләшкәндә: «Барысын да эшләрбез, Минтимер Шәрипович!» – дип вәгъдә бирә. Һәм: «Безгә комачауламасыннар гына», – дип өстәп куя. Минтимер Шәймиев, көлемсерәп: «Комачауламасыннармы? Теләгең артык зур икән!» – ди. Әмма ул шуны һәркемнән дә яхшырак аңлый: синә берничек тә комачауламый торган эш була алмый. Әгәр син дөньяны үзгәртергә омтыласың, нииндидер мөһим нәрсә эшлисең икән, юлыңа аркылы басачак кешеләр, шартлар һәрвакыт табылачак. Әйберләрнең, мәсьәләнең асылын һәрберебезгә шаярту аша аңлатып, күрсәтеп бирә белүе – Шәймиевнең тагын бер сәләте.

Сүз уңаеннан, юмор еш кына аның башка сыйфатын яшереп тора иде – чынлыкта, ул кырыс җитәкче булды. Аның янына киңәшмәгә имтиханга барган кебек бара идек. Ул теләсә нинди сорау бирергә мөмкин, ә син аңа җавап бирергә тиеш. Әмма шуңа да карамастан, кешеләр аңа тартылды һәм хәзер дә тартыла. Минтимер Шәриповичның табигый мөлаемлыгы төп сәбәпче дип уйлыйм. Өстәвенә, ул – бик тирән эчке культурага ия кеше дә.

КЫЮ РӘВЕШТӘ КИЛӘЧӘККӘ КАРАУ

Минтимер Шәймиевнең тагын бер таланты – алдан күрә белү. Моңа әле батырлык та өстәлә. Минтимер Шәрип улы иң катлаулы карарларны кабул итүдән беркайчан да курыкмады. Ә аннары – алар өчен җавап та тота белде. Ил икътисады өчен бик катлаулы вакытта, башкалар зарланып, ярдәм сораганда, ул алга искиткеч зур бурычлар куйды. Ул чакта республикада күпме яңа программа эшли башлады һәм алар барысы да уңышлы адым булып чыкты. Мисаллармы? Алар бик күп! Авылларны газлаштыру программасы, тузган торакны бетерү, социаль ипотека программасы, ә 1996 елда Казан метрополитенын төзи башлау нәрсә? Хәтерлисезме, «Китсәнә! Нинди метро?» кебек сүзләрне бик күпләрдән ишетә идек. Тик ул, әйтерсең, безнең бүгенге транспорт коллапсын шул чакта ук күз алдында тоткан. Әлбәттә, киләчәкне алдан күреп эшли белү – күпмедер дәрәҗәдә илаһи бүләк ул.

Минемчә, соңгы унъеллыктагы иң колачлы социаль проектларның берсе – күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү программасы. Аны әзерләүдә һәм тормышка ашыруда катнаша алуым белән бәхетлемен. Мин ул вакытта республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Шакирҗан улы Хөснуллинның беренче урынбасары вазыйфасын башкара идем. Россиянең яңа Торак кодексы үз көченә кергәч бәйле рәвештә шактый катлаулы мәсьәлә калкып чыкканын хәтерлим: күпфатирлы йортларның торышы өчен җаваплылык милек хуҗалары җилкәсенә авыр йөк булып төште. Халык мондый финанс йөген күтәрә алмады. Шулкадәр күп акча кирәк – бу мәсьәләне республика һәм җирле бюджетлар ярдәме белән генә хәл итеп булмый иде. Ул чакта Минтимер Шәрипович гаҗәп әһәмиятле адым ясады. Ул Россия Президенты Владимир Путинга РФ Дәүләт Советы Президиумының торак-коммуналь хуҗалык проблемаларына багышланган күчмә утырышын Казанда үткәрергә, бер уңайдан «Россия гражданнарына – һәркем алырлык һәм уңайлы торак» милли проектын гамәлгә ашыру турында фикер алышырга тәкъдим итте. Киңәшмәне уздыру вакыты да – 2007 елның гыйнвары – очраклы гына сайланмаган иде. Шул рәвешле үзенең юбилеен Минтимер Шәрипович мөһим стратегик мәсьәләне хәл итү өчен куллана алды. Ул вакытта Татарстан башкаласына иң күренекле сәясәтчеләр һәм икътисадчылар килде, һәм Минтимер Шәймиев йортларны капиталь төзекләндерү юнәлешендә яңа федераль программаны эшләтеп җибәрү зарурлыгына ышандыра алды. Безнең республиканың бу проект өчен пилот төбәк итеп сайлануы гаҗәп түгел. Без аны беренче булып эшләтеп карадык – шул рәвешле бихисап сандагы татарстанлы торак шартларын яхшыртты, су үтә торган түбәләр һәм су баскан подваллар проблемасын хәл итте. Һәм болар барысы да – Минтимер Шәймиевнең тагын бер таланты – аның стратегик фикерләве, башкаларны күндерә һәм алга таба бөтен ил күләмендә файдаланырлык карарлар тәкъдим итә белү сәләте бәрабәренә! Мондый кеше белән эшләү һәм аның берсеннән-берсе зуррак проектларын тормышка ашыруда катнашу бәхете миңа да насыйп булган өчен, язмышыма рәхмәтлемен.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

ЧОР ФОНЫНДАГЫ ПОРТРЕТ

Тәлгать Абдуллин,
«Связьинвестнефтехим» АҖ генераль директорының төзелеш секторы мәсьәләләре буенча урынбасары

Хәзерге вакытта Татарстанда безне горурландырган бар нәрсә – зур предприятиеләр, заманча торак комплекслары, мәдәни мирас объектлары, матур парклар – республиканың беренче Президентындагы сәяси талант, ихтыяр көче һәм үз халкына мәхәббәттән башка була да алмас иде.

– Советлар Союзы таркалган чорда җәмгыятьне тотып торган бөтен нәрсә – идеология, сәяси система, икътисад җимерелә башлады. Аларның кайсыдыр яңа шартларда яши алмый иде, кайсыдыр максатчан рәвештә юкка чыгарылды. Төбәк җитәкчесе өчен бу шактый катлаулы, хәтта куркыныч та хәл иде. Әмма Минтимер Шәймиев чигенмәде. 1990 елда ул ТАССР Югары Советы рәисе итеп сайланды һәм ул чакта ук Татарстанда хакимият институтларын формалаштыра башлады. Республиканың яңа Конституциясен, яңа закон проектларын булдыру юнәлешендә эш кузгалды.

БЕРЕНЧЕ БУЛУ КЫЕН

– Мин «Татарстан» төркемен җитәкләдем. Татарстан Югары Советында без күпчелек идек. Без Конституциядән кала теләсә нинди законны кабул иттерә ала идек, чөнки Төп Закон өчен барлык депутатларның кимендә өчтән икесе хуплап тавыш бирү кирәк. Документның һәр бәхәсле пунктын тикшерү өчен, Минтимер Шәрипович Югары Совет Президиумы һәм Министрлар Советы вәкилләрен, депутат төркемнәре җитәкчеләрен җыя, һәм без, республика файдасына эшләрлек карар кабул ителгәнче, һәр пункт турында фикер алыша идек, – дип сөйли Тәлгать Абдуллин. 1992 елда Татарстан Республикасы Конституциясе кабул ителә. Аны үтәргә, анык мәсьәләләрне, беренче чиратта икътисадны коруга кагылышлыларын, хәл итәргә кирәк була. СССРда планнар һәм финанслау ил җитәкчелеге тарафыннан раслана. Яңа шартларда исә республикалар Дәүләт планы, Дәүләт тәэминаты, Дәүләт бәя комитеты һ.б. оешмаларның эшен алыштыра алмый. Моннан тыш, үзәк тарафыннан предприятиеләр өчен хуҗалык кооперациясе кагыйдәләре дә билгеләнмәгән була. Бу шартларда барлык төбәкләрдә диярлек җитештерү күләме кими, мөһим предприятиеләрне кулга төшерү һәм талау очраклары күзәтелә. Моңа Үзәк банкның елына 200–240 процентлы кредит бирү сәясәте дә этәргеч була. Заводларның табышы бу процентларны капламый. Предприятиеләр өлешләп яки тулысынча сатыла башлый, еш кына төрле кара көчләрнең көндәшлегә корбанына әйләнеп бөтенләй бушка диярлек сатып җибәрелә. Икътисад таркалу белән бергә эш урыннары да кими, башка социаль һәм икътисадый бәлаләр дә баш калкыта.

– Бу авыр хасталарга дару сыйфатында, мин Минтимер Шәриповичка, Татарстандагы эре предприятиеләрнең производство капиталын саклап калу һәм аларның мөстәкыйль үсешкә сәләтен торгызу максатыннан, җитештерүчеләргә икътисадый ярдәм күрсәтү өчен, бу предприятиеләрнең дә өлеше булган банк төзергә тәкъдим иттем, – дип сөйли Тәлгать Абдуллин.

Мондый тәкъдим, чынлыкта, күптән корылган системага таяк ыргыту дигән сүз. Ул вакытта Үзәк банк бик җитди структура, элеккеге СССР икътисадының кан тамырлары системасы һәм йөрәге була. Республикада аның бүлекчәсе – бюджет түләүләре белән мәшгуль Татарстан Милли банкы эшли. Һәм кинәт – аның көндәшен булдырыргамы? Әмма Шәймиев Абдуллинның тәкъдименә зур игътибар күрсәтә. Нәтиҗәдә, 1993 елда Татарстанның коммерция банкы – «Ак Барс» банкы ачыла. Тәлгать Абдуллин җитәкчелегендә банк үсә башлый, әмма республикадагы кризис җилләрен басу өчен, аның ресурслары җитәрлек булмый.

– Республикада акча җитмәү генә түгел, юк иде ул. Мин янә Минтимер Шәриповичка бардым да, уңышлылыгы шактый шикле тәкъдимемне җиткердем: «Ак Барс» банкының вексельләрен, ягъни бурыч йөкләмәләрен белдергән кыйммәтле кәгазьләрен чыгарырга. Предприятиеләр аларны үзара һәм республика белән исәп-хисап өчен файдалана алыр иде, дидем. Ахыр чиктә сүз банкның түләү сәләте генә түгел, ә проектның инициаторы һәм вексельләрнең капланылачагына төп гарант булган Татарстан Президентының абруе турында да бара иде, – ди Тәлгать Абдуллин. – Минтимер Шәрипович минем планны хуплады. Мин республика предприятиеләренең баштанаяк бурычка батуына өмет итүчеләр тарафыннан каршылыкны алдан чамаладым. Алар «Вечерняя Казань» газетасында минем белән әңгәмәне укыячакларын белеп, вексельләр проектының – куәтле паровоз икәнен, аның каршында рельсларга яту урынсызлыгын әйттем.

Бу чагыштыруны Минтимер Шәрипович ошата. «Бу безнең паровоз. Артка юл юк. Ермак тар, әмма без тартып барырбыз», – ди Минтимер Шәймиев министрлар һәм Милли банк вәкилләре белән йомгаклау киңәшмәсендә. Тиздән вексельләр әйләнешкә чыга һәм тагын берничә ел республикада һәм аннан читтә исәп-хисап өчен файдаланыла.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН ТРАМПЛИН

– Яңа закон актын яки программаны кабул иткәндә, Минтимер Шәймиев әлеге тәкъдим авторына: «Моннан кемгә яхшы булачак?» – дип сорау бирә иде. Әгәр җавап «халыкка түгел» рәвешендә булса, карар кабул ителми. Башта мин моны Шәймиев ягыннан үзенә күрә бер сәя-

си адым дип уйладым. Аннары моның хакимлек теләге белән түгел, ә кешеләр арасында, кешеләр өчен иң яхшы яшәү ысулын табу теләге белән бәйле булуын аңладым, – ди Тәлгать Абдуллин.
1990 елда Казанда, шулай ук Татарстанның башка шәһәрләрендә һәм зур бистәләрендә торак фонды белән хәл коточкыч дип әйтерлек дәрәҗәдә була. Россия бюджетында исә тузган торакны бетерүгә акча юк. Ул чакта Минтимер Шәймиев нефтьчеләрне, химикларны, шинчыларны, әле ничек тә җан асрарга маташкан барлык предприятие вәкилләрен җыя да әлеге проблема турында сөйләп бирә. Торакны предприятиеләр акчасына төзергә тәкъдим итә ул. «Эшлибезме моны?» «Әйе, эшлибез», – дип җавап бирә киңәшмәгә җыелучылар. «Ул чакта, әйдәгез, түләгез», – ди Шәймиев. Шулай итеп, 1995 елда Татарстанның үз «салым»ы барлыкка килә – сатылган продукциянең 1%ы күләмендә акчалар тузган торакны бетерү фондына күчерелә башлый.
– Бервакыт, мин инде Татарстан Дәүләт торак фондының башкарма директоры булганда, Минтимер Шәрипович үзенә чакырды да, кызыксындыру өчен, предприятие һәм район җитәкчеләренә алар күчергән акчаларга нәрсә төзүебезне күрсәтергә кирәклеген әйтте. Очрашу алдыннан ул әлеге проектта кемнәрнең бурычлылар исемлегендә йөрүе белән кызыксынды. Түбән Кама Нефть химиясе заводы һәм шин заводы, дип җавап бирдем. Химия заводында акча җибәрмәгәнлекләрен әйттеләр, ә шинчылар исә, акча күчердек, диде. Әмма бу акчалар фондка килмәде, – дип сөйли Тәлгать Абдуллин.
Чакырылган җитәкчеләр Казанга җыела. Алар арасында химия заводы директоры да була. Башкалар кебек үк, ул да Минтимер Шәрипович белән исәнләшергә тели. «Син ничек килеп эләктең монда? Без килештек бит, ә син эшләмәдең, ә үзең күрешергә кул сузасың. Син монда нинди намус белән килдең? – ди аңа Минтимер Шәймиев. – Арканы соңгы тапкыр күрүем булсын!» Ике көннән химия заводы директорын Акционерлар советы эштән җибәрә.
Соңрак, федераль үзәкнең көчле басымы астында, республика салым системасын Россиянеке белән яраштыру өчен, бу салымны гамәлдән чыгарырга туры килә. Алга таба да торак төзү мәсьәләсе күтәрелә. Фатир алучыларның исемлеге берничә елга алдан төзеп куелган була, кешеләр көтә. Программаның дәвам иттерелүен яклап, ул вакытта әле Татарстан Премьер-министры булган Рөстәм Миңнеханов та, Тәлгать Абдуллин да чыгыш ясый. Минтимер Шәймиев алар белән килешә. Фондка кертемнәрне ирекле дип игълан итәргә карар кылына. Социаль ипотека, авыл халкы, ятим балалар һәм яклауга мохтаҗ башка категория гражданнар өчен торак төзү программасы башланып китә.
– Без районнарга, шәһәрләргә барып, җитәкчеләргә шуны аңлатырга тырыштык: үзләре фатирлар төзергә һәм аларны халыкка сатарга телиләр икән, бу кешеләрне бик югары хезмәт хакы белән тәэмин итәргә, димәк, салымнарны да күбрәк түләргә туры киләчәк, – ди Тәлгать Абдуллин. – Предприятие Фондка күчергәнгә караганда күбрәк акча югалтачак. Ә без, аның каравы, төзелеш күләмен, эш урыннарын, шуңа бәйле җитештерү процессларын саклап калабыз. Без күндерә, инандыра алдык, һәм республиканың елына 1,1 млн кв. метр торак төзи башлавына ирештек, шуларның 850 мең кв. метры фонд аша төзелде. Торак йортлар гына түгел, ә әлеге программага кадәр районнарда бөтенләй булмаган белгечләр дә үсте, чөнки моңарчы андый белгечләргә ихтыяҗ юк иде. Татарстанлылар җәмгыяте һәм аларның бердәмлеге шулай төзелде һәм ныгыды.
Минтимер Шәймиев ярдәмчесе сүзләренчә, берничә ел элек, Тәлгать Абдуллин тузган торакны бетерү программасы буенча яңа фатир алган 155 мең кешенең исеме язылган «Без бергә!» китабын бүләк иткәч, ул бүлмәсендә әлеге китапны бик озак кочаклап йөргән.
Татарстан Президенты булган дәвердә Минтимер Шәрипович бик күп йөри һәм чит илләр тәҗрибәсеннән нинди проектларны гамәлгә ашырырга теләве турында даими сөйли торган була. Тик шунда ук өстәп куя: чит трамплиннан егылып төшәргә мөмкин, шуңа күрә акрынлап алга барырга кирәк. Бүген исә ачык күрәбез: республика гына түгел, бөтен ил тыныч күңел белән шуарлык трамплин төзегән ул.

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

ЕЛЛАР ҮТӘР, ТАРИХ КАЛЫР

Лотфулла Шәфигуллин,
алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе

Шәймиев кебек кешеләрне гадәттә дөнья гражданы дип атыйлар. Минтимер Шәрипович тырышлыгы нәтиҗәсендә Болгар һәм Зөя утрау-шәһәре кебек бәһасез объектлар кешелеккә кире кайтарылды. Әлеге объектлар Татарстанда яки Россиядә генә түгел, бәлки дөньякүләм тарихи брендка әйләнде. Ул – варисларыбызга Татарстан мәдәни мирасын калдырырга омтылучы олпат шәхес. Вакыт буенча сәяхәт итү өчен генә түгел, иң әүвәл халкыбызның үткәне белән горурланыр өчен кирәк бу гамәлләр.

ЙӨЗЛӘРЧӘ ЕЛДАН СОҢ

Арча районы Хәтнә авылы – искиткеч матур, гаҗәп урын. Хәзер халык аз яшәүгә карамастан, ул бай тарихлы, сихәтле сулы изге урын буларак сакланачак. Авыл тарихы дворян Перцовлар гаиләсенә бәйле. Лотфулланы бала чагында бередәге изге чишмәгә әбисе алып килә торган була. Әбиләр намаз укый, малай исә тын гына карап тора. Тикмәгә генә, балачак хатирәләре күңелдән җуелмый, димиләр бит. Берничә дистә елдан соң, студент улының андагы хәлне күреп күңеле төшеп кайткач бара ул Хәтнәгә янадан. Яшьләр, ачынып: «Лотфулла Нурисламович, бу илнең киләчәге юктыр ла ул», – диләр. Кайчандыр оҗмах почмагыдай урынның хәзер асты-өскә килгән икән. Бөтен нәрсә җимерелгән, Петр һәм Павел чиркәвендәге тәрәзәләр ватылган, коймалар аударылган, Перцовлар гаиләсе төрбәсендәге кабер ташлары да урыныннан кузгатылган – кемдер анда алтын-көмеш эзләгән, күрәсең... Шәфигуллин командасы иң беренче эш итеп төрбәне тәртипкә китерә. Православие кәшәнәсе, мөселманнарга намаз уку йорты төзеп куялар, изге чишмәне чистарталар...

КИЛӘЧӘККӘ КАЙТУ

Шуннан башлана да инде. Соңгы елларда Татарстанда дистәләрчә чишмә торгызыла. Лотфулла Нурислам улы әйтүенчә, меценатлык темасы, мәдәни-тарихи мирас объектларын торгызу проектлары – Минтимер Шәймиев башлаган игелекле эшнең дәвамы ул:

– Милләт казанышларын саклап калу темасы һәркемгә кагыла. Хәтта берәр ташландык авылдагы «ниндидер» зират турында гына сүз барса да. Дөньяда бөтен нәрсә үзара бәйләнештә, бу очракта да сүз яшь буынны тәрбияләү хакында бара.

Түбән Камада яртысы – татар, яртысы керәшенненеке булган зират ике дача кооперативы арасында калган. Күп еллар буе бакчачылар аны чүплеккә әйләндереп бетергән. Без аннан 30 машина чүп чыгардык, киртәләп куйдык. Мулла һәм попны чакыртып, дога укыттык. Панихидага килгән карчыклардан берсе бередә үзенең әтисе һәм сугыш вакытында үлгән абыйлары җирләнүе турында сөйләде: «Кайчандыр бу каберләрнең тәртипкә китереләсеннән мин өметемне өзгән идем инде», – дип елады. Моны яшьләр күреп һәм ишетеп торды. Минемчә, тәрбия менә шул инде ул...

ТАРИХ – ҺӘРВАКЫТ КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА УЛ

Габдулла Тукай – иң шәп татар шагыйрьләреннән берсе, ул иң аяныч нәрсәдә көлке таба һәм, киресенчә, комедиядә фаҗига күрә алган. Республиканың беренче Президентына да хас бу талант. Аңардан искиткеч җан җылысы һәм ихласлык бөрки. 2016 елның 26 апрелендә Яңа Кырлай авылында әдәбият-скульптуралар паркы ачылышында булган хәлне искә төшерәсе килә. Чишмә янында «Су анасы» поэмасын тыңлагач, Минтимер Шәрипович:

– Карагыз әле, нинди тирән мәгънә, нинди тәрбияви аспект бар бит монда! Чит кеше әйберенә кагылырга ярамаганны ничек оста күрсәтә Тукай! Балачакта мин курка идем хәтта: әлеге таракны мин урлап китмәдемме икән ул? Шулкадәр тормышчан сурәтләнә бит барысы да, – диде.

Шәймиев Яңа Кырлайда күргәннәренә бик куанды: «Минем мондыйны башка беркайда да күргәнем юк әле. Афәрин! Татарлар нәрсәгә тотынса да, хәлләреннән килә. Әллә никадәр кыенлыкларга карамастан, рухи яңарыш буенча шулкадәр эш эшләнүенә күңел сөенә. Кеше үткәннәр белән кызыксына, горурлана һәм балаларына да шул хисне сеңдерергә тырыша. Без дә үзебездән соң килгән буынга тапшырырлык рухи мирас калдырырга тиеш. Бу бик гади, аңлаешлы, әмма бик мөһим фәлсәфә. Шәфигуллинга бит беркем дә: «Әйдә,



менә шуны эшлә!» – дип әйтмәгән. Ул моны үз теләге белән эшләгән. Бу исә соклану уята», – диде.

Ул чакта Лотфулла Нурислам улы үзенең бу якта туып-үсүе һәм укуы, парк ясау теләгенең исә Зиннур Мансуровның «Тукай белән әңгәмәләр» китабын укыганнан соң үзеннән-үзе пәйда булуы хакында әйткән иде. Һәм бүген дә Шәфигуллин:

– Бу берниндә дә искитәрлек фикер түгел, әмма һәркем үз милләте өчен нәрсә дә булса эшләргә тиеш, дип уйлыйм. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗани. Дөнья мөселманнары өчен ул – татарлык үрнәге. Аның исемендәге мәчет манарасы, шулай ук Сөембикә манарасы да... Һичшиксез, ул бөек шәхес булган, наданлыкны җиңәрлек, мәгърифәтле яңа татар дөньясын тудырган. Ә безнең күп кенә замандашларыбыз хәтта аның кайда тууын да белми! Еллар үтәр, ә тарих калыр. Моны аңласаң, яшәү һәм чынбарлыкны аңлау да җиңелләшә, – дип ышана.

«ВАРЯГ» ДОШМАНГА БИРЕЛМИ

1904 елның апрелендә Николай II Кышкы сарайда Чемульпо каһарманнарын котлап тост әйтә. Патша сараенда бәйрәм итү легендар «Варяг» крейсеры һәм «Кореец» канонер көймәсе диңгезчеләре хөрмәтенә оештырылган була. Әлеге җәһәттән махсус савыт-саба әзерләнә, тантанадан соң алар морякларга бирелә. «Варяг» матросларының барысына да Николай II исемле сәгать һәм «Чемульпо герое» медален тапшыра. Патшаның көмеш кашыкларыннан берсе ул чакта Казан губернасының Гремячка авылына да кайта. «Варяг» матросы Сидор Александров шул авылдан була. Соңрак ул тарихи реликвияне ТАССР Дәүләт музеена тапшыра. Үзе дә бер гасырга якын яши.

– Җиде еллап элек мин Балык Бистәсе районындагы әлеге авылда булдым, – дип искә ала Лотфулла Нурислам улы. – Һәм анда легендар «Варяг» матросы каберен күреп шаккатый гаҗәпләндем.

Нәтиҗәдә 2015 елда Гремячка авылында Сидор Александров хөрмәтенә мемориаль комплекс пәйда була. Аның туган йорты ремонтлана. Бүген рус матросы каберенә варислары гына түгел, башка кешеләр дә килеп йөри...

– ХӨРМӘТЛЕ МИНТИМЕР ШӘРИПОВИЧ!

Күркәм юбилеегыз көнендә Сезгә замандашларыгызга биргән фәлсәфә һәм кешелеклелек сабакларыгыз өчен рәхмәт әйтәсем килә. Киләчәктә дә тормышыгыз игелек энергиясенә тулып торсын. Сезгә ихластан яңа кызыклы проектлар, нык сәламәтлек, җан тынычлыгы һәм гармония телим!

Реклама

СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ШӘФИГУЛЛИН КОМАНДАСЫ МЕЦЕНАТЛАРЫ КӨЧЕ БЕЛӘН ТОРГЫЗЫЛГАН ТАРИХИ ЯДКӘРЛӘРНЕ САНАП УЗЫЙК: Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында Туфан Миңнуллин музей-утары; Казанның Николай Ершов урамында Бөек Ватан сугышы элемтәчеләренә һәйкәл (үрнәге – Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов); Биектау районы Иске Казан музей-тыюлыгындагы агач ныгытма корылмалары; Арча районы Урта Курса авылында фикер иясе Габденнасыйр Курсавига истәлек тактасы; Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында Каюм Насыйрига истәлек корылмасы; Әтнә районы Ябынчы авылында Шиһабетдин Мәрҗанигә истәлек корылмасы.

ОСТАЗ...

«ТАТАРСТАН» ӨЧЕН ГЕНӘ

Вәгыйзь Минһаҗев.
«Россельхозцентр» ФДБУнең Татарстандагы филиалы директор урынбасары, ТР Дәүләт премиясе лауреаты, РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре

Һәрберебезнең нык ихтирам иткән, алай гына да түгел, язмышында хәлиткеч роль уйнаган кешеләре була. «Россельхозцентр» ФДБУнең Татарстандагы филиалы директор урынбасары Вәгыйзь Минһаҗев өчен андый кеше Минтимер Шәймиев.

ХАЛЫК ФИКЕРЕН ИШЕТҮ...

1988 ел. Вәгыйзь Васильевичны Арча районының беренче секретаре итеп сайлап куялар. Бу вакытта Минтимер Шәрипович Татарстан Министрлар Советы рәисе була. Яңа вазыйфага кадәр Вәгыйзь Минһаҗев Арча авыл хуҗалыгы бүлеге җитәкчесе була. Шул чорда Минтимер Шәрипович Арчага килеп, кырларда эш барышы, район белән таныша. Ягъни ике арада булган аралашу шул чакта ук башлана.

– Һичшиксез, районның беренче секретаре итеп билгеләнгәч, Минтимер Шәрипович белән ныграк аралаша башладык, – диде Вәгыйзь Василович. – Заманалар болгана башлаган чор. Хуҗалык мәсьәләләрендә ярдәм сорап, Министрлар Советы рәисенә бер генә мөрәҗәгать итмәдем. Алланың рәхмәте, җитәкче безнең районга карата гел хәерхаһлы булды.

1989 елның сентябрендә Минтимер Шәймиев КПССның Татар өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайлана. Шул чордан җитәкче Арчага елына ике тапкыр килә – чәчү барышын һәм урып-җыю эшләрен карарга.

– Шулай ук Минтимер Шәрипович район тормышы белән дә кызыксынды, – дип сүзен дәвам итте Вәгыйзь Василович. – Яңа ачылган мәктәп, мәдәният йортлары, юл төзелешләрен шәхсән үзе барып карый иде. Ул игътибарлылыгы белән аерылып торды – һәр юнәлешкә нык игътибар бирә, энәсеннән җебенә кадәр төшенә... Алай гына түгел, Минтимер Шәрипович бик еш гади халык белән аралаша иде. Теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәтләрен сорый, фикер алыша, нәтиҗә чыгара. Һәм соңыннан, болай эшләгез, дип безгә әйтә. Кыскасы, ул район тормышыннан да читтә калмый иде. Юк, мин бер Арчага гына шундый мөнәсәбәт булды дия алмыйм. Минтимер Шәрипович бик игътибарлы иде. Мин аның хәтеренә шакката идем.

САБАК

Вәгыйзь Василович Минтимер Шәймиевнең тагын бер сыйфатын ассызыклады – төгәллек. Аның күңелендә бүген дә бер вакыйга саклана:

– Арча районының беренче секретаре булып эшли башлаган чагым. Арчага җиткәндә бер матур гына бодай басуы бар иде – иген шаулап тишелеп чыккан, бер чүбе юк. Районны карап йөргәндә, Минтимер Шәриповичның күзе шул басуга төште. «Монда ничә гектар җир. Кайчан чәчтегез, туфракка нәрсәләр керттегез?» – дип сорады ул. Ничек бар, шулай җавап бирдем. Шуннан җитәкчебез әйтеп куйды: «Бу җирдән күпме уңыш җыеп алуыгызны әйтерсең», – диде. Ярар, хуш, көз җитте. Минтимер Шәриповичның теге соравы бөтенләй онытылган. Дөресен генә әйткәндә, мин инде аны искә алыр дип тә уйламадым. Татарстанда бер безнең район гына түгел бит!

Гадәттәгечә, көзен, урып-җыю эшләре белән танышырга килгәч, Минтимер Шәрипович Вәгыйзь Василовичтан сорап куя: «Ә бу кырдан күпме уңыш алдыгыз?» Җитәкче бер мәл аптырап кала. Аннан тиз генә үзен кулга алып: «Әйтә алмыйм. Мин күргәндә, инде җыеп алганнар иде», – ди. Минтимер Шәриповичка бу җавап ошамый: «Белергә кирәк, син бит җитәкче», – ди ул.

– Бу минем өчен бик зур сабак булды, – диде Вәгыйзь Василович. – Беренчедән, чынлап та районның һәр уңышын, һәр уңышсызлыгын мин белеп торырга тиеш. Икенчедән, Минтимер Шәрипович әйтте икән, димәк, онытмаячак. Бүтән андый хаталар эшләмәдем кебек...

МАТУР ПАРЛАР

Үзгәртеп кору чорын – 90нчы елларны күпләр хәтерлидер. Кибетләрдә товар юк, талон системасы. Эшчеләр айлар буе хезмәт хакы ала алмый. Вәгыйзь Василовичның күңелендә дә ул көннәр гомергә истә калган:

– Заманалар авыр, яшәү шартлары катлаулы. Район җитәкчесе булгач, халык ватык юллардан, башкасыннан зарланып килә. Күп оешмалар салым түли алмый. Нишләргә? Минтимер Шәрипович белән киңәшләшеп, аның рөхсәтен алып, оешмалар белән үзара исәп-хисап ясарга сөйләштек. Ягъни товар белән түли торган итеп.

Әнә шулай тырыша торгач, җае табыла. Районда ел саен җитмеш, сик-

сән километр юл салынып барыла. Ә 1998 елга Арча районы тулысынча газлаштырыла. Бер елдан Вәгыйзь Василович Арча районы башлыгы вазыйфасыннан китә. Үзе әйткәнчә, тыныч күңел белән, чөнки район өчен авыр заманалар артта кала.

– Ул елларда Минтимер Шәрипович ярдәме белән Арчада бик күп эшләр башкарылды, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – Ул эшләгәнне күрә, күңелне күтәрә белүче җитәкче иде. Шул елларда без иң күп иген уңышы ала башладык. Яңа орлыклар, яңа ашламалар алып кайттык. 1997 елда тарихта иң зур уңыш – 317 мең тонна иген җыеп алдык. Шул елны Татарстанның беренче Президенты зурлап уңыш бәйрәме үткәрде, Арча районын да мактап телгә алды. Мактаулы исемнәргә, дәүләт премияләренә лаек булдык. Бу минем өчен дә, игенчеләр өчен дә тагын канатланып эшләргә зур этәргеч бирде.

1980 нче елларда Россиягә Чехословакиядә эшләнгән уникe кирпеч заводы кайта. Шул исәптән берсен Татарстанга, ә нәкъ менә Арча районына бирәләр. Иң кызыгы һәм кызганычы – Россиянең башка төбәкләрендәге унбер кирпеч заводы таралып бетә, ә Арчада ул гөрләп эшләп тора. Ярты Татарстанны тәэмин итә.

– Шул чакта кирпеч заводын Минтимер Шәрипович безгә ышанып тапшырды. Ә без аның ышанычын акладык. Яшермим, мин моңа әле дә сөенәм, – ди әңгәмәдәшем.

Минтимер Шәрипович җәмәгате Сәкинә ханым белән дә берничә тапкыр Арчада булган. Вәгыйзь Василович ул чакларны болай дип искә алды:

– Ир белән хатын арасындагы иң матур мөнәсәбәтләрнең үрнәге иде алар, – диде ул. – Әйе, мин аларның өендә еш кунак түгел идем. Шулай да Сабантуйлар, башка зур чараларга Минтимер Шәрипович яраткан тормыш иптәше белән килде. Сәкинә ханым зыялылык үрнәге, бик гади, ачык, аралашырга рәхәт кеше иде. Алар белән бер табын артында утыру күңелле дә, дәрәҗә дә булды.

Вәгыйзь Василович тальянда уйный. Туры килгәндә, Татарстанның беренче Президенты янында да уйнаган. Берсендә Минтимер Шәрипович аңа үзенең балачак хыялы турында әйтә – кечкенә чагында тальянда уйнарга теләгән. Ләкин аерым сәбәпләр аркасында, бу хыялын тормышка ашыра алмаган. Шуны истә тотып, Вәгыйзь Василович Президентка тальян бүләк итә.

– Минтимер Шәрипович уйнарга өйрәндеме соң? – дим.

– Юктыр инде. Ә бәлки кайчагында тальянны кулына алып карыйдыр...

Татарстанның беренче Президенты турында истәлекләрне барлап сөйләшкәннән соң, Вәгыйзь Василович Минтимер Шәриповичка теләкләрен җиткерде:

– Иң мөһиме – саулык. Куанычлы озын гомер насыйп булсын Сезгә, Минтимер Шәрипович. Сез минем өчен – иң кешелекле, иң яхшы җитәкче. Гомергә...

«БЕЗГӘ МЕДИЦИНА СӘНӘГАТЕН ЮГАЛТУ ҺИЧ ЯРАМЫЙ...»

Нур Шакиров,
1987 елдан «Казан медицина инструментлары заводы» АҖ генераль директоры

– 1990 нчы еллар башында, тармакның башка предприятиеләре кебек үк, КМИЗ да кыен хәлдә калды.
Ил икътисадының җимерелүе, табигый ки, заводка бик нык зыян китерде. Коллективка эш хакы түләргә акча юк иде, Пенсия фондына зур бурыч җыелды. Ничек тә сафта калыр һәм хезмәткәрләребез белән исәп-хисап ясар өчен, без медицина инструментларын бартер буенча көнкүреш товарларына алыштыра идек. Предприятиенең киләчәге бер дә өмет уятмады...
Мин бик озак уйландым һәм... Президент янына киттем. Дөресен әйтим, сөйләшү шактый авыр булып чыкты. Нәтиҗәдә, бөтен нюансларны тикшергәннән соң, Минтимер Шәрипович: «Безгә медицина сәнәгатен югалтырга һич ярамый. Уйларга кирәк. Хәлне төзәтеп булыр, дип өметләнәм», – диде. Берничә көннән соң республика финанс министры КМИЗ проблемалары буенча Пенсия фонды җитәкчелеге белән махсус очрашты. КМИЗ бурычларын реструктурлаштыру турында карар предприятиене коткарып калды. Һәм без асылда инде өр-яңа КМИЗ булдырырга керештек. Шул вакыттагы очрашу һәм озаклап сөйләшү бүгенге казанышларыбызга китергән беренче адым булды.
Бүген КМИЗ – Россиядә стоматология, микрохирургия инструментларын һәм медицина өчен кирәкле полимер эшләнмәләр җитештерә торган иң зур предприятие. Завод үз продукциясен 90 нан артык илгә экспортка озата. Завод продукциясе ISO, ЕС (Европа), FDA (АКШ) стандартларына туры килә, күп илләрдә теркәлгән.
Хәзерге вакытта Татарстан – заманча медицина җиһазлары һәм инструментлары җитештерү буенча Россиядә һәм БДБ илләрендә әйдәп баручылардан берсе. Моңа республиканың беренче Президенты күрсәткән хезмәттән башка берничек тә ирешеп булмас иде.

Реклама

АБРУЙ ҺӘМ ЭНЕРГИЯГЕЗ ВАТАНЫБЫЗ ФАЙДАСЫНА ХЕЗМӘТ ИТСЕН!

Рөстәм Нуриев,
Алабуга муниципаль районы башлыгы, Алабуга шәһәре мэры

– Хөрмәтле Минтимер Шәрипович! Барлык алдынгы башлангычларга ярдәм итүче, актив тормыш позициясенә ия кеше сыйфатында, Сез һәрвакыт Россия масштабындагы шәхес булдыгыз һәм шундый булып каласыз, чөнки Татарстанда гына түгел, ә гомумән бөтен илнең иминлегенә, тынычлыгына, муллыгына керткән өлешегез бәяләп бетергесез.

Республиканың беренче Президенты буларак, Сез озак елларга Татарстанның нәтиҗәле үсеш юлын билгеләдегез, аны бөтен ил күләмендә иң алдынгы субъектлардан берсенә әверелдергән бик кирәкле карарлар кабул иттегез. Өстәвенә, «Татарстан моделе» – Сез җитәкчелек иткән вакытта нигезе салып калдырылган акыллы икътисадый реформалар гына түгел, ә тирәнтен уйланылган социаль һәм милли сәясәт тә ул.

Тузган торакны бетерү, социаль ипотека, тарихи кыйммәткә ия биналарны торгызу кебек Сезнең шәхси инициативагыз белән тормышка ашырылган программалар республика халкының мул тормышын, иминлеген кайгырту юнәлешендәге иң яхшы үрнәкләр булып кала бирә. Алабугалылар исә каланың 1000 еллыгын үткәргәнегез өчен Сезгә аеруча рәхмәтле.

Һәм бүген, республиканың Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасында, Сез татарстанлылар өчен әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итәсез. Шундый мисаллардан берсе: 2020 елда Алабугада Сезнең проект кысаларында «Адымнар-Алабуга» полилингваль мәктәбе төзелде, анда балаларны өч телдә – рус, татар һәм инглиз телләрендә укыталар. Мөмкинлектән файдаланып, мин барлык алабугалылар исеменнән Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм! Киләчәктә дә Сезнең абруегыз һәм энергиягез Ватаныбыз файдасына хезмәт итсен. Нык сәламәтлек һәм озын гомер телибез Сезгә!

БАРЛЫК НИЯТЛӘРЕГЕЗНЕ ЧЫНГА АШЫРУ ӨЧЕН ҖИТӘРЛЕК ЭНЕРГИЯ ҺӘМ КӨЧ ТЕЛИМ СЕЗГӘ!

Рәгать Хөсәенов,
Лениногорск муниципаль районы башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры

– Хөрмәтле Минтимер Шәрипович, шәхсән үз исемемнән һәм барлык лениногорскилылар исеменнән Сезне олуг юбилеегыз белән котлыйм!

Сездәге акыллы прагматизм, сабырлык, дипломатлык сәләте һәм искиткеч зирәклек күпмилләтле һәм күпконфессияле төбәгебездә тынычлык һәм иминлекне саклап калырга мөмкинлек бирде, дип әйтү һич арттыру булмас. Бу ахыр чиктә Татарстанга киләчәктә бер-бер артлы берничә республика программасын тормышка ашыруга һәм халкыбызның тормыш сыйфатын күтәрүне күздә тоткан социаль бурычларны үтәүгә юл ачты.

Эрудиция, зирәклек, фикер сөрешегез буенча Сез сәясәтче генә түгел, ә чын фәлсәфәче дә. Бу сыйфатларның барысы да татар мәдәнияте һәм республикабызда яшәүче башка халыкларның мәдәнияте саклау һәм үстерүгә юнәлдерелгән бүгенге эшегездә лаеклы чагылыш таба. Сез хәзерге Россия дәүләтенең үсешенә, аның гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һәм илебездәге төрле халыкларының бердәмлеген һәм татулыгын тәэмин итүгә элеккечә үк зур өлеш кертәсез.

Бу бәйрәм көнендә Сезгә иң ихлас йөрәктән чыккан теләкләремне юллыйм. Озын гомер һәм нык сәламәтлек Сезгә! Барлык уй-ниятләрегезне һәм планнарыгызны тормышка ашыру өчен җитәрлек энергия һәм көч насыйп булсын, боларның Сездә әле бик күп булуына ышанам!

БАРЛЫК НИЯТЛӘГӘН ЭШЛӘРЕГЕЗДӘ УҢЫШ ТЕЛИМ!

Илшат Нуриев,
Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе

– Хөрмәтле Минтимер Шәрипович! Арча районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 85 яшьлек гомер бәйрәмегез белән котлыйм.

Сез төрле вазыйфаларда ярты гасырдан артык армый-талмый республикабызга хезмәт итәсез. Тормыш юлыгыз Татарстан белән аерылгысыз бәйләнгән, Сезнең биография – Ватанны ныгыту һәм үстерү өчен аңа ихлас хезмәт итү үрнәге ул.

Якты шәхес, бетмәс-төкәнмәс иҗат потенциалына ия талантлы кеше, абруйлы һәм йогынтылы сәясәтче буларак, Сез Татарстаныбызның һәрьяклы үсешенә, хәзерге Россия дәүләтчелеген торгызуга, милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга бәяләп бетергесез өлеш керттегез. Игелеккә һәм иҗатка юнәлгән куәтле энергиягә ия булып, халкыбызның чын тарихын торгызу юлында бинигһая көч куя-куя, Сез хәзер дә кешелеккә һәм туган җиргә хезмәтегезне дәвам итәсез.

Юбилеегыз көнендә бездән хөрмәт һәм рәхмәт сүзләрен кабул итеп алыгыз. Сезгә ихлас күңелдән нык сәламәтлек, озын гомер һәм барлык планнарыгызны тормышка ашыруда уңышлар телибез.

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

игелекле эшләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Азнакайда галәм белән **НИЧЕК** аралашалар

Балан бәлеше **НИЧЕК** тәмле була

Татарстан блогерлары популярлык хакына **НӘРСӘЛӘРГӘ** әзер

PRESSA

RC4P – 210 нчы БИЕКЛЕКТӘ

– Бу халыкара космик станция зонасы… Бу Кара диңгез... Монысы – Каспий... Болары Азнакай турында мәгълүмат... Менә мин двигательне, бору җайланмасын кушам, радиостанцияне тоташтырам... Бер канал кабул итә, икенчесе – тапшыра… Роман-үзәк-дүрт-Павел… Рэди-Чарли-фор-әти… Ишетәсезме? Бу галәм тавышы! Ниндидер кыштырдаулар, чыелдаулар аша без чыннан да кемнәрнеңдер ерак тавышын ишетәбез кебек тоела.

БУ ГАЛӘМ

– Бу чыннан да галәм! Тоела гына дип уйламагыз! – ди 40 еллык стажы булган радиосөюче Ринат Вәлиев. – Ә хәзер якынрак киләчәк… Менә бу җайланма биеклек буенча да, горизонталь буенча да контрольлек итә. Һәм МКС-ның кайчан безнең өстән үтәсен хәбәр итә. Роман-үзәк-дүрт-Павел… Рэди-Чарли-фор-әти… Галәм белән элемтә расписание буенча алып барыла. Күптән түгел генә укучылар белән радиокосмик сеанс оештырдык. Алар өчен шаккаткыч булды!

Фото: Александр Ефремов

АЭРОДРОМДА РАДИОИҖАТ

Без Азнакай аэродромына, яшьләр радиостанциясенә килдек. Ринат Вәлиев үз укучылары – яшь радиосөючеләрне – атнага ике мәртәбә нәкъ менә бирегә алып килә. Монда радиоиҗат түгәрәге уздырыла.

Ә бу дәресләрне энтузиаст Ринат Вәлиев үз өендә – Азнакайдагы гадәти күпкатлы йорт фатирында үткәрә башлаган. Аның иң беренче укучыларыннан берсе бүген космонавтлар әзерләү үзәгеннән сәламнәр җибәреп тора, ул самолет төзелеше белгече!

Бүген район администрациясе, нефтьчеләр, шулай ук отып алынган грант акчалары ярдәме белән түгәрәкнең техник яктан җиһазланышы яхшыра бара. Һәм нәтиҗә буларак балалар төрле бәйгеләрдә җиңәләр, спорт мастерлары кандидаты нормасын үтиләр, ә бу аларга юнәлешле югары уку йортына керү мөмкинлекләрен ача. Европа, Азия, бөтенроссия ярышларында җиңүләр, Белоруссия, Россиянең башка төбәкләре, Халыкара космик станция белән радиоэлемтә сеанслары аларның техника һәм радиоэлектроника өлкәсендәге белемкүнекмәләрен ныгыта.

РИНАТ ВӘЛИЕВНЕҢ БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТЕ

Ринат Вәлиев бүгенге көндә Россия радиосөючеләре берлегенең Азнакай районындагы җирле бүлеген җитәкли. Радиотехника белән, үзенең кул астындагылар кебек үк, бала чактан мавыккан. Әлеге мавыгуын үзенең беренче һәм бердәнбер мәхәббәте дип атый. Чөнки аңа беркайчан да хыянәт итмәгән.

– Чөнки ул техник спортның иң кызыклы һәм тыныч төре, – дип аңлата ул. – Радио шәһәрләрне һәм илләрне, диңгез һәм океаннарны һәм хәтта галәм киңлекләрен берләштерә. Өстәвенә, радиосөючеләр, нинди генә телдә сөйләшсәләр дә, алар арасында беркайчан да сугыш һәм каршылыклар булмый. Һәм тагын радио белән шөгыльләнүче балалар белемле, акыллы була, чөнки радио белеменә бөтен нәрсә кирәк – алар антеннаны дөрес урнаштырырга һәм кирәкле диапазонны табарга өйрәнү белән бергә, тарих, география буенча белем алалар, телләр өйрәнәләр. Мин үзем, радиоэфирда төрле милләт кешеләре белән аралашып, сигез тел өйрәндем.

КИҢ БЕЛЕМЛЕ ПОЛИГЛОТЛАР

Радиоэлемтә серләренә өйрәнеп, Азнакай районы тиздән киң белемле полиглотларга ия булыр, ахрысы! Әлеге малайлар белән танышасы иде...

– Малайлар белән генә түгел! – дип төгәллек кертә Ринат. – Кызлар бездә хәтта күбрәк тә. Алар бик кызыксынучан. Космик элемтә вакытында биргән сорауларын ишетсәгез иде: «Сездә курку хисе буламы?», «Космик ашамлыклар сезгә ошыймы?», «Нинди төшләр күрәсез?». Космонавтлар кызыксындырган сорауларга бик рәхәтләнеп җавап бирделәр.

Бер сүз белән әйткәндә, узган гасырда ничек булгандыр, бусында космостагылар Җирдә Азнакай дип аталган гаҗәеп урын барлыгын беләләр, аны чакыру сигналы – RC4P – Роман-үзәк-дүрт-Павел... Рэди-Чарли-фор-эти...

1

– Роман-үзәк-дүрт-Павел... Рэди-Чарли-фор-әти...

2

– Бу чыннан да галәм! Сезгә тоела гына дип уйламагыз! – ди Ринат Вәлиев.

1

2

ДИАПАЗОННАРДА

– Радиосөючеләр өчен махсус ешлыклар бирелгән, без шул дулкыннарда эшлибез, – дип аңлата Ринат. – Чакыру сигналын махсус категория имтиханын тапшырганнан соң алалар. Категориягә бәйле рәвештә, теге яисә бу диапазоннарда эшләргә мөмкин.

Әңгәмә барышында эфирга башка радиосөючеләр бәреп керә.

– Николай-өч-Василий...

– Ульяна-радио-тугыз-Мария-Сергей...

– Роман-үзәк-дүрт-Павел, – дип җавап бирә Ринат.

– Сәлам, Ринат! – дип кычкыралар каяндыр космостан. – Диапазоннарда кабат очрашуыбызга шат!

– Бу космостан түгел, – дип көлә Ринат. – Украинадан. Ульяна-радио-тугыз-Мария-Сергей! Сәлам бирәм! Владимир, «Татар-

3
Европа, Азия, бөтенроссия ярышларында җиңүләр, Белоруссия, Россиянең башка төбәкләре, Халыкара космик станция белән радиоэлемтә сеанслары аларның техника һәм радиоэлектроника өлкәсендәге белем-күнекмәләрен ныгыта.

4
– Бу халыкара космик станция зонасы... Бу Кара диңгез... Монысы – Каспий... Болары Азнакай турында мәгълүмат...

5
Укучылар белән радиоэлемтә сеансы.

6
– Радиостанциядә алар үзләренең айфоннары турында онытып торалар. Чыбыклар белән мәш киләләр, үзләре өчен кечкенә, әмма шундый мөһим ачышлар ясыйлар... Бер сүз белән әйткәндә, интернетка бәйлелектән арынып яшиләр.

стан» журналы журналистларына сәлам бирегез әле! Алар бүген бездә кунакта. Приём!

– Татарстан Республикасы журналистларына Украинадан сәлам! Ульяна-радио-тугыз-Мария-Сергей-спутник – минем чакыру сигналы! Украинага килгәч, безнең янга да рәхим итегез!

– Сез безгә килсәгез, яхшырак булыр! – дип, татар кунакчыллыгын белдерергә тырышабыз без дә.

– Дмитрий-Леонид-беренче-Борис-үзәк! – безнең сөйләшүгә тагын берәү килеп керә.

– Бу Германиядән, – дип аңлата Ринат. – Рэди-Чарли-фор-эти... Сәлам! Приём!

Сәлам бирешүләр тәмамлана һәм без DL1BC (Дмитрий-Леонид-беренче-Борис-үзәк) сигналының Бремен шәһәреннән 20 км көньяктарак, Голландия чикләренә якынрак урнашкан кечкенә генә немец шәһәреннән килгәнлеген беләбез. Һәм шулай ук алар да Казаннан – 314 км һәм Мәскәүдән 1138 км ераклыкта урнашкан Азнакайдагы дусты – радиосөюче Ринат үтенече буенча «Татарстан» журналына сәлам тапшыра.

ИНТЕРНЕТКА БӘЙЛЕЛЕКТӘН АРЫНУ

Радионың да Интернетныкы кебек үк чикләре юк. Әмма аралашу ысулы искермәгәнме соң – бу турыда Азнакайдагы яңа танышыбыздан сорыйбыз.

– Бу бит бик кызык! – дип җавап бирә Ринат Вәлиев. – Бу танып белергә булыша, балаларның фикерләү сәләтен үстерә. Ышаныгыз, монда, радиостанциядә, алар үзләренең айфоннары турында онытып торалар. Чыбыклар белән мәш киләләр, үзләре өчен кечкенә, әмма шундый мөһим ачышлар ясыйлар, акыллырак була баралар, җанланып китәләр, төрле һөнәри күнекмәләр алалар. Бер сүз белән әйткәндә, интернетны онытып, телефон-интернетка бәйлелектән арынып яшиләр. О! Эфирга космонавтлар чыкты! Рэди-Чарли-фор-эти... Рэди-Чарли-фор-эти... Антон Шкаплеров белән сөйләшергә телисезме?

– Әлбәттә, телибез!

Тик монысы инде башка тарих. Бу турыда Космонавтика көнендә сөйләшербез! Т

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

АЛМАЛЫ БАЛАН БӘЛЕШЕ

Руфия Фазылова

Бу юлы аш-су бүлмәсенә зыялы да, уңган да, чын татар апасын чакырасы килде. Андый кешене озак эзләмәдек – Нәкыя апа Гыйләҗева гел күз уңында. Аның аш-суга оста икәнен күпләр белә. Кыскасы, бүген бездә кунакта – Аяз Гыйләҗевнең хәләл җефете, татар милләтенә өч зыялы ир бала үстергән Ана кеше.

«ҮЗЕМ УЙЛАП ТАПТЫМ»

Нәкыя апага ноябрьдә сиксән биш яшь тулды. Әле һаман сафта – хәләл җефетенең мирасын туплый, Аяз абыйның машинкада баскан хатларын, кулъязмаларын компьютерда җыя. Хәер, язучы үзе исән вакытында да, Нәкыя апа иренә әсәрләрен башта машинкада, аннан компьютерда җыярга булышкан.

– Аяз бик таләпчән булды, – ди Нәкыя апа. – «Миннән хата калырга тиеш түгел», – дип әйтә иде. Аның архивының тулысынча электрон вариантын булдырасым килде. Аязның аралашкан кешеләре белән хатларын тематик яктан тәртипкә китердем. Ибраһим Салахов, Вахит Юныс, Миргазиян Юныслар белән язышкан хатларын барладым. Аязның халыкка чыкмаган әйбере шактый күп иде, минә шуларны туплап калдырасым килде. Аллага шөкер, теләгемә ирештем инде.

Нәкыя апа уңган хуҗабикә, кайгыртучан дәү әни дә. Җиде оныгының, тугыз оныкчыгының кайда, ниләр белән шөгыльләнүен белеп тора. Сәгатенә кадәр әйтеп бирде. (Мондый хәтер һәр кешедә булсамы!)

Нәкыя апа камыр ризыкларын яратып пешерә икән. Бүген дә атнасына ким дигәндә бер тапкыр камыр куя. Безгә ул үз рецепты буенча балан бәлеше пешерергә вәгъдә бирде. Иртәнге тугызга хуҗабикәнең камыры кабарган иде инде.

Фото: Лилиана Вәлитова

КИРӘК БУЛАЧАК:

- Камыр

Эчлек:

- Балан – 2 стакан
- Алма – 2 данә
- Шикәр – 1 стакан
- Манный ярмасы – 5–6 аш кашыгы

1

– Алма турап салгач, балан бәлеше тәмлерәк була, – ди Нәкыя апа.

– Камыр кабарганны көтсәгез, озак булыр дип уйладым. Сез бит эш кешесе, – ди.

Нәкыя апа гадәти камыр куйган – сөт, май, йомырка, шикәр, тоз, чүпрә...

– Кем нинди камыр ярата инде, – ди хуҗабикә. – Берәүләр май белән шикәрне кушып, баллы камыр ясый, икенчеләр кибеттән генә сатып ала. Монда иң мөһиме – эчлек. Аяз исән вакытта балан бәлешен бик пешермәдем – яратмады. Дөресрәге, ул баланның исен өнәми иде. Искәндәрем белән Рашатым да этиләре кебек үк бу ризыкны ашамый, ә Мансурым менә ярата. Аяз вафатына өч айдан егерме ел тула, шуннан бирле балан бәлешен пешерәм.

Хуҗабикәнең туган ягы Сарман районында балан бәлешен һәр йортта пешергәннәр. (Бүген дә шулай икән.) Нәкыя апа исә иң тәмле балан бәлешен Аяз абыйның дәү әнисе пешергән дип саный. Һәрхәлдә, балачакта кызга шулай тоелган.

– Элек эчлекне арыш оны белән ясыйлар иде, – диде хуҗабикә. – Мин дә аны шулай пешереп карадым, ләкин килеп чыкмады. Шуннан соң үземчә менә шушы рецептны уйлап таптым. Ул мәшәкатьсез, бик җайлы әзерләнә – иң мөһиме шул.

ТУҢДЫРГЫЧТА – ЕЛЛЫК ЗАПАС

Чүпрәле камырны Нәкыя апа икегә бүлде. Бер өлешен шунда ук туңдыргычка алып куйды, гел шулай итә икән. Аннан кирәк чакта алып пешерә. Камырның икенче өлешен исә куна тактасына төшерде. Гадәттәгечә, бәлешнең асты өчен зур кисәк, капкач өчен кечкенә кисәк ясады. Аларны уклау белән җәйде. Зур түгәрәкне табага салды.

– Нәкыя апа, табаны майларга оныттыгыз түгелме, – дип куйдым.

– Онытмадым, табаны майлаганым юк. Камыр эченә май салдым бит, шул җитә. Ябышмый ул.

Нәкыя апа камыр өстенә башта туралган алмаларны тезеп чыкты. Аннан соң берәмберәм туңдыргычтан алган баланнарны җәйде.

– Элегрәк баланның үзен генә салып пешерә идем, хәзер алма да салам. Алай тәмлерәк була икән, – диде ул.

Шуннан соң кашыклап манный сипте. Монысы баланның суы агып чыкмасын өчен кирәк икән.

– Манный өстенә шикәр салабыз, – диде Нәкыя апа – Балан баллы ярата, шуңа күрә шикәрне кызганмаска кирәк. Аны тигезләп, эчлекнең бөтен җиренә салып чыксаң яхшы. Алай иткәндә бәлешнең әче өлеше булмый.

Ул арада хуҗабикә бәлешне томалап та куйды. Кырыйларын матурлап ясап чыкты.

– Булды, – диде Нәкыя апа. – Хәзер 180 градуслы мичкә кырык минутка пешерергә куябыз.

Хуҗабикә туңдыргычын ачып күрсәтте – ни генә юк анда! Биш литрлы чиләкләрдә карлыган, җиләк, чия, балан... Бактың исә, Нәкыя апа соңгы елларда кайнатма ясамый, ә җиләк-җимешне фәкать менә шулай катырырга куя икән.

– Ә туңдырылган карлыганны ничек ашыйсыз? – дим.

– Көн саен ярты стакан чамасы карлыганны алып куям да, җебегәч, ашыйм. Чәй белән дә эчәм, болай да кабып куям. Чын витамин бит ул, кибеттән химия сатып

алып ашаганчы... Ике улым үз йортлары белән яши, җимешләрне алар китерә. Туңдыргычны ел да шулай тутырам, ашалып бетә, Алланың рәхмәте. Киленнәр дә хәзер җиләк-җимешне шулай катырып кына куя, кайнатма ясамый.

БАТЫР НӘКЫЯ

Нәкыя апаны күзәтәм – күз тимәсен, шундый тере! Татар дөньясындагы барлык соңгы яңалыклардан хәбәрдар ул.

– Сез яшь чагында да шундый үткен идегезме? – дим.

– Әйе. Шулай булмасам, «халык дошманы» гаебе тагылган, биш ел ярым төрмәдә утырган, өстәвенә миннән тугыз яшь өлкән кешегә кияүгә чыкмас идем...

Аяз Гыйләҗев иҗаты белән таныш кешеләр хәбәрдардыр: 1950 елның 21 мартында яшь язучыны кулга алалар. Совет властена каршы язуда гаеплиләр аны. Биш елдан артык тоткынлыкта утыра ул. Ә Нәкыя апа белән кавышу тарихлары гаять үзенчәлекле. Аяз абый яшь кызга төрмәдән хатлар яза башлый.

– Мин Аязны тәүге тапкыр беренче класста укыганда күргән идем, – дип дәвам итте Нәкыя апа. – Әнинең бертуган сеңлесе Нәҗия апа Аязның әнисенең энесе Мирза абыйда кияүдә иде. Нәҗия апаларга бәби карашырга еш бара идем. Ә Аяз Сарман мәктәбенең 10 нчы сыйныфында укыганда аларда торды. Күрәсең, ул мине шул чакта якын итеп калган.

Беренче хатны игътибарсыз калдырса да, яшь кыз төрмәдән килгән икенче хатка җавап бирә. Шуннан... Аяз абый көн саен Нәкыягә хат язып тора. Һәм үзенә дә көн дә җавап язуын үтенә.

– Ә якыннарыгыз «халык дошманы» белән хат алышуыгызга каршы килмәдеме?

– Безне әни ялгызы үстерде, әтиебез яшьли вафат булды. Әниебез гаҗәп дәрәҗәдә зирәк, бик уңган хатын иде. Аязның хатларына җавап бирүемне күреп: «Кызым, ялгышмыйсыңмы икән?» – диде. Тик катгый каршы килде дия алмыйм. Без бит инде гаиләләребезне бик яхшы белә идек. Аязлар нәселе белемле, бик зыялы иде. Әни шуңа да каршы төшмәгәндер дип уйлыйм.

...Алар 1955 елның августында очрашалар. Биш елдан артык төрмәдә утырып чыккан Аяз тизрәк Нәкыясе янына ашыга. Беренче тапкыр Әхмәт авылында, Бузат чишмәсе янында очрашалар. «Син мин уйлаганнан да чибәррәк кыз булып үсеп җитешкәнсең», – ди егет кызга.

Әнә шул очрашудан соң ике елдан артык вакыт узгач, егет белән кыз өйләнешә. Бу вакытта алар икесе дә Казан дәүләт университетының татар теле бүлегендә укый. (Аяз абый төрмәгә утыртылганчы ук әлеге уку йортына кергән була.)

– Очрашып йөргән вакытта Аяз мәкалә, хикәяләрен минем исем белән бастыра иде, – дип дәвам итте Нәкыя апа. – «Халык дошманы» гаебе тагылган кешенең исем-фамилиясен күрсәтергә куркалар иде. Аннан, дөньялар үзгәрә башлагач, Аязны «Чаян» журналына эшкә алдылар. 1957 елның 3 марты иде ул. Шуннан Аяз, миңа килеп, кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Дөрес, аңа кадәр дә ул хакта әйткәләгәне булды. Мин ризалаштым һәм 1957 елның 4 мартында Аяз белән өйләнештек.

Ир белән хатынның беренче уллары Искәндәр туганда, яшь ана әле университетны тәмамламаган була. Шуңа да ярдәмгә авылдан Нәкыя апаның әнисен чакыралар. Нәтиҗәдә, ул алар белән гомер буе яши.

– Аяз әнине бик хөрмәт итте, кире авылга китә күрмәсен, дип борчылды, – диде хуҗабикә. – Аннан соң Мансур улыбыз да туды. Ике кечкенә баланы карарга кирәк. Минем башта уку, аннан эш булды. Шуңа күрә без әнигә бик рәхмәтле идек. Улларыбызга тәрбия, белем бирүдә аның роле зур булды. Мәктәпкә озату, каршы алулар, төрле түгәрәкләргә йөртүләр... Барысы да аның өстендә иде.

«УЛЛАРЫМ – ГОРУРЛЫГЫМ»

Балан бәлеше пешкән арада ана белән балалары турында да сөйләштек. Искәндәр, Мансур, Рашат – Нәкыя апа уллары белән го-

2

Чаллы татар дәүләт драма театрына Аяз Гыйләҗев исеме бирелү тантанасында.
Сентябрь, 2020 ел.

3
Нәкыя һәм Аяз Гыйләҗевлар.

рурлануын яшерми. Үзе әйткәнчә – эшлекле балалар үстергән.

– Өчесендә өч холык, – диде Нәкыя апа. – Искәндәрем шундый йомшак, чын зыялы. Бер генә дә усаллык юк аңарда. Нәкъ менә кайнатам инде, суйган да каплаган! Дөрес, төс белән охшамаган, тик сөйләшүе, холкы нәкъ ул. Эти төсле бакчаны ярата, әллә ниләр утырта. Барысы да геннардан килә. Шуңа да татар гомергә нәселенә карап кыз биргән, кыз алган. Менә хәзер шуны балалар мисалында ачык күрәм: нәсел кирәк, нәсел.

– Мансурым кайнанама охшаган, – дип дәвам итә Нәкыя апа. – Бик зиһенле, тиз эләктереп ала, эш сөя. Искәндәр кебек үк бакчачы түгел, ләкин ул агач ярата. Яз-көз, ел да сатып алып, агачлар утырта. Югары Осланга барып, бер гектар җиргә агач утыртты ул. Анда хәзер урман инде. Ни хикмәт, кайнанамнар ягы – Сөләйман картлар да гел агач утырткан. Бабай яз саен Бузат чишмәсен барып чистарткан, бөтен болынга агач утырткан. Әле аның юан-юан усаклары бүген дә үсеп утыра. Төпчегебез Рашатны ун елдан соң гына алып кайттык. Төсе белән нәкъ Искәндәр абыйсы, ә холкы белән миңа охшаган. Дөрес, Аязыма да охшаш яклары бар. Ул да бик зиһенле, чит телләрне яхшы белә. Аллага мең шөкер, безгә булдыклы, зиһенле балалар бирде.

– Нәкыя апа, – дим. – Ә кыз алып кайту теләге булмадымы соң?

– Юк, булмады. Киресенчә, малайлар булуына сөендем. Бер вакыйга сөйлим әле. Искәндәрем белән авырлы чак. Аяз белән Казан үзәгендә фатир яллап яшибез. Ерак түгел Нил Юзиевлар тора, аның хатыны Дамирә дә көмәнле иде. Нил безнең аша узганда кереп-чыгып йөри. Һич онытмыйм, 1958 елның июль ае, без Аяз белән өйдә. Берзаман Нил тәрәзәдән кычкыра: «Сез өйдәме? Зур шатлыгым бар – минем улым туды!» Аяз дерт итеп китте. «И, Юзиевлар бәхетле булды инде ул. Миңа Ходай кыз бирер...» – дип куйды. Шул вакытта борчылганнарым... Чынлап та кыз булса, Аязның кәефе кырылыр инде, дим... Малай тапканымны белгәч, Аяздан бигрәк үзем сөендем! Ник алай икәнен төгәл генә әйтә дә алмыйм. Аязлар дүрт ир бала үскән, безнең гаиләдә дә дүрт баланың өчесе малай булган. Малайлар белән җиңелрәк кебек миңа. Гәрчә аннары кыз оныкларым туды, бик яратам үзләрен. Алар да «әбекәй» дип кенә тора.

Кайсы гына язучы, галим белән сөйләшсәң дә, Гыйләҗевләрне мисал итеп куялар. Аяз Гыйләҗев малайларын

1 Камырны кабартабыз

2 Төшерәбез

3 Җәябез

4 Табага салабыз

5 Алма тезәбез

6 Балан салабыз

7 Шикәр комы өстибез

8 Җыябыз

9 Чит-читләрен бөгәбез

4

Алмалы балан бәлеше өлгерде дә.

чын милләтпәрвәр итеп тәрбияли алды, диләр. Һәм бу чынлап та шулай. Гыйләҗевләрнең һәркайсы – ана телен камил белүче, үз милләтенә хезмәт итүчеләр.

– Улларыгызда туган телгә хөрмәт, мәхәббәтне ничек тәрбияләдегез? – дим Нәкыя апага.

– Тел инде ул язылмаган закон. Татар телендә сөйләшәбез, татар гореф-гадәтләре буенча яшибез. Оныклар да шул юлны дәвам итә. Бу турыда сөйләшеп тә торасы түгел. Шулай буыннан-буынга килгән, шулай дәвам итәчәк, Алла боерса. Безнең гаиләдә: «Татарча сөйләш», – дигән сүз булмады. Балалар үзләре ана телендә сөйләште. Алар бер дигән итеп инглизчә дә белә. Ә Искәндәр немец телендә камил аралаша.

Гыйләҗевләрнең балалары татар мәктәбендә укымаган. Алай гына да түгел, алар укыган чорда мәктәптә татар теле дәресе факультатив кына булган. Шуңа карамастан, өчесе да татарчаны камил белә. (Сүз грамматика, телнең үзенчәлекләре турында да бара.)

– Сөйләм теле аңлашыла, ә мәктәптә ана телен укымаган балаларыгыз ничек татарча хатасыз яза белә соң? – дим.

– Мин бит татар теле укытучысы. Мәктәпкә кергәнче үк балаларны татарча язарга өйрәттем. Шунда телнең кагыйдәләре турында да сөйләгәнмендер. Татар китаплары, татар матбугаты укып үскән балалар алар. Искәндәр кайвакыт минем грамматик хаталарны да табып ала. Әлеге дә баягы, зиһен, нәселдән килү дә бар инде...

Балалар тәрбиясе турында сүзне йомгаклап, Нәкыя апа бүгенге яшь әти-әниләргә үз киңәшләрен бирде:

– Балаларның белемен үстерү өчен акча, вакытны кызганмаска кирәк. Без улларыбызны кечкенәдән төрле түгәрәкләргә йөрттек, максатчан рәвештә телләр өйрәттек. Хәзер минә оныкларны шулай үстерәләр. Мин моңа бик сөенәм.

Нәкыя апа шундый тәмле итеп сөйли ки, кырык минут вакыт бер мизгелдә узып китте. Аннан мин аның төгәллегенә игътибар иттем – телефонына искә төшерү режимын куйган. Кырык минуттан соң телефоны җырлый башлады. Минә бу ичмасам хуҗабикә!

– Булган, – диде Нәкыя апа.

Һәм балан бәлешен газ плитәсе өстенә алып куйды. Тәмле сый суынган арада зур фатирның бүлмәләре буенча экскурсия ясап чыктык. Монда һәр бүлмә музейны хәтерләтә – Аяз абыйның дистә еллар эчендә язылган хат төпләнмәләре, затлы картиналар (аларның һәркайсының үз тарихы бар), китаплар, тагын әллә ниләр... Нәкыя апа аларның һәркайсы турында бәйнә-бәйнә, яратып сөйли. Ә мин гаҗәпләнеп тә, сокланып та тыңлап тордым – иреңне ярату гына түгел бу, аны күккә чөю, гомереңбуе аңа соклану...

Нәкыя апа балан бәлешен кисте. Чынлап та, балан агып чыкмаган, матур булып пешеп кенә киткән. Алма белән балан катнашмасы әчкелт, шул ук вакытта баллы да бер тәм ясаган. Кышкы озын кичләрдә мәтрүшкәле чәй янына бер дигән ризык, киңәш итәбез!

PRESSA



НУРИӘХМӘТ САФИННЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Руфия Фазылова

–Җитмеш биш яшьлек юбилеем уңаеннан «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медален бирделәр. Шулай да татар артистларына Россия югарылыгында игътибар аз дип уйлыйм. Мәскәү артистлары белән безнең хезмәт хаклары да җир белән күк арасы бит. Пенсия дә шулай. Югыйсә безнең паспортка да Россия дип язылган. Илле елдан артык гастрольләрдә йөрдем, Советлар Союзын, Россияне аркылыга-буйга кичтем...

Әтисез үскән балачагым турында күп сөйләдем. Мин балачагымны фәкать якты төсләр белән истә калдырдым. Иң мөһиме – әнием исән иде, һәм мин аның канаты астында үстем. Әни белән безнең мөнәсәбәтләр шуның кадәр җылы иде ки, әйтеп аңлата алмыйм. Аның миңа тырнак очы белән дә чирткәне булмады. Ул каядыр чыгып китсә, тәрәзәдән күземне алмый идем. Иң курыкканым әнине югалту булды. Әниемсез мин нишләрмен дип, котым оча иде. Мөгаен, әтисез үскәнгә, күңелдә шундый уйлар булгандыр.

Әти дигән кеше үзебезнең авылда яшәде. Ләкин иң авыры әтисезлек түгел, ә туу таныклыгында әти исеме язылмаган булу иде. Минем ул юлда сызык торды. Шуның аркасында комсомол, аннан партиягә кергәндә тилмергәннәрем... «Ничек инде әтисез кеше булсын?» – диләр иде миңа. Илле яшемә җиткәч, пенсия документларын караштыра башлагач, сатып алдым ул исемне.

Әнине утыз биш елдан артык үзем тәрбияләдем. Күчмә театрга эшкә урнашкач та, аны авылдан Казанга алып килдем. Әнигә алтмыш та тулмаган иде әле. Тулай торакка бик теләп килде ул. Дөрес, җәй җиткәч, апа янына кайтып китә иде. Тик анда озак тора алмый – мине чакырып ала. Ни аяныч, апа җизни белән бергә салырга яратты. Икесе дә мәрхүм инде. Апаның бәхете булмады. Башта яраткан кешесенә кияүгә чыга алмады. Шуннан ничектер тормышы гел кире килеп торды.

Әни туксан бер яшькә кадәр яшәде. Мин гастрольләрдә булганда, хатыным карады, Казанда булганда исә – үзем. Чәчләренә кадәр кистем. Тик ничек кенә тәрбия кылсам да, күңелдә үкенеч бар – әнигә бар игътибарымны бирә алмадым кебек. Әни бакыйлыкка күчкәндә янында булдым, моның өчен Аллаһы Тәгаләгә бик рәхмәтлемен. Гастрольләргә чыгып киткәндә иң курыкканым шул булды: мин кайтканчы әни бакыйлыкка күчә күрмәсен.

Ул көнне бүгенгедәй хәтерлим. Белоруссиядән гастрольдән кайттык. Әни авыр хәлдә, алай да тамагына капты. Хатын эшкә китте, балалар мәктәпкә. Әни урыныннан тормакчы булды. Шулвакыт йөзе үзгәрде. Әнине кочагыма алдым, куенымда җан бирде... Бу минем әле дә йөрәгемне җылыта. Әгәр Казанга кайтып җитмәсәм, мәңгелек үкенеч белән яшәр идем. Әнине җирләү бик авыр булды. Кабергә такталар тезгәнне әле дә хәтерлим. «Әнием кала, әнием кала», – дип туктаусыз еладым... Шулвакыт миңа, Нури, син бүген әниең янында монда калырга тиешсең инде дисәләр, ике дә уйламас идем... Ул халәтне сөйләп аңлатып булмый.

Әни янына ирләр килмәде. Ул андый хатын булмаган, мин моны һич икеләнмичә әйтәм. Ә минем дөньяга килүем, эти кеше әнине көч белән алгандыр, дип уйлыйм. «Ник ирсез бала таптың?» – дигәч, әни: «Картлыгымда карар кешем булыр дип таптым», – дигән.

Язмышыма зарланмыйм. Шундый авыр тормыш киресенчә чыныктыргандыр, дип уйлыйм. Үземне якларга өйрәндем, монысы бәхәссез. Әниемә бик рәхмәтлемен, укытты, тәрбияләде. Улым кеше арасында ким-хур булмасын дип, соңгы сыерын, сарыгын да сатты...

Театр училищесын тәмамлагач, Уфа дәүләт университетына читтән торып укырга кердем. Ул вакытта мин өйләнгән идем инде. Театр училищесында укыганда укытучылар безгә: «Бәлки барыгыз да театрда эшли дә алмассыз, шуңа күрә тагын бер һөнәр үзләштерегез», – дип әйтә килделәр. Шулай итеп, Уфага гастрольләр белән баргач, университетның татар теле бүлегенә укырга кереп кайттым. Һәм уңышлы гына тәмамладым да. Уфада бик күп дуслар таптым. Читтән торып укысам да, ул чорлар бик җылы булып истә калды.

Укытучы булу теләге күңелдә калды кебек. Хәтта авылдан чыгып киткәндә, театр училищесына керә алмасам, укытучылыкка укыйм да авылга кайтам, дип уйлаган идем. Чөнки туган мәктәбемдә бик яраталар иде, хәтта чакырып калдылар.

Театр училищесын тәмамлагач, күчмә театрга эшкә урнаштым. Ләкин сиксәненче еллар азагында аннан киттем. Ни өчен дигәндә, гаиләмә, дөресрәге, балаларга игътибар калмый башлады. Мин гел гастрольләрдә, өйдә күрмиләр дә. Шуңа күрә «Тасма»га эшкә урнаштым. Озакламый мине Фәрит Хәбибуллин эзләп тапты: «Яшьләр өчен театр студиясе оештырабыз. Синең ярдәмең кирәк», – диде. Мин ризалаштым.



«Нигез ташлары» спектакленнән күренеш.

1987 елда оешкан татар театр студиясе Дәүләт техник һөнәри белем бирү комитеты каршында эшләде. Ягъни алар дәүләт карамагында, димәк, артистларга хезмәт хакы да түли алдылар. Соңрак аңа Кариев театры исеме бирелде. Шулай итеп, әлеге театрга нигез салучыларның берсе мин. Репертуар сайлау, спектакль кую – баштагы мәлдә болар барысы да минем өстә иде.

Сәхнәбез – һөнәр училищесының актлар залы, ә репетицияләр бер класста уза иде. Биш-алты елдан соң аңа дәүләт статусы бирделәр. Казанда беренче яшьләр театры оешты. Ул чор өчен зур вакыйга иде ул.

Дәүләт статусы алганчы, бик күп гастрольләрдә йөрдек. Туксанынчы еллар башы бит, суверенитет дип күкрәк киереп йөргән чак. Биш йөз, җиде йөз кешелек заллар шыгрым тула иде. Халыкның милли үзаңы уяна башлаган чор. Спектакльне тәрҗемә итү дә юк. Беләме-белмиме – театрга килеп утыра. Ник берсе каршы килсен!

Гладилов урамындагы бинаны калдырып, монда күчү, әлбәттә, сөенеч булды. Ләкин... Әгәр заманында аны «Созвездие-Йолдызлык»ка биргән кебек заманча ремонтлап тапшырган булсалар, без күбрәк отасы идек, дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, ул – тарихи бина. 1917 елда Касыйм Шамил шул бинада балалар өчен беренче спектакльләр куя баш-

Татар театр студиясе. 1990 нчы еллар.

лый. XX гасыр дәвамында берничә тапкыр балалар өчен театр оештырып караганнар. Менә шуңа бәйлисе килгән иде.

Телевидениедә балалар өчен тапшыру эшләгән чорларны әле дә сагынып искә алам. Тәм табып эшләдем. Үзләрен күрмәсәм дә, экран аша ул балаларның карашын тоя идем. Егерме еллап шунда эшләдем.

Олылар яки балалар өчен уйнау рәхәтрәкме дип сорыйлар. Икесе дә күңелгә якын. Король Лир кебек рольләрем бар. Ул спектакльне шундый яраттылар – күпме яхшы кайтаваз булды. Бүген исә «Нигез ташлары»нда Гарифулланы яратам, чөнки ул, хәзерге заман белән тәңгәл килеп, дөреслек белән бара торган бабай.

Бүгенге көндә яңа рольләргә бик алынмыйм. Хатыным чирләгәч, бер-ике спектакльдән баш тарттым. Кайбер рольләр күңелгә хуш килми, пьеса белән килешеп бетә алмыйм... Мисал өчен, «Сөннәтче бабай» белән шулай булды. Минем Гаяз Исхакый язган бабайны уйныйсым килгән иде, ә режиссер аны бөтенләй үзгәртеп бетерде. «Юк, мин моны уйнамыйм», – дидем.

Бүген татар театрында яңа жанрлар, мотивлар барлыкка килде. Заманнан артка калмас өчен аларны карап барырга тырышам. Дөресен әйтим, миңа ул бик авыр бирелә. Мин традицион, классик театрлар яклы. Бездә бер нәрсә булса, Европага юл тотабыз, диләр. Ә ни өчен без алардан үрнәк алырга тиеш? Ни өчен үзебезнекен үстермибез?

Бәләкәй чакта курчак театрын карап үстем. Анда начарны начар, яхшыны яхшы итеп күрсәтәләр иде. Ә декорация турында әйтеп тә тормыйм! Күңелгә якын, үзебезчә иде ул. Бүген менә шуларның барысын да, искелек калдыгы дип, сәхнәдән куып төшерергә тырышалар. Кайбер заманча спектакльләрне карагач, нәрсә турында барды соң бу, дип уйлыйсың. Нинди генә тәнкыйтьче килеп ышандырырга тырышса да, мин ул дөньяны аңлый алмам инде...

Хатыным белән бер ул, бер кыз үстердек. Улымның гаиләсе юк, прораб булып эшли. Эчми, тартмый, Аллаһка шөкер, зарлана алмыйм. Кызым исә французда кияүдә, чит илләрдә дә яшәделәр. Бүгенге көндә Мәскәүдә гомер итәләр. Кияү зур сәүдә челтәре кибетендә директор вазыйфасын башкара. Биш телне әйбәт белә, полиглот. Кызыма карата бик игътибарлы, әйбәт торалар. Бер кыз үстерделәр.

Кызымның бүтән милләт кешесенә кияүгә чыгуыннан башта кыенсындым. Аннан яхшылап уйлап карадым. Бәхет эше бит, каршы килеп, аннан гомер буе үкенсә. Кияү буласы кеше – Иван безнең белән танышырга кайткач, ошаттык үзен. Төпле кешегә ошаттык. Һәм ялгышмаганбыз да.

Үземне карыйм, сәламәт яшәү рәвеше алып барам, дип әйтә алмыйм. Соңгы елларда хатыным эчәк, ашказаны авырулары белән интегә. Шуңа күрә майлы, тозлы, кыздырылган ризыклардан баш тарттык. Иртән төрле ярма боткалары әзерлибез. Ә спорт юк инде бездән. Аңа җай да булмады. Минем гимнастика – сәхнәдә репетиция. Көне буе аяк өстендә бит.

БЕЛЕШМӘ:

Нуриәхмәт Сафин. 1946 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасының Алексеевск районы Кыр Шонталасы авылында туа. 1966 елда Казан театр училищесын тәмамлый.

1983 елда Октябрьнең 40 еллыгы исемендәге Башкорт дәүләт университетын читтән торып тәмамлый.

Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында 1987 елдан эшли.

1971 елдан Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге әгъзасы. Кариев театрына нигез салучыларның берсе.

Татарстан Республикасының атказанган артисты (1986 ел), Татарстан Республикасының халык артисты (1994 ел), Россиянең атказанган артисты (2007 ел).



1 ЯЗЫЛ

2022 елның 21 гыйнварына кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

электр иттарткыч, робот-пылесос, телевизор, кар көри торган җайланма. Төп бүләк — санаторийга 2 юллама



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 22.10.21 — 20.03.22 кадәр үткәрелә. Гаризалар 21.01.2022 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

ЯҢА ГАСЫР БЛОГЕРЛАРЫ

«Татарстан» журналы, инде гадәткә кергәнчә, Яңа ел алдыннан үз сайтында елның иң популяр блогерын ачыклау буенча тавыш бирүләр оештырды.

«ЯҢА ГАСЫР БЛОГЕРЫ» премиясен алу өчен 11 номинациядә 110 блогер катнашты. Исемлеге «Татарстан» журналы редакциясе тарафыннан төзелде. Анда - 2021 елның иң популяр, талантлы һәм үзенчәлекле блогерлары.

Жюри составына теләге булган онлайн-актив татарстанлылар керде. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча 11 җиңүче билгеләнде.

Җиңүчеләргә дипломнарны «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков тапшырды.

СЕЗНЕҢ АЛДЫГЫЗДА – ҖИҢҮЧЕЛӘР – ЯҢА ГАСЫР БЛОГЕРЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ:

Яңа гасырның туган тел блогеры:
Гөлназ Сәфәрова **(34%, 4 237 тавыш)**
@saffarka

Яңа гасырның лайфстайл-блогеры:
Салават Миңнеханов **(23%, 2 332 тавыш)**
@salavat_minnikhanov

Яңа гасырның бизнес-блогеры:
Руслан Абдулнасыйров **(22%, 2 173 тавыш)**
@ruslan_abdulnasyrov

Яңа гасыр музыкасы:
Фирдүс Тямаев **(21%, 3 111 тавыш)**
@firdustyamaev_official

Яңа гасырның фуд-блогеры:
Наидә Солтанова **(33%, 11 109 тавыш)**
@naida_foodblogger

Яңа гасырның фэшн-блогеры:
Анжелина Гыйльманова **(32%, 6 173 тавыш)**
@anzhelina_style

Яңа гасыр тиктокеры:
Рәмис Җиһаншин **(36%, 3 444 тавыш)**
@ramis007ramis007

Яңа гасыр инстамамасы:
Энҗе Нармаева **(34%, 3 775 тавыш)**
@enge_narmaeva

Яңа гасыр спор-блогеры:
Ольга Вдовина **(32%, 5 218 тавыш)**
@_olga_vdovina

Яңа гасыр бьюти-блогеры:
Алиса Тулынина **(22%, 1 772 тавыш)**
@alisatulynina

Яңа гасыр арт-блогеры:
Алина Николаева **(19%, 815 тавыш)**
@alina.photo.shik

ПОПУЛЯРЛЫК ХАКЫНА БЛОГЕРЛАР НӘРСӘЛӘРГӘ ӘЗЕР

Җиңүчеләр «Татарстан» журналы редакциясендә җыелды. Редакция бүлмәсендә чәй табыны оештырылды. Тәмле «Татарстан» торты белән чәй эчә-эчә журналистларыбыз кунаклар белән әңгәмә корды һәм тавыш бирү вакытында татарстанлыларны кызыксындырган төп сорауга җавап алды: популярлык казану хакына сез нәрсәләргә әзер?

ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕН КОРБАН ИТӘ АЛМЫЙМ

Алиса Тулынина:

– Мин инде популяр, әмма камиллеккә чикләр юк. Туганнарым һәм үземнең гаилә кыйммәтләрен, әлбәттә, корбан итә алмыйм, мин моңа әзер түгел. Әмма күбрәк эшләргә әзер. Кызыклы кешеләр белән коллаборацияләр эшләргә әзер. Нииндидер критик чиккә җитүме? Юк, мин моны абсурд дип саныйм. Чөнки барыбер кадрлар артында калган чын тормыш бар.

МИН ӘДӘПЛЕЛЕК КЫСАЛАРЫННАН ЧЫГА АЛМЫЙМ

Ольга Вдовина:

– Бу шактый катлаулы сорау. Шунысын тәгаен беләм: мин әдәплелек кысаларыннан чыга алмыйм. Һәрвакыт чикчаманы сакларга кирәк. Һәм бу чикне иң әүвәл кешенең тәрбиялелеге билгели. Кызганычка, бүген күпләр, үзләре дә аңламыйча, әлеге чикне үтеп чыга.

МИН ҮЗ-ҮЗЕМ БЕЛӘН ГАРМОНИЯДӘ БУЛУ ЯКЛЫ

Анжелина Гыйльманова:

– Әгәр кеше эшен яратып башкара, янып эшли икән, ул һичшиксез үсәчәк. Мин шундый үсеш яклы. Бу яктан караганда миңа нииндидер кискен этәргеч кирәк – мин үз-үзем һәм гаиләм белән гармониядә булу яклы.

УЙЛАП ЧЫГАРЫЛГАН ТАРИХЛАР ҺӘМ МӘКЕРГӘ БАРМЫЙМ

Энҗе Нармаева:

– Минем өчен әхлакый чикләр бар. Ялганга, популяр булу өчен махсус уйлап чыгарылган тарихларны, мәкерле эшләрне яктыртуга бармыйм. Тормышны ничек бар, шулай алып барырга тырышам. Элегрәк минем өчен популярлык авыррак иде: сторисха чыгу, шәхси тормышны төшерү һәм күрсәтү – болар барысы да үземне уңайлылык зонасыннан чыгару булды. Хәзер инде иялләштем. Эшем кебек кабул итәм.

ХАЙПКА КАРАГАНДА КОНСТРУКТИВ ЭШЛӘР КҮПКӘ НӘТИҖӘЛЕРӘК

Алина Николаева:

– Әлеге юнәлештә ниндидер конструктив гамәлләр кылу, кешене җәлеп итү өчен буш сөйләшүләр урынына үз гамәлләреңне күрсәтү хайпка караганда күпкә нәтиҗәлерәк дип саныйм мин. Пандемия шартларында, мәсәлән, ковидка каршы көрәшүче хастаханәләргә һәм табибларга булышырга мөмкин. Кемдер рак белән авыручыларга ярдәм итә, лейкемия белән чирләүчеләргә булышу өчен махсус фонд төзи. Әгәр бу чыннан да кирәк икән, аның турында барыбер сөйләячәкләр.

ХАЙП – БЕЗНЕҢ ТЕМА ТҮГЕЛ

Салават Миңнеханов:

– Хайп – безнең тема түгел. Без дини кешеләр, кара пиар безнең тормыш рәвешенә туры килми. Иманым камил, популяр булу өчен иң беренче чиратта эшләргә, үз эшеңнең фанаты булырга кирәк. Безнең очракта бу – иҗат. Без гадәти концертта гадәти эшебезне дә 100 процентка башкарырга тырышабыз. Вак-төяккә зур игътибар бирәбез. Бу, ихтимал, алай ук бәяләнми дәдер, әмма безгә моны эшләү күңелле, тамашачыларыбыз да моны сизә. Без акрынлап үзебезнең уңышларыбызны туплыйбыз һәм популяррак була барабыз.

ҮЗЕМ КАБУЛ ИТКӘН ИДЕЯЛӘРНЕ ГЕНӘ АЛГА СӨРӘМ

Гөлназ Сәфәрова:

– Чик һәркемнең үзенеке. Минем дә үз принципларым бар. Үземә якын, күңелемә хуш килгән, башкалар белән уртаклашырга теләгән нәрсәләрне блогыма куям. Чыннан да үзем кабул иткән, миңа ошаган идеяләрне генә алга сөрәм. Кешегә зыян сала алырдай нәрсәләрне, нинди генә акчалар түләсәләр дә, күрсәтмәячәкмен һәм акча түләнгән агитация белән дә шөгыльләнмим.

МИН НИНДИ БАР – ШУНДЫЙ!

Руслан Абдулнасыйров:

– Гомумән бернәрсәгә дә әзер түгел. Блог болай да популяр. Хайп ясыйм дип, «ыштан төшерергә», бака ашарга әзер түгел. Мин нинди бар – шундый. Хайп – һәркемнең шәхси эше. Әгәр ул беркемгә дә зыян салмый, бәреп екмый һәм беркемне дә зарарламый икән, бу нормаль күренеш. Һөнәри блогер – иҗат белән шөгыльләнүче кеше ул.

БЕРКАЙЧАН ДА ЯШЬ БУЫНГА ЗЫЯН КИТЕРЕРЛЕК НӘРСӘНЕ ЭШЛӘМӘЯЧӘКМЕН

Рәмис Җиһаншин:

– Минем өчен беркайчан да бозылырга тиеш түгел чикләр бар. Беренче чиратта – әхлакый. Беркайчан да яшь буынга зыян китерерлек нәрсәләрне эшләмәячәкмен.

ЧАРАБЫЗ ПАРТНЕРЛАРЫ:

«Cinema 5» кинотеатрлар челтәре (@cinema5ru)

«ESHAK» Көнчыгыш кухня рестораны (@eshak.kazan)

«Skyron» техника кибете (@skyron_kzn)

«Бинхартс Кофе» кофейнялар челтәре (@beanhearts.coffee)

«СМИТ» ит гастрономиясе кибетләре (@cmeat_meat)

«ЛЕПИМ и ВАРИМ» заманча пилмән кибетләре челтәре (@lepimivarim_kzn)

«Эби Суши» азык-төлек китерү хезмәте (@ebi_sushi_kzn)

«Florissimo Studio» чәчәкләр студиясе (@florissimo_studio)

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Разил Валиев
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Татар олимы аксакалы
Реклама 16+

Мәңгелек кыйммәтләр /

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татар гыйлеме җәмгыятен оештыруда **КЕМ** катнашкан

Китап киштәсендә **НИНДИ** китаплар бар

Республика күләмендә Яңа ел бәйрәме **КАЙДА** узган

Рудольф Нуриев келәмнәрне **КАЙДАН** сатып алган

РОМАНТИК ТАРИХЧЫ МИХАИЛ ХУДЯКОВ

Илдус Заһидуллин

Идел-Чулман төбәге халыкларының борынгы һәм урта гасырлар чорын өйрәнгән рус галимнәре бармак белән генә санарлык. Шундый күренекле затларның берсе – совет археологы һәм тарихчысы Михаил Георгиевич Худяков (1894–1936). Күренекле удмурт галимәсе, тарих фәннәре докторы Маргарита Гришкина аның турында: «Ул якты идеалларны тормышка ашырырга мөмкин булуына, Россиядә кешеләр һәм халыклар арасында чын мәгънәсендә тигезлек һәм туганлык булырга мөмкинлегенә ышанган үз заманы баласы, тарихчы-романтик булды. Шашынып ышануының бөтен көчен ул үзенең хезмәтләренә салды, шул исәптән Нократ-Чулман төбәге тарихына багышланган хезмәтләренә дә. Идеаллары тормышка ашсын өчен, ул үзен дә, хезмәттәшләрен дә җәлләмәде, ахыр чиктә шулар өчен гомерен бирде», – дип яза.

БЕЛЕМ ТУПЛАУ ЕЛЛАРЫ

Михаил Худяков Вятка губернасының өяз шәһәре Малмыжда 1894 елның 3 сентябрендә 2 нче гильдия сәүдәгәре Егор Павлович һәм Анна Михайловна гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе белемгә омтылучы улын Казанга җибәрә. 1906–1913 елларда шәһәрнең 1 нче гимназиясендә укыганда, яшүсмер сыйныфташлары белән Австро-Венгриядә һәм Төркиядә булып кайта. Гимназия укытучылары аның һөнәр сайлавында мөһим роль уйный: Михаил археология фәне белән ныклап кызыксына башлый.

Гимназияне алтын медальгә тәмамлагач, егет укуын Казан университетының тарих-филология факультетында дәвам итә. Студент Михаилның басылып чыккан мәкаләләре буенча ул шө-

Фотолар автордан алынды

гыйльләнгән фәнни темаларны төгәл ачыкларга мөмкин. Аның туган шәһәре һәм Малмыж өязе тарихының кайбер сәхифәләренә багышланган мәкалә һәм хәбәрләре «Вятка гыйльми архив комиссиясе хезмәтләрендә» 1915–1916 елларда дөнья күрә. Беренче фәнни язмаларында ук Михаилның галимлек сыйфатлары күренеп тора: автор тарихи фактларга һәм чыганакларга, аларның эчтәлегенә гаять зур игътибар бирә; язма чыганаклардан тыш, археология, этнография һәм хәтта өлкән буын кешеләреннән сораштыру материалларын урынлы файдалана; яктыртыла торган темага караган барлык хезмәтләрдән хәбәрдар була.

Студент елларында Михаил даими шөгыльләнгән икенче зур тема – Идел-Чулман төбәгенең борынгы тарихы. Ул археологик эзләнүләр һәм экспедицияләр белән үрелеп бара. Болгар шәһәрлегендә казу эшләре алып барачак П.А. Пономарев җитәкчегендәге группага Михаил Худяков 1914 елда фотограф штатына кабул ителә. Чынлыкта исә аңа беренче елны ук казу эшләре буенча хисап язуны – каталаулы һәм махсус белем сорый торган эшне ышанып тапшыралар. 1915 һәм 1916 елларда Биләр һәм Болгар шәһәрлекләрендә казу нәтиҗәләрен Худяков фәнни мәкаләләрендә сөйли. Археологик эзләнүләр Михаилның фәнни карашлары формалашуда мөһим урын тоткан, күрәсең: ул еш кына, мин археолог, дип әйтергә яраткан.

Михаил Худяков Вятка һәм Казан гыйльми җәмгыятьләрендә француз һәм алман телләрен камил белгән һәм тормышын фәнгә багышларга теләгән студент булып таныла. Әмма Беренче бөтендөнья сугышы елларында армиягә алыну һәм 1916–1917 елларда хәрби хезмәттә булу аңа университетта укуын кабат 1918 елда гына дәвам итәргә һәм шул ук елны тәмамларга мөмкинлек бирә. Сәяси карашлары буенча эсерлар партиясе тарафдары була.

КАЗАНДА ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Михаил Худяков, университетны тәмамлагач, 1918–1919 елларда Казанның 4 нче икенче баскыч мәктәбендә укыта, аннан соң 1925 елның 1 февраленә кадәр Казан губернасы (1920 елдан – Татар республикасы Үзәк музее) музеенда тарих-археология бүлеге мөдире булып эшли. Бу елларда Үзәк музейда Б.В.Адлер (директор), П.М.Дульский, Н.И.Воробьев, Г.С. Гобәйдуллин, М.Е. Евсевьев һ.б. кебек көчле галимнәр төркеме хезмәт куя. Музейның Михаил Худяков җитәкләгән бүлек фонды Ф.В.Баллод казыган Иске һәм Яңа Сарай шәһәрлекләре табылдыклары, археолог В.Ф.Смолин тапкан материаллар, Казан коллекционерлары Н.В.Высоцкий, В.И.Заусайлов варисларыннан сатып алынган әйберләр хисабына байый. Аларны теркәү һәм тасвирлау белән бүлек мөдире шөгыльләнә. Михаил Худяков, гомумән, биредә тупланган материалларны кызыксынып өйрәнә, яңа табышлар төбәкнең һәм Казанның борынгы һәм урта гасыр чорларын чагылдырган яңа экспозицияләргә дә урнаштырыла. Ул шулай ук Казан һәм шәһәрнең тирә-ягына тарихи-мәдәни һәм археологик эчтәлекле экскурсияләр планнарын эшләүдә катнаша, 1921–1922 елларда шушы юнәлеш белән шөгыльләнүче Казан экскурсия базасының уку-укыту бүлеге мөдире булып та тора. Болардан тыш, 1919 елның көзеннән 1922 елның язына кадәр Көньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институтының археология кафедрасында дәресләр алып бара.

Гражданнар сугышыннан соңгы чорда советча яшәү рәвеше империя чоры тарихи-мәдәни ядкәрләрен кирәксезгә чыгара. Худяков аларның бер өлешен музей-архивларга туплау буенча гаять кирәкле эш башкарган галимнәр сафында була. Биредә аның 1920 елда «Казанский музейный вестник» журналында басылган «Старое – юно!» исемле мәкаләсен искә алып үтү зарур. Удмурт, мари, чуваш һәм татар төбәк тарихларын өйрәнүчеләргә мөрәҗәгать итеп, автор милли тарихка бәйле әйберләрнең барысын да игътибарга алырга, тикшерергә чакыра, борынгы бабайлар нәрсә белән яшәгәннәрен белү, риваятьләрне, йолагадәтләрне, ритуалларны, җырларны җыю, бабаларыннан ишеткән борынгы легендаларны язып алу кирәклеген искәртә, «Тизрәк эшләргә ашыгыгыз!» дигән лозунг ташлый. Бу халыклар вәкилләреннән тиз арада милли даһилар үсеп чыгачагына ышанычын, төбәк халыкларының мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүне үзенең рухи бурычы итеп санавын белдерә.

1921–1924 елларда, ТАССР хөкүмәтен Кашшаф Мохтаров җитәкләгән вакытта, Казанда татар гыйлеме академик фән буларак формаша. 1921 елда Халык мәгарифе комиссариаты каршында Академүзәккә нигез салына. Аның беренче рәисе булып Гаяз Максудов тора. Академүзәк, булган фәнни көчләрне җәлеп итеп, татар тарихының мөһим этапларын язарга алына. 1922 елда Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим авторлыгында бүгенгә кадәр тиңе булмаган, татар мәдәниятенең күпгасырлык тарихын колачлаган «Татар әдәбияты тарихы» исемле фундаменталь хезмәт дөнья күрә. Шул ук елны Газиз Гобәйдуллин «Татар тарихы» исемле яңа китабында беренче тапкыр, Европа тарих фәне традицияләренә нигезләнеп, милли тарихны бербөтен, өзлексез процесс буларак язып чыга.

Шунысы кызык: 1923 елның мартында Академүзәк Татар мәдәниятен өйрәнү институтын төзү турында карар кабул итә, аның беренче зур фәнни эше итеп ТАССРның археологик картасын төзүне билгели. Михаил Худяков Татарстанның археологик картасын төзи, ләкин институт нинди дер сәбәпләр белән ачылмый кала. Күрәсең, бу фәнни оешманың вазыйфалары 1923 елда теркәлгән Татар гыйлеме җәмгыятенә тапшырыла. Ху-



Михаил Худяковның гимназиядә укыган вакыты. 1913 ел.

дяков бу җәмгыятьне оештыруда катнаша, 1923–1925 елларда идарәсенең сәркатибе була.

Казанда яшәгән вакыты Михаил Худяков өчен искиткеч нәтиҗәле иҗади чор дия алабыз: 6–7 елда галим кырыкка якын хезмәт бастыра. Күпсанлы мәкаләләрендә, китапларга язган рецензия-бәяләмәләрендә, некрологларда, күзәтү рәвешендәге язмаларында галим үзен фин һәм угыр халыкларының этнографиясе, мифологиясе һәм фольклоры, болгарларның һәм Казан татарларының тарихы һәм мәдәнияте, Урта Идел төбәгендәге бакыр археологиясе чоры, ананьин археология культурасы буенча киң карашлы белгеч итеп таныта. Бу хезмәтләр арасында Михаил Худяковка фәнни даирәдә танылуны Казан ханлыгы тарихына багышланган китабы китерә.

«КАЗАН ХАНЛЫГЫ ТАРИХЫ БУЕНЧА ОЧЕРКЛАР» КИТАБЫ

Владимир Ленин яшь совет дәүләтенең рәсми тарих фәнендә марксистик идеологияне эшләүче итеп рус тарихчысы М.Н.Покровскийны сайлый. Марксист тарихчының «милли мәсьәлә» буенча фикерләре игътибарга лаек. М.Н.Покровский рус булмаган халыкларны «мәдәни яктан артта калуда» гаепләүгә һәм башка кимсетүләргә каршы чыга. Кайбер халыкларны Россиягә кушуны – прогрессив күренеш түгел, кушуның сәбәбе царизмның агрессив тышкы сәясәте дип атый.

Михаил Худяковның 1923 елда дөнья күргән «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» китабы нәкъ менә академик М.Н.Покровскийның тарихи концепциясе буенча эшләнә.

28 яшьлек Худяковның китабы Россия гуманитар фәнендәге империячел стереотипларны җимерүгә хезмәт итә. Авторның йөгерек каләме, кыю фикер сөреше, галимлек таланты, чыганакларны яхшы белүе һәм оста анализлавы күп мәсьәләләрне дәлилле итеп яктырырга мөмкинлек бирә. Галим казанлылар турында тирән ихтирам белән яза. Ул, беренче булып, Казан ханлыгы эшчәнлеген һәм казанышларын цивилизация күзлегеннән югары бәяли, халкының азатлык өчен көрәшен Ватанын саклау өчен гадел көрәш дип билгеләп үтә.

Автор ханлыкның сәяси тарихын берничә этапка бүлеп яктырта: дәүләтнең көчле чагы (1438–1487 еллар), рус протектораты чоры (1487–1521 еллар), милли күтәрелеш заманы (1521–1550 еллар) һәм ханлыкның егылуы (1551–1556 еллар). Ханлыкның идарә һәм хакимият институтларына, җәмгыятьнең социаль төркемнәренә, дәүләтнең җиңелү сәбәпләренә махсус бүлекләр багышлый. Шулай ук урта гасыр Казан каласы турында материалларны аерым туплап урнаштыра. Китапны укыган кешедә Казан ханлыгы тарихына һәм аның халкына карата олы хөрмәт, ә татар укучысында милли горурлык хисе һәм идарәче даирәләр җибәргән хаталарга ачыну тойгысы туа. Әлбәттә, китапта төгәлсезлекләр, тарихи вакыйгаларны беркатлы яки бер яклы итеп сурәтләү очраклары да юк түгел, ләкин алар хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен һич кенә дә төшерми.

КАЗАНДА СӘЯСИ КӨРӘШКӘ КУШЫЛУЫ

1920–1921 елларда Казан университеты каршындагы Археология, этнография һәм тарих җәмгыятенең эшчәнлеге төрле сәбәпләр аркасында туктап кала. 1922 елның апрелендә җәмгыятьнең яңа рәисе сайлана, ләкин аның Гыйльми шурасын оештырганда, Совет хөкүмәте яклы булган галимнәрнең күбесе каршы тавыш белән төшеп кала. Шулай итеп, җитәкчелеккә сайлаулар галимнәрнең профессиональ сыйфатларына карап түгел, ә сәяси карашларына нигезләнеп уздырыла.

Бу вакытта җәмгыятьнең җитәкчелеге, совет дәүләтенең фән һәм фәнни хезмәткәрләргә карата уздырыла торган сәясәте белән килешмичә, аңа пассив һәм әчкерле каршылык күрсәтү юлына баса. Мондый позиция сәя-

си максатларны күздә тотмый, ә фәннең киләчәге турында борчылуга бәйле була. Җәмгыятьнең 1923 елның гыйнварыннан 1924 елның мартына кадәрге вакыт аралыгы хисабында «Хәбәрләр»нең XXXIII томының 1 нче чыгарылышы, марксистик әдәбият бастырырга кирәк булу сәбәпле, дөнья күрми калды дип әйтелә. Нәтиҗәдә совет хакимияте тарафыннан җәмгыятьнең эшчәнлеген күзәтү көчәйтелә, ОГПУның Татарстан бүлеге 1924 елның сентябрендә рәис К.В.Харлампович һәм тагын алты галим өстеннән тикшерү башлый. Алар карагруһчылыкта, иске фикерләр белән сугарылган «чиста фән» белән шөгыльләнүдә, контрреволюцион эшчәнлектә, халык арасында христианлык, искелек, консерватизм фикерләрен таратуда гаепләнә.

ИДЕЛ-ЧУЛМАН ТӨБӘГЕ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Михаил Худяков 1925 елда Казан фәнни җәмәгатьчелегенең тискәре карашы һәм басымы астында Ленинградка күченергә мәҗбүр була һәм хезмәт юлын хәзерге Россия милли китапханәсендә фәнни хезмәткәр буларак башлый. 1926–1929 елларда, Тарих һәм матди мәдәният тарихы дәүләт академиясе аспиранты буларак, Идел буе төбәге тарихының таш һәм бакыр чорларын өйрәнү белән шөгыльләнә. 1929 елдан ул СССР ФА каршында СССР халыкларын өйрәнү институтында эшли. 1934–1936 елларда Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясендә хезмәт куя.

Ленинградта галим Казанда башлаган темасын – фин халыкларының тарихын өйрәнүне дәвам итә. Тарихчы 1935 елда «Очерки истории первобытного общества на территории Марийской области» дигән хезмәт бастыра. 2008 елда галимнең Ленинградта язылган «История вотского народа» һәм «Общественный строй вотяков в VII–XIV столетиях» исемле күләмле хезмәтләре, ниһаять, укучыга барып иреште. Архивларда аның әлегә кадәр басылмаган «Культ деревьев народа мари», «Религиозные верования в Поволжье в эпоху родового общества», «Древнее Поволжье (до V в.н.э.)», Среднее Поволжье (до V в.н.э.)» һ.б. кулъязмалары саклана.

Саналган хезмәтләре галимнең искиткеч киң карашлы энциклопедик белемле белгеч булганлыгын раслый.

СОВЕТ ТАРИХ ФӘНЕНӘ ХЕЗМӘТТӘ

Совет хөкүмәте Михаил Худяков эшләгән Матди мәдәният тарихы дәүләт академиясенә археология фәненә марксистик методологияне кертү, «буржуаз-дворян археологиясен һәм историографиясен» тәнкыйтьләү һәм шушы тәнкыйтьнең һәм чыганакларны анализлауның яңа методларын эшләү бурычын йөкли. Худяковның шушы бурычны үтәү йөзеннән һәм яңа идеологик таләпләрне күздә тотып 1933 елда басылган «Дореволюционная русская археология на судьбе эксплуататорских классов» хезмәте методологик әһәмияткә ия була. Әмма галим Россия археология фәнен сыйнфый күзлектән чыгып бәяли: «марксистик совет фәнен» яклап, «буржуаз фән вәкилләрен» тәнкыйтьли, тискәре мисаллар төсендә үзе яхшы белгән хезмәттәшләренең биографияләреннән фактлар китерә һәм аларны, аерым очракларда, урынсызга кимсетә. Шунысы кызык: соңрак Михаил Худяков эшләгән Россия тарих фәне этаплары барлык совет югары уку йортлары өчен тарих фәне дәреслекләрендә, авторның исеме аталмыйча гына, урын ала. Шулай итеп, Михаил Худяков историографиядә партиялелек принцибы методологиясен булдыра. Талантлы шәхесләргә һәр сәяси режим мохтаҗ: совет хөкүмәте тарих фәнендә марксистик принципларны әзерләүдә күренекле тарихчы Михаил Худяковның гыйлемен файдалана.

Аның 1932 елда басылган «Великодержавный шовинизм в русской этнографии» исемле хезмәте дә шушы рухта язылган. Инкыйлабка кадәрге фәнни мирасны бәяләгәндә, Худяков Россия империясендәге барлык уку йортлары, фәнни җәмгыятьләр, галимнәр самодержавиене ныгытуга хезмәт итте, хөкүмәт тарафыннан финансланды, шовинистик идеологияне булдырды дигән фикергә таяна.

1936 елның февралендә СССР Мәгариф наркоматының Югары аттестация комиссиясе, галимнең күпсанлы фәнни хезмәтләрен исәпкә алып, Худяковка яклатмыйча гына тарих фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсен бирә.

Кызганычка, 1936 елның 9 сентябрендә Михаил Худяков һәм аның тагын ике хезмәттәше контрреволюцион троцкист-зиновьевчылар оешмасында катнашуда һәм террорчылыкта гаепләнеп кулга алына. Беренче көннәрдә сорау алганда Худяков совет хөкүмәтенә каршы булганын инкарь итә. Ләкин берничә көннән, күрәсең, җәзалауга түзә алмыйча, үзенең гаебен «таный» һәм тагын берничә хезмәттәшен террорчылар оешмасы әгъзалары дип атый. СССР Югары суды Хәрби коллегиясенең 1936 елның 19 декабрь карары нигезендә галим шул ук көнне атып үтерелә.

Бу карар шул ук оешма тарафыннан 1957 елның 27 июнендә юкка чыгарыла. Ләкин нахакка гаепләнгән галимнең хезмәтләре фәкать соңгы өч дистә елда гына кабат фәнни әйләнешкә керә.

Михаил Худяковның иң популяр хезмәтләреннән берсе.

КӨЗГЕДӘГЕ ЧАГЫЛЫШ, ЯКИ БЕЗНЕ ҮЗЕБЕЗГӘ АЧА ТОРГАН КИТАПЛАР

Луиза Янсуар

2021 елның ахыры безне кызыклы китап «премьералары» белән сөендерде. Шуларның икесенә тукталып узыйк.

олар https://www.livelib.ru/, https://www.litmir.me/ сайтларыннан алынды



ГАДӘТИ ТОРМЫШНЫҢ ТАТЛЫ АЧЫСЫ

Сандро Веронези, «Колибри»
«Эксмо» нәшрияты, 2021
Тәрҗемәче: Владимир Лукьянчук

Мин үзем бу романның китап кибетләрендә пәйда булуын ел дәвамында көттем. Веронези шәхсән миңа һәм гомумән рус телле укучыларына моңарчы тәрҗемә ителгән һәм рус телендә дөнья күргән «Спокойный хаос», «Сила прошлого» романнары буенча таныш. Аның прозасын Альберто Моравиа һәм Джон Ле Карре традицияләре белән бәйләп шәрехлиләр, Паоло Пазолини һәм Орсон Уэллс кебек режиссерлар экранда тудырган атмосферага тартым дип табалар. Мин үзем параллельләр китерүгә һәрчак шикләнеп карыйм, әмма «Колибри» романы миндә кайчандыр баштанаяк әсир иткән Джон Ирвингның «Молитва об Оуэне Мини» һәм Джон Фаулзның «Башня из черного дерева» әсәрләре белән аваздаш тойгылар уятты. Ирвинг, Фаулз шикелле үк, Веронези шактый катлаулы, әмма искиткеч серле фактура белән эш итә – бу, бер карасаң, бик гади, өрфиядәй җиңел тарих та, шул ук вакытта эпик башлангыч белән фәлсәфи катламнарны укмаштырган катлаулы структура да.

Сандро Веронези – итальян язучысы, публицист, журналист. Флоренциядә туып-үсә. 1985 елда Флоренция университетында «Виктор Гюго һәм заман реставрация мәдәнияте» темасына диплом эше язып, архитектор дипломы ала. Әмма 25 яшендә язучы булырга карар кыла. Тәүге шигырь җыентыгын бастырып чыгара. Шуннан соң прозага күчә һәм берничә роман, күпсанлы мәкалә-эсселар, пьесалар, телевидение өчен сценарийлар иҗат итә. Берничә әдәби премия лауреаты. Әдәби газеталар һәм журналлар белән актив хезмәттәшлектә. Fandango Libri исемле нәшрияткa һәм Radiogas дигән веб-радиога нигез сала һәм аларны җитәкли.

Сюжетка килсәк, ул бик гади, хәтта ки гадәти дә дияр идем. Марко Каррера исемле геройның гаҗәеп сыйфаты бар – ул, әйтерсең, кечкенә генә колибри, тирә-юньдә нинди генә матавыклар булмасын, дөнья тигезлеген, ягъни балансын саклап кала белә. Язмыш аның үзен дә, гаиләсен дә бер-бер артлы сынаулар белән сыный, ләкин бу «кечкенә» зур кеше һәр көн аларга каршы торырга һәм җиңеп чыгарга көч таба. Ул әлеге катлаулы хәлләрдән үзе өчен чыгармалар ясый, башкаларның ялгышларын йөрәге аша уздырып, арадагы өзелгән җепләрне ялгый. Без аңа үзебез дә роман барышында җиңел бурычлар куймыйбыз, алар җиңелрәк тоелса, хәтта тел шартлатабыз. Янәсе, син нәрсә, син бит сыгылырга да, сынарга да тиеш түгел! Син моннан зуррак йөкне дә күтәрергә сәләтле!

«Колибри» романын тәнкыйтьчеләр Пол Остерның атаклы «4321» романы белән чагыштырырга ярата. Чынлап та, бу ике саллы роман арасында охшашлык бар, әмма Остер әсәренең героена тормышын дүрт мәртәбә яшәп карарга һәм төзәтергә мөмкинлек бирелгән булса, Марко Каррера очрагында, юк, андый форсат каралмаган. Бу – бер җепкә тезелгән һәм котылгысыз вакыйгаларга корылган язмыш. Һәм ул, Италия язучысы тарафыннан язылган булса да, «татлы» гына түгел, ә үз югалтулары, төзәтеп булмаслык борылышлары, ачысы, хәсрәтләре белән дә бирәгәйле.

Роман 2020 елның мәртәбәле китап премиясе Strega белән бүләкләнде. Дөньяда 300 меңнән артык нөсхә белән сатылды.

– БУ РОМАН – КЫЗЫКЛЫ ХӘЛЛӘР ҺӘМ КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ МОГҖИЗАЛАР БЕЛӘН ТУЛЫ ТАРТМАНЫ ХӘТЕРЛӘТӘ.
Иэн Макьюэн, язучы

ҖИҢҮ БЕЛӘН ҖИҢЕЛҮ – БЕР БИЗМӘНДӘ

Энн Пэтчетт, «Голландский дом»
«Синдбад» нәшрияте, 2021
Тәрҗемәче: Сергей Кумыш

Энн Пэтчетт безгә шулай ук яхшы таныш автор, аның моңа кадәр басылып чыккан әсәрләре буенча укучы үз фикерен һәм мөнәсәбәтен булдырып өлгерде. Яңа романны тәнкыйтьчеләр, дөнья күргән көненнән алып, «абыйлы-энеле Гриммнар экиятенә тиң» дип билгеләде. Асылда, бу без XIX–XX гасырлар чигендә яхшы үзләштереп өлгергән, ә аннан соң күпсанлы үзгәрешләр кичергән гаилә эпосы буларак кабул ителә ала. Автор үзе дә әлеге линияне һәрдаим күз уңында тота булса кирәк, төп сюжет сызыгыннан тайпылмый һәм аны соңгы ноктасына кадәр эзлекле рәвештә китереп җиткерә.

Энн Пэтчетт – Америка язучысы, Лос-Анджелеста туып-үсә. Күпсанлы әдәби премияләр лауреаты. 2012 елда Time журналы аны дөньядагы иң абруйлы 100 кеше исемлегенә кертте. Рус теленда Пэтчеттның «Белькanto», «Свои-чужие», «Прощальный фокус», «Предчувствие чуда» романнары һәм «Это история счастливого брака» эсселар җыентыгы тәрҗемә ителеп басылып чыкты. 2020 елда «Голландский дом» романы Пулитцер премиясе лауреатлары исемлегенә кертелде.
Энн Пэтчетт 2010 елда Parnassus исемле бәйсез китап кибетенә нигез сала. Аның әсәрләре буенча фильмнар да билгеле.

Готик романнар стиле, әлбәттә, метаморфозалар кичерә, әмма барыбер дә үз атмосферасын җуймый. Романдагы абыйлы-сеңелле Конройлар язмышы безне, Эмили Бронтеның «Грозовой перевал»ы яисә Дафна Дю Морьеның «Ребекка»сы кебек, баштанаяк җәлеп итә, без бу тарихның азагы ни белән бетәсен белми торып тынычлана алмыйбыз. Югыйсә, Нетлфикс сериалларындагы кебек, үтә дә баналь сюжет: Конройлар көннәрдән бер көнне кайчандыр Нидерланд магнатлары Ванхубейклардан калган Пенсильваниядәге йортны сатып ала һәм шунда яши башлыйлар. Кемнәрдер фаразынча, голландлар йорты өрәкләр һәм үткән хуҗалардан калган аура белән өретелгән, монда берәү дә бәхетле була алмый, ә портретлардан элеккеге абруйлы затларның карашлары бага һәм һәр адымны сагалый. Ләкин эш өрәкләрдә генәме икән соң? Әллә йорт бары тик инде гаиләдә булган чатнауны аныграк сиздерә һәм башка вариантларга юл калдырмыймы?

–ЮК, АХЫР ЧИКТӘ, «ГОЛЛАНДСКИЙ ДОМ» – ҮЧ АЛУ ҺӘМ ХАКЫЙКАТЬНЕҢ ӨСТЕН ЧЫГУЫ ТУРЫНДАГЫ ТАРИХ ТҮГЕЛ. Ул ялгыш адымнар, үткәннең газабы һәм барлык җиңүләр белән җиңелүләрнең мәгънәсезлеге турындагы тарих.
Вера Богданова, язучы

Без ике бала белән бергә аларның бөтен тормышын диярлек күздән кичерәбез. Һәм, чынлыкта, тарихның нәкъ башына кайтып төшәбез. Әсәрнең башыннан алып азагына кадәр бер уй тынгы бирми – ә гаепле кеше бар идеме соң монда? Бар икән – ул кем?

Бәлки, безнең күзгедәге чагылышыбыз гынадыр...

ТИКТОРМАС КҮЛ ЧЕРКЕНЕ

Руфия Фазылова

Республикада гел макталган берничә район бар. Алар иген уңышы, икътисад, халыкның көнкүреше, башка күп кенә яклар буенча алдынгылар рәтендә йөри. Буа районы әнә шундыйлардан берсе. Яңа елның беренче эш атнасында әлеге төбәктә булып кайттык.

Фото: Лилиана Вәлитова

КҮЛ ЧЕРКЕНЕ

ГОРУРЛЫК

Күл Черкене Буага орынып тора, биш кенә чакрым ераклыкта. Без килгәндә авылда әле Яңа ел рухы сизелә иде – бизәлгән зур чыршы, аллы-гөлле утлар, ясалма шугалак, төрле хайван сыннары... Шәһәр чыршыларыннан бер дә ким түгел.

– Быел бездә республика күләмендә Яңа ел бәйрәме узды, – диде Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы Мөдәррис Истиев. – Көн саен чыршы янында концерт куйдылар, эстрада артистлары да килде. Үзебезнең Мәдәният йорты хезмәткәрләре дә күп көч куйды. Быелгы кебек күңелле Яңа ел бәйрәме булганын хәтерләмим...

Күл Черкене – төп белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы, ике мәчете, мәдәният йорты, китапханәсе, кибетләре булган зур авыл. 456 кеше яши биредә, 297 хуҗалык бар. Төп белем бирү мәктәбендә 39 бала белем ала. Тик авылда мәктәп яшендәге балалар саны күбрәк, кайбер ата-аналар балаларын Буага йөртеп укыта. Ә унынчы, унберенчегә болай да укучылар Буага барып белем ала, чөнки берничә ел элек Күл Черкене мәктәбен тугызъеллыкка калдырганнар.

Казаннан килгәндә, Буа башында безне Күл Черкене авыл җирлеге башлыгы каршы алды.

– Хәзер мин сезне авылның иң хөрмәтле кешесе янына алып керәм, Буада яши ул. Авылның тарихын да сөйләр, – диде Мөдәррис Истиев.

Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов Күл Черкененең генә түгел, республиканың да танылган кешесе булып чыкты. СССР Югары Советы депутаты. 1989 елның 17 октябрендә Кремльдә СССРның соңгы Президенты Михаил Горбачевка шактый кискен сорау биргән кеше дә ул. Соңрак «Зөя» ширкәте төзегән икътисадчы, аннан соң Буада карабодай, борчак, солы кебек культуралар, ярма яру заводы ачкан эшкуар.



1
Без килгәндә авылда әле Яңа ел рухы сизелә иде.

2
Бер бәйрәм дә Мәдәният йорты хезмәткәрләреннән башка узмый...

3
Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов Күл Черкененең генә түгел, республиканың да танылган кешесе булып чыкты.

4
Мөхәммәтҗановларның кышкы бакчаларында сап-сары лимоннар җитешкән, ак, кызыл розалар чәчәктә утыра.

– Сәламәтлегем белән кайбер проблемалар бар, шуңа күрә пандемия башланганнан бирле, балаларны санамаганда, өйгә кеше кертмибез, – диде Мөхәррәм Тимергали улы. – «Татарстан» журналыннан килүләр дигәч, ризалаштым. Сез бит абруйлы басма.

Мөхәррәм Тимергали улына күптән түгел 75 яшь тулган. Хатыны Гөлфия апа белән икәү гомер кичерәләр икән, балалары читтә яши. Мөхәммәтҗановларның кышкы бакчаларын күреп шаккаттык. Анда нинди генә гөлләр, үләннәр юк! Сап-сары лимоннар җитешкән, ак, кызыл розалар чәчәктә утыра.

– Берничә ел элек кыяр-помидорлар да өлгереп утыра иде, хәзер инде кышын чәчәкләр генә үстерәбез, – диде хуҗа кеше. – Хатын белән хобби бу безнең. Мин шушы кышкы бакчада истәлекләр дә язам, иҗат итәр өчен әйбәт урын.

Мөхәррәм ага журналист халкы өчен чын табыш – аның белән бөтен нәрсә турында сөйләшеп була: икътисад, сәясәт, тарих, экология, бакчачылык... Шуңа да шактый озак утырдык аның янында. Ә туган авылы – Күл Черкене турында менә нәрсәләр сөйләде:

– Безнең авыл атаклы саналган. Революциягә кадәр ике мәчет дин нуры тараткан. Халкы бик тырыш булган, сугыштан соңгы авыр елларда да кешеләр ач утырмаган: тегермән төзеп, ипи пешергәннәр. Күл Черкене Зөя елгасы буенда урнашкан авылларның берсе. Узган гасырның 70-80 нче елларына кадәр Зөя, ташып, ярларыннан чыга иде әле. Хәтерлим, моннан алты чакрым ераклыктагы Каенлык авылы белән безнең Күл Черкене арасын су баса иде. Менә шул араны язын көймәдә йөрдек. Һәр авылның үз күпере бар. Язын аны җыеп куялар. Төрлесен күрде авыл. Бүген Күл Черкенендә яшәр өчен бөтен мөмкинлекләр бар, шуңа сөенәм...

«КЫЯР-ПОМИДОРГА КАРАГАНДА, СУГАН ҮСТЕРҮ ОТЫШЛЫРАК»

Авылда үз эшен башлаган кешеләр шактый, Гыйльметдиновлар шундыйлардан. Наил һәм Римма өч ул үстерә. Гаилә башлыгы шәхси эшмәкәр булып теркәлгән, хуҗабикә исә авылда фельдшер-акушер хезмәтендә.

Гыйльметдиновлар төрле тармакта эш алып бара – суган үстерәләр, инкубаторда чеби чыгаралар, пай җирләрен үзләре эшкәртәләр. Әле берничә ел элек теплицада кышын кыяр-помидор да үстереп караганнар, тик бу юнәлештән баш тартканнар.

– Кыяр-помидор үстерү үз-үзен акламый, утка күп акча түлисе, – ди Наил. – Ә кыяр-помидорның тапшыру бәясе йөз сумнар тирәсе генә. Без эшли башлаганда аның килосы ике йөз сумнан да ким түгел иде. Шуннан бәяләр кисәк кенә төшеп китте.

Ә менә кышын кыяклы суган үстерү отышлы икән. Наил инде бу өлкәне җайлаган – килолап Буа, Тәтеш, Апас районнары кибетләренә тапшыра, алып бетерәләр.

– Суганны 130 квадрат метрлы подвалда үстерәбез, – диде эшкуар. – Суганнарны комга утыртабыз. Бернинди ашламасыз егерме бер көндә үсеп җитәләр. Аннан соң гаилә белән бергә җыябыз. Икенче көнне сәүдә нокталарына таратып чыгам. Кыяклык суганның аерым бер вакыты бар, озак торса саргая, ава башлый. Шуңа күрә карап кына торырга кирәк.

Наил белгечлеге буенча агроном. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, читтән торып Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясендә белем алган. Колхозда баш агроном булып та хезмәт куйган. Ә берничә ел элек шулай үз эшен ачкан.

– Җир эше сезонлы бит, – ди Наил. – Шуңа күрә дә төрле юнәлешне өйрәндем. Инкубаторда чебиләр чыгару нияте әнә шулай эзләнә торгач туды. Яз, җәй өчен бер дигән шөгыль. Һәр 21 көн саен инкубаторыбызда сигез мең баш чеби чыга. Йомыркаларны Европадан гына кайтартам. Ветеринария лабораториясендә тикшерелгәннәрен генә алам, чөнки кош гриппы кебек чирле булуы мөмкин. «Кобб 500» һәм «Росс 308» токымнары белән эш итәбез.

– Европадан кадәр йомырка кайтару чыгымлы түгелме соң? Үзебездә дә никадәр кош фабрикасы бар бит, – дим.

– Әйе, бездә дә шактый. Алар белән дә эш иткәнем бар. Ләкин аларда буш йомыркалар күп була, чеби чыкса да, начар үсә. Ә Европадан кайткан йомырка чебиләре тиз үсә, чыгыш та әйбәт.

Гыйльметдиновлар гаиләсендә эш бөтен кешегә дә җитә. Буа техникумында укучы олы уллары, кулына диплом алгач, авылга кайтырга җыена икән. Хәер, гаҗәп тә түгел, әти кеше улларына үрнәк күрсәткән, димәк, шушы юнәлешне үстерергә генә кирәк.



5
– Суганны 130 квадрат метрлы подвалда үстерәбез, – диде Наил Гыйльметдинов.

«БАКЫЙ УРМАНЧЕ ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!»

Күл Черкене Бакый Урманченең туган авылы. Татар сынлы сәнгатенә нигез салучы әлеге бөек шәхес биредә үскән. Авылдашлары аның турында гел бер фикердә: «Гаҗәп дәрәҗәдә гади, ләкин бик зыялы, итәгатьле иде», – диләр. Күл Черкенендә Бакый аганың музее бар. Тыштан ул рәсемдәге йортны хәтерләтә – агачтан, челтәрле тәрәзә яңаклары белән. Сынчы үзе яратканча – гадилек белән бергә зәвык сизелә анда.

– Музей 2012 елның 11 февралендә ачылды, – диде музей җитәкчесе Илдия ханым Гыйниятуллина. – Буа Туган якны өйрәнү музее филиалы булып торабыз. Аның ачылышына ул чакта ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры булып эшләгән Марат Әхмәтов килде.

Баксаң, Күл Черкенендә Бакый Урманче музеен булдыруны Флора Әхмәтова-Урманче бик теләгән икән. Иренең вафатыннан соң, Флора ханым бу якларга еш кайткан – мәктәптә булган, халык белән аралашкан, Урманчеларның нәсел шәҗәрәсен өйрәнгән. Ни кызганыч, Күл Черкенендәге әлеге музейны күрмичә бакыйлыкка күчкән ул.

Әлеге зур булмаган музейда Бакый Урманче ясаган сыннар, картиналар шактый.

6
Зур булмаган музейда Бакый Урманче ясаган сыннар, картиналар шактый.

7
Биредә үзенчәлекле экспонат саклана – Бакый Урманченың вафатыннан соң алынган битлеге.

8
– Рөстәм Миңнеханов бүләк иткән Бакый Урманче портретын саклап кына тотабыз, – ди музей җитәкчесе Илдия Гыйниятуллина.

Аларны атаклы сынчының улы Айдар махсус бүләк иткән.

– Безнең музейга ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның да килгәне бар, – диде Илдия Гыйниятуллина. – Рәссам Ирек Нуретдинов ясаган Бакый Урманче портретын бүләк итте. Без аны менә шулай саклап тотабыз.

Гадәттә, музейларга баргач, үзенчәлекле экспонат күрсәтүләрен сорыйм. Биредә дә андый экспонат бар – Бакый Урманченың вафатыннан соң алынган битлеге. Ул бары тик бер генә икән. Башта ул Буа Туган якны өйрәнү музеенда торган. 2012 елда исә Күл Черкененә алып килгәннәр.

– Музейга бик күп кеше килә, – диде мөдир. – Күпләр сынчының туган авылы нинди икән, дип тә кызыксына. Аннан, без Буага якын. Әйе, музеебыз зур түгел, ләкин бай ул. Ачылган вакытта тагын бер зал өстәп салабыз дигән сүзләр дә ишетелде. Кем белә, бәлки киләчәктә булыр да.

«ҖИДЕ БАЛА – ЧИК ТҮГЕЛ...»

Күл Черкенендә күп балалы гаиләгә дә кердек. Ирле-хатынлы Наилә һәм Марат Гайфуллиннар җиде бала (сигезенчесен көтәләр) үстерә. Егерме ел элек гаилә корган ир белән хатын дин кануннары буенча яши.

– Өйләнгәнче үк намазда идем, – диде Марат. – Башта үзебезнең авыл мәчетендә гарәп графикасын, Коръән сүрәләрен өйрәндем. Аннан Буада мәдрәсә тәмамладым. Әби белән бабай да күп догалар өйрәтте, алар гомергә диндә булган.

Маратның әти-әнисе – Фирдүс абый белән Фирдәвес апа да биредә иде. Алар икенче урамда гомер итә икән. Марат – өлкән уллары. Тагын бер уллары һәм кызлары гаиләләре белән Буа шәһәрендә яши.

– Ярдәм сораганда, балалар белән калып торырга кирәк булганда гел киләбез, – диде Фирдәвес апа.

– Тагын бер улыгыз белән кызыгыз да намаздамы? – дим.

– Юк, алар дин кануннары буенча яшәми. Әлбәттә, Аллаһның барлыгына, берлегенә инаналар. Тик әле абыйлары кебек яшәргә сәгате сукмагандыр. Мин менә акрынлап шул юлга бастым, иншәАллаһ.

Марат ике йөз башлап сарык үстерә. Пай җирләрен алган, авыл башына кечкенә ферма салган.

– Элек йөк ташу белән шөгыльләнә идем, хәзер КАМАЗларны саттык, – диде гаилә башлыгы. – Ун ел элек фермерлык эше белән кызыксынып китеп, сарыклар сатып алдым. Шуннан баш санын гел арттырдым. Ел әйләнәсе ит сораучылар бар. Әле менә бүген генә дә бер сарык суеп бирдем. Ә Корбан бәйрәменә иллеләп китә.

Марат ел саен Корбан гаете көнне авылдашларын тәмле пылау белән сыйлый икән.

Шуның өчен ул махсус сарык суя, зур казанда пешерә. Наилә камыр ризыклары пешерә, чәй кайната. Күрше-тирә, корбан сарыклары алырга килгән һәркем табын янына килми китми.

Ашау-эчү турында сүз чыккач, хуҗабикәгә дә сүз каттым. Наиләнең төп эше бала карау. Буа ветеринария техникумының икенче курсында укыганда яулык япкан ул. Тора-бара эти-әнисе дә дингә килгән.

– Балаларны да Аллаһ кушканча тәрбиялибез, иң зур сөенечем шул, – диде Наилә.

– Күп балалы әни булуның уңай, тискәре яклары нинди? – дим.

– Тискәре дип... Балалы йортта фәрештәләр яши бит. Аллаһка шөкер, тормыш алып бару өчен бөтен нәрсә бар. Менә яңа йорт җиткереп чыктык. Башта Маратның әби-бабасыннан калган кечкенә йортта яшәдек. Хәзер инде иркенәйдек. Азмы-күпме дәүләт тә ярдәм итә, пособие түлиләр. Балалар бер-берсенә карата бик игътибарлы, итәгатьле. Ике балабыз инде безнең янда түгел. Олы улыбыз Уфада мәдрәсәдә укый, ә кызыбыз Мөхәммәдия мәдрәсәсендә белем ала.

Наиләгә узган ел «Ана даны» медален тапшырганнар. Әлбәттә, алар балаларын үзләре өчен дип таба, үстерә. Аллаһның бүләге дип кабул итә. Ләкин дәүләт тарафыннан әнә шундый игътибар булу гаилә өчен зур куаныч та, мәртәбә дә.

...Бакый Урманче музеена кергәч: «Икмәкле вә шикәрле Буа төбәгендә сезне күрүебезгә бик шатбыз», – дип каршы алган иде Илдия ханым Гыйниятуллина. Кайтканда ул җөмләнең асылына янә бер кат төшендем. Шуңа кунакчыл дип тә өстисе килде.

9
Ирле-хатынлы Гайфуллиннар: «Балалы йортта фәрештәләр яши бит».

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов:

– Авылның кайчан барлыкка килүе һәм исеменең ни өчен Күл Черкене дип аталуы турында төгәл мәгълүмат юк. Якынча XVIII гасыр башларында оешкан дип карарга кирәк. Безнең якларда Черкен исемле җиде авыл бар. Халык сөйләве буенча, бу урыннарда сазлык булган, табигый ки, черкиләр дә яшәгән. Менә шуңа да яңа оешкан авылларга «черкен» атамасы биргәннәр дигән фараз бар.

Бу урында шуны әйтим: безнең як зонасында эчәргә яраклы су юк диярлек була. Судагы кальций составы унбердән дә ким түгел, ә норма буенча ул җидедән артмаска тиеш. Безнең бабайлар шуны белгән, күргән. (Суны бит кайнатып караганнар.) һәм Зөя елгасын авылга таба ерып керткәннәр. Нәтиҗәдә, авылда күл ясалган, димәк, эчәргә яраклы су да барлыкка килгән. Авыл атамасындагы «күл» сүзе менә шуның белән бәйле булырга бик мөмкин.

РУДОЛЬФ НУРИЕВ
ӨЧЕН УНИКЕ КЕЛӘМ

Лариса Усманова

Дөньяның төрле почмакларында яшәүче кешеләр арасында данлыклы милләттәшебез, балет артисты Рудольф Нуриев турында хатирәләрен кадерләп саклаучылар да шактый. Кайвакыт бу хакта гаҗәеп урыннарда һәм гаҗәеп рәвештә мәгълүм була...

– Күптән түгел мин Төркиягә бардым һәм Эгей диңгезе ярларындагы шәһәрләр буйлап сәяхәт иттем. Кайчандыр Борынгы Грециянең Ликия провинциясендәге порт каласы булган бик кечкенә, әмма бик матур һәм тарихи Каш шәһәрендә, кичен дусларым белән тар урамнарда сәйран кылып йөргәндә, борынгы келәмнәр кибетенә кердек. Инде бик соң, шуңа салонда беркем дә юк иде. Әмма диварларда таң калдыргыч келәмнәр эленеп тора, соңыннан ачыклангача, аларның күпчелеге берәр гасырдан артык тарихка ия булып чыкты. Берничә минуттан соң, елмаеп, хуҗа да күренде (ул икенче катта яши икән). Сөйләшеп киттек. Мондый очракларга хас: «Кайдан килдегез?», «Төркиядә беренче тапкыр гынамы?», «Кашта булганыгыз бар идеме?», «Ни белән шөгыльләнәсез?» – кебек сораулар ява башлады.

Без башта Россиядән килүебезне әйттек. Аннары Татарстаннан, Казаннан булуыбызны өстәдек. Һәм көтмәгәндә татарлар турында бик күп җылы сүз ишеттек. Кибет хуҗасы Чыңгыз үзенең татарларны яхшы белүен һәм яратуын әйтте, чөнки ул халкыбызның иң күренекле вәкилләреннән берсе Рудольф Нуриев белән таныш булган икән!

Келәм кибете хуҗасы бу шәһәрдә 50 елдан артык яши, артист исә яхтасында еш кына Кашка керә торган булган. Эш шунда ки, Нуриев келәмнәрне бик яхшы белгән һәм коллекциясенә туплаган. Әлеге төрек кибетеннән ул берничә ел эчендә уникедән артык борынгы кыйммәтле келәм сатып алган. Хуҗа белән дуслашкан, әллә ничә тапкыр аның кафесында диңгезгә хозурланып утырган. Үз сүзләрен раслап, Чыңгыз безгә Нуриевның фотосын һәм үз кулы белән язып биргән чегын күрсәтте, ул аларны махсус папкада кадерләп саклый икән.

Без дә үзе аяклы тарих булган кибет хуҗасы белән фотога төштек.Чыңгыз Истанбул университетында сәнгать белгече һөнәрен үзләштергән. Укуын тәмамлагач, келәмнәр кибете ачкан. Аннары Эгей диңгезе буенда да салон ачып җибәргән, чөнки бирегә җәйләрен Европа элитасы һәм мәдәнияте вәкилләре күп килә икән. Әмма миңа бөек татар турында рәхәтләнеп татарлар белән сөйләшү аңа әле беренче тапкыр гына насыйп булган.

Автор фотосы

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама